КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 23
22 декабрь
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



Бүгенге санда:

2 *Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.* Вакытлыча эшкә яраксызлык, йөклелек, бала табу, гарип балаларны тәрбияләү һәм башка социаль яклау өчен акчаны социаль иминият фонды табарга тиешле.

6 *Сәйфихан НАФИЕВ.* Мин хезмәттәшләремә карата кырыс түгел, шулай да таләпчән, үз хезмәтен төгәл башкаруны, гадел һәм заманча карар чыгаруны таләп итәм.

10 *Фәнис ЯРУЛЛИН.* Күп кенә очракта кешегә матди ярдәм дә кирәкми, аның ялгыз түгеллеген, янында индәшләре, фикердәшләре, кирәк чакта таянычы барлыгын белгертеп торсаң да җитә.

16 *Ризван ХӘМИД.* Соңгы 70-80 елда халкыбызның табигате шулкадәр танымаслык булып үзгәрде ки, без хәзер ат менүгә атабызны онытабыз.



Кайсы тарафларга юл чыксак та,
Киләчәккә урап кайта уйлар...

МӘДӘНИ
ҖОМГА

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Ниһаять, без быел да иң-иң кыска көн чиген узып барабыз. Тагын берничә тәүлектән Кояш соңрак баеп, көннең озынлыгы берәр генә минутка булса да арта башлаячак. И бу Табигатьнең могҗизасы: көн вә төн озынлыкларын үзгәртеп, Адәм баласында яктылыкка, яшәүгә сусау-дәрт уята. Димәк, тиздән күп гамәлләребезне якты көздә кылып, илаһи чыраг нурын күңелләребезгә күбрәк сеңдерергә мөмкинлек туачак. Менә-менә кошкы кояшлы көннәр башланыр, язгы чирәмгә басып, бик тә кыска төнле җәйгә барып җитәрбез. Их, яшиселәр алда әле!..

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН

КАРАР ТУРЫНДА КАРАР

Бу хакта сүз башлануга ук. «Нигә әле кычытмаган җирне кашырга алындың, энекәш?» диючеләр табылды «Әйе булды андый хаталану әмма дә ләкин төзәттек ич инде без аны». — диделәр сиртмәле кәнәфиләрендә утыручы тук чырайлы бәгъзе түрәләр Бер карасаң, хаклы да кебек иде алар Ә шулай да шулай да.

Безнең халык иртәгесен баш җитмәс, колак ишетмәс нәрсәләр булырына тәмам күнегеп бетте инде Берәүне ишеге төбендә атып екканнар икенчесе Идел ярына ук терәп катлы-катлы йорт төзегән фәлән дә фәсмәтән икән дигән сүзләр таң аткач кич буласы кебек табигый бер нәрсә сыман кабул ителә башлады

Көннәрнең берендә халык арасында безнең өчен янып-көеп яшәүче хөкүмәтебез янә бер карар кабул иткән һәм ул «Татарстан Республикасында гражданнарның хезмәткә вакытлыча сәләтсез булуларын раслаучы документларны бирү тәртибен һәм хезмәткә вакытлыча сәләтсез булу йөклелек һәм бала табулар буенча пособиеләр белән тәэмин ителешне камилләштерү турында» дип атала икән дигән сүз таралды

Тора-бара моның чыннан да хак икәнлеге мәгълүм булды Гәзитләр әлеге карар шушы елның 24 октябрендә 790 нчы номер белән кабул ителде. дип хәбәр салды «Ватаным Татарстан» гәзите исә бу карарны тулысынча үзенең сәхифәләрендә бастырып та чыгарды Журналист халкы кызыксынмый кала димени инде?! Без дә әлеге карарны игътибар белән укып чыктык Беренче карашка барысы да яхшы халык мәнфәгатьләренә туры килә кебек Чернобль АЭСы шартлау нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә һәм башка шуның кебек афәтләргә дучар булучыларга. йөрәк туберкулез авырулары белән җәфаланучыларга бик күп кенә өстенлекләр ташламалар вәгъдә итә әлеге карар

Хәер карар карар инде Моңа кадәр дә кабул ителде алар киләчәктә дә кабул ителер Дөресен генә әйткәндә халыкның аларга исе китүе шуның кадәр генә лә бугай Ни генә димәсеннәр купшы матур сүзләр язылган ул карарларның байтагы кәгазьдә генә кала эш-гамәлләребездә әллә ни файда бирми

Ярар югарыда телгә алынган карардан читкә китмик әле Бу юлы чыккан карарны да белгечләр күккә чөеп мактарга кереште Русия Федерациясенең социаль иминият фондының Татарстан региональ бүлеге (әлеге карар нәкъ менә аларның турыдан туры тырышлыгы белән иҗат ителгән) идарәчесе урынбасары В Хаҗиәхмәтова сүзләренә караганда моңа кадәр пособиеләр билгеләү һәм бүлү Русия Федерациясенең социаль иминият фонды тарафыннан 1984 елда кабул ителгән һәм 1995 елның башында үзгәрешләр кертелгән положениеләр нигезендә тормышка ашырылган Русия Федерациясендә бүгенге көндә хезмәткә түләүнең минималь күләме 55700 сум ә Татарстанда 200 мең сум булу сәбәпле иминият фондының Татарстан региональ бүлекчәсе чыгымнарны Русиянең башка төбәкләренә караганда 3,6 тапкыр күбрәк тота икән. Белгеч фикеренчә хезмәткә вакытлыча яраксыз булганда больничный лист бирүне тәртипкә китерергә. ягъни авыруларга акча түләүне киметергә кирәк. Шул чагында хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына санаторий-курорт хезмәте күрсәтү аша профилактика эшен яхшыртырга мөмкинлек туачак, имеш Имәндә икән чикләвек, диюләре менә шул була да инде

Моңа кадәр кабул ителгән купшы карарлар үтәлмәсә дә, очын-очка көч-хәл белән ялгап яшәүче халыкның тез астына монысы кебек сугардайлары юк иде шикелле Югарыда телгә алынган белгечебез әлеге карарны туын, ә хастаханәләргә барып дәвалану бик аз кешеләргә генә насыйп булуын да белергә тиешләрдер Мәгълүматлар шуны күрсәтә: халыкның тормыш хәле көннән-көн авырая. Гаиләнең дүрттән өч өлеше авырлык белән генә очны-очка ялгап бара. Ни кызганыч, гарип балалар күп туа, инвалидлар саны арта. Балаларыбыз җәйге ялларын лагерьларда үткәрә алмый. Экспертларның әйтүенә караганда, әлкән сыйныфларда укучыларның бары 0,8 проценты гына таза-сау. Соңгы бер ел эчендә генә дә ятим балалар саны икеләтә арткан. Җинаятьләр саны да балигъ булмаучылар исәбенә ишәя. Сүз уңаеннан әйтик, безгә Президентыбызның социаль страхованиеләргә кагылышлы мәгълүм указына, Конституциябезнең 3, 7, 10, 20, 46 нчы маддәләренә, хезмәт турындагы кодексыбызга каршы килә торган чиле-пешә генә үткәртеп җибәрү ягында һәм ул аны халык файдасына. дип тәкрарлый Карар үтәлгән чакта авыру баланы өйдә караган өчен элек 100 процент хезмәт хакы түләнсә хәзер 80 процент. хастаханәдә дәваланса 60 процент түләнә. ә инде янга калган акча хезмәт ияләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына санаторий-курорт хезмәте күрсәтү өчен тотылачак, имеш Әмма эшләгән акчасын берничә айлар соңарып алучы гади халыкның соңгы елларда кайда да булса барып ял итеп кайтканын ишеткәнегез бармы сезнең? Юктыр мәгаен болай барган очракта тиз генә булачак та түгелдер Бездә әйткәнемчә хөкүмәтебез тарафыннан төрле мәсьәләләргә караган карарлар кабул ителә тора. Аларның еш кына тормышка ашмавы. мәгаен. төптән уйланып эшләнмәү нәтиҗәседер Әйтик. халыкка хезмәт хакын үз вакытында бирүне алга сөргән карар нигә үзенең уңай нәтиҗәләрен бирми соң? Күп кенә районнарда игенчеләребез. терлекчеләребез әле дә булса җәй айлары өчен хезмәт хакларын ала алмый интегәләр бит Алганнары исә хезмәт хакын кәбестәләтә чөгендерләтә генә алдылар Мисаллар китереп тормыйм аларны укучылар үзләре дә беләләр Белмәсәләр авыл халкы белән сөйләшеп карасыннар шәһәр предприятиеләрендә оешмаларда эшләүчеләр янына барсыннар

Без сүз кузгаткан һәм халык тарафыннан катгый рәвештә кире кагылган карарны иҗат итүчеләр хастаханәләрдә төрле даруларны хәтта бармак бәйләр өчен бинтларга кадәр табибларның үзенә табарга кушуларын белергә тиешләр иде Халыкка социаль яклауны яхшыртабыз дип көне төне сөйләүче вәгъдәләр бирүче җитәкчеләребез авыруларның көннән көн артуын, ә хастаханәләргә барып дәвалашле карарлар кабул иткәнче, Җөмһүриятебездә БМО конвенциясе таләпләренә яраклаштырылган балалар хокукларын, авыру-гарипләр мәнфәгатен яклаучы норматив документлар булдыру турында уйларга вакыт җитте.

Янә «Татарстан Республикасында гражданнарның хезмәткә вакытлыча сәләтсез булуларын раслаучы документларны бирү тәртибен һәм хезмәткә вакытлыча сәләтсез булу. йөклелек һәм бала табулар буенча пособиеләр белән тәэмин ителешне камилләштерү турында»гы карарына әйләнеп кайтыйк әле Шушы елның 24 октябрендә кабул ителгән карарның гомере. бәхеткә озын булмады Аңа каршы иң әүвәл Татарстан Җөмһүрияте профсоюзлар федерациясе рәисе Фәридә Гайнуллина каршы чыкты Карарның ачлыктан тилмерүче авыру халыкка каршы юнәлтелгән булуын әйтте 22 ноябрьдә Татарстан Республикасы Конституция күзәтүе комитеты әлеге карарны дөрес түгел дип тапты Соң булса да, уң булсын, диптер инде. 22 ноябрьдә даими эшләүче парламентыбыз да бу мәсьәләгә үзенең мөнәсәбәтен белдерергә булды, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аның гамәлдән чыкканлыгын билгеләп үтте.

24 октябрьдә кабул ителгән һәм айга якын гади халыкның җанын игәүләп, бимазалап торган больничный листларга түләүне шактый киметкән карар шактый гына күңелсез уйларга этәрде Әле дә истә, онытылмаган Дәүләт Советына сайлаулар башланыр алдыннан безнең бүгенге депутатларыбыз үз сайлаучыларына ниләр генә вәгъдә итмәделәр Халык өчен җан тәслим кылырга да әзербез, диде алар ул көннәрдә Кызганыч, хөкүмәтнең 790 нчы халыкка каршы юнәлтелгән карарына каршы бер генә депутатыбыз да күтәрелеп чыкмады аны төнкыйтьләмәде. Битараф булып калды. Дөрес, соңыннан халык депутаты Ю.Прохоровның бу мәсьәләне Дәүләт Советы сессиясендә карауны тәкъдим итүе мәгълүм булды. Әмма сессия аны тикшерүне, бәя бирүне кичектерә килде, бары тик эш узгач, республика Конституцион күзәтчелек комитеты әлеге карарны һәм аның буенча расланган нигезләмәне дөрес түгел дип тапкач кына әйләнеп кайтты, карар турында карар кабул итте. Ыгы-зыгы, күп аңлашылмаучылыклар тудырган 790 нчы карар хөкүмәт структурасына кергән оешмаларның, мөстәкыйльлек юлыннан барабыз дип мактанышкан без фәкыйрьләрнең һәр закон, һәр карар кабул иткәндә Мәскәү тарафларына карап эш йөртүе абыну-сөртенүләр китереп чыгара. Монысы да шуның ачык мисалы иде. Мәгълүм карар гамәлдән чыккач, Татарстан Республикасы хөкүмәтенең матбугат үзәге халыкка мөрәҗәгать итте, мәсьәләгә ачыклык кертергә омтылыш ясады. Хөкүмәтебезне бу адымга барырга берничә сәбәп мәҗбүр иткән икән. Вакытлыча эшкә яраксызлык, йөклелек, бала табу, гарип балаларны тәрбияләү һәм башка социаль яклау өчен акчаны социаль иминият фонды табарга тиешле Ә ул юк, чөнки акча күчерергә тиешле фәкыйрь предприятиеләр нәтиҗәсез эшли, җитмәсә Русия Сәламәтлек саклау министрлыгы инструкциясе нигезендә табиблар вакытлыча эшкә яраксызлык кәгазьләрен озаграк вакытларга мөстәкыйль бирү хокукы алдылар. Моның нәтиҗәсе билгеле инде Әлеге дә баягы, кода-кодагыйлык чәчәк атты Хәер, сәбәпләрнең иге-чиге юк Ә безнең хөкүмәт, бошул сәбәпләрне бетерәсе урында, болай да хәлдән тайган халыкны талау юлын сайлаган булып чыкты.

Карар юкка чыгарылса да, мәсьәлә әле дә ачык кала. Алдагы көннәрдә шушы уңай белән кабул ителәчәк карар халык авызына кәрәсе кара икмәк хисабына эшләнмәс дип кем өздереп әйтә ала?

..Сүз башыбыз Шүрәле турында иде бит, дигәндәй, алдан ук кычытмаган җирне кашып куюыбызның сәбәбе дә әнә шунда. Тел кашып торганда да чамага гына туры килә әле ул безгә

ЖИДЕГӘН 5 6 7 1 2 3 4 ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Бу сайлау — безнекеме?

Бу җәһәттән Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Марат Сираев болай дигән иде:

— Иң беренче шуны әйтәсем килә, Русия тапшыруларында — радиоданмы ул, телевизорданмы — сайлауга килүчеләрнең саны моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә, дип сөйлиләр, тегө сайлауларга караганда 10-15 процентка арттьы, диләр. Бездә андый әйбәр юк. Татарстан халкы өчен бер нәрсә хас — ул электән үк сайлауларга килә. Халык дәүләт органнарын формалаштыруга битараф түгел. Менә бер генә мисал: 1994 елда Русия Федерациясе Дәүләт Думасына беренче сайлаулар үткәрелде. Анда Татарстан сайлаучыларының 58,5 проценты катнашты. 1995 елның 5 мартында үзебезнең Дәүләт Советына сайлаулар булды. Анда 59,7 процент кеше катнашты. Хәзер менә Русия Федерациясе Дәүләт Думасына икенче сайлау үткәрдек. Анда 58,7 процент сайлаучы катнашты.

Марат әфәнде тарафыннан бәян ителгән мәгълүматларга карасак, аныңча, безнең Русия Дәүләт Думасына депутатлар сайлауда катнашуыбыз бик тә мөслихәт гамәл булган икән. Әйтәсе дә юк инде, нинди гакыллы, нинди тәүфыйклы безнең халык! Ошбу сайлауларда 58,7 процент сайлаучы катнашкан лабаса. Ә Татарстан Конституциясендәге маддәләргә караганда хурлык түгелме соң бу? Хуш, хәзер коммунистлар һәм Жириновскийның ЛДПРы беренче урында тора. Нигә? Кем гаепле? Без үзебез, әлбәттә.

Ярый, бүген без коммунист һәм шовинист депутатларны сайладык, ди. Ялгыштыкмы? Киләсе елда урысның иске Президенты урынына яңасын — Жириновскийны сайлап куйсак, бик күпләргә букчаларын, чүпрәк-чапракларын җыеп, Монголиягә китәргә туры килмәсме?

Заһид МӘХМҮДИ.

«Ул флаг миндә аллергия уята»

Дәүләт Думасына сайлаулардан соң, Казанда Татар иҗтимагый үзәге матбугат конференциясе үткәрде. Конференциядә Үзәкнең президенты Марат Мөлеков хәбәр иткәнчә, 17 декабрьдә дә сайлау участокларында агитация эше бернинди тоткарлыксыз, актив рәвештә алып барылды. Дервишләр бистәсендәге 2116 нчы сайлау участогына Татар иҗтимагый үзәгенең ашыгыч ярдәм төркеме бара. Кайтканда төркемдәгеләр Татарстан Конституциясе тарафыннан расланмаган Русия Федерациясе флагын элеп куелган җиреннән алып ташлый. Шуның өчен Татар иҗтимагый үзәгенең алты активистын — ТИҮнең президиум әгъзасы, запастагы полковник, техник фәннәр докторы, «Мәрҗани» җәмгыяте президенты, язучы Зәки Зәйнуллинны, ТИҮнең президиум әгъзасы, запастагы полковник, качаклар һәм күченеп кайтучылар фонды рәисе Юныс Камалетдиновны, ТИҮнең президиум әгъзасы, Ватан сугышы инвалиды Зөфәр Сәлиевне, ТИҮнең рәис-координаторы, мәктәп директоры Фәрит Уразаевны һәм тагын ике кешене, сайлау көнне, көндезге сәгать 1дә, милиция кулга алып, изоляторга озата.

Бу турыда «Маяк», «Азатлык», «Свобода», Би-би-си радиостанцияләре хәбәр итә.

Иртәгесен Татар иҗтимагый үзәгенең президиумы җыела. Анда тоткарланучыларны азат итү буенча программа төзелә. Алар азат ителмәгән сурәттә президиум әгъзаларының берсе үзен-үзе яндырырга карар итә. Шокер, иртәнге сәгать 8дә тоткынлыктан иреккә чыгарыла.

Матбугат конференциясендә тоткарланучыларның берсе — З.Сәлиев болай диде:

— Ватан сугышы елларында без 1001 көн буе төньяк сопкаларда яттык, безгә каршы власовчылар шушы Русия флагын күтәреп сугышты. Шул флагны күрсәм, миндә аллергия башлана, мин аны кайда күрсәм дә, алып ташлаячакмын.

Матбугат конференциясендә Татар иҗтимагый үзәгенең сәяси белдерүе игълан ителде.

Композиторга — истәлек тактасы

Мәсгут Латыйпов татар музыка сәнгатен үстерүгә үзеннән лаеклы өлеш керткән күренекле шәхесләребезнең берсе иде. Ул дистәләгән җырлар, кантаталар иҗат итте. «Сафа» операсын язды. Ул шулай ук тынлы оркестр өчен язылган байтак кына әсәрләр авторы буларак та билгеле.

Шушы көннәрдә күренекле композиторның истәлеген мәңгеләштерү җәһәтеннән Казанда, ул яшәгән Горький урамындагы 17 нче йортта истәлек тактасы куюу тантанасы булды. Аңа татар һәм урыс телләрендә: «Бу йортта 1956-1987 елларда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор һәм дирижер Мәсгут Латыйпов яшәде», — дип язылган.

Әлеге тантанага килгән Татарстан Мәдәният министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре, композиторлар, җырчылар үзләренең чыгышларында Мәсгут Латыйповның иҗатына һәм дирижерлык эшчәнлегенә югары бәя бирделәр, аның тормышта да ихлас күңелле, олы җанлы кеше булуын билгеләп үттеләр.

Ә.ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Президенты Указы белән яшьләргә белем һәм тәрбия бирү өлкәсендәге казанышлары өчен **«Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы»** дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Людмила Анатольевна ФРОЛОВА — Лениногорски шәһәренең 12 нче мәктәп-лицее директорының фәнни-эксперименталь эш буенча урынбасары;

Рәзинә Заһирҗан кызы ШАРАЕВА — Баулы район хакимияте мәгариф бүлегенең укыту-тәрбия эшләре буенча инспекторы.

Эчкерсез истәлекләр дәшә

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе күренекле әдип Гурий Тавлинның туууна 70 ел тулуга багышланган кичәгә дәшә. Язучының үзе һәм иҗат юлы белән, иң эчкерсез истәлекләр белән якыннан таныштырачак бу мәҗлестә танылган сәнгать әһелләре дә катнашачак.

Кичә 1995 елның 25 декабрендә Язучылар берлегенең Тукай клубында (Комлев урамы, 14) 18 сәгатьтә башлана.

Кичәгә рәхим итегез!

Чыңгыз Айтматовның бабасы — безнең якташыбыз

Бишкекта Татарстанның хәзерге Кукмара районында туып үскән татар эшмәкәре, танылган язучы Чыңгыз Айтматовның бабасы Хәмзә Абдувәлиев турында фильм төшерделәр.

Картинаның режиссеры — Рахилә Җамабаева, ә сценарий авторы — Хәмзә аганың оныгы Ринат Абдувәлиев. Кыргыз телендәге бу фильм тиздән татарчага тәрҗемә ителәчәк.

Хәмзә ага Каракол шәһәрендә иң дәрәҗәле кешеләрнең берсе булган. Ул биш кибет һәм чүлмәкләр ясый, тирә эшкәртә торган ике остаханә тоткан. Шәһәрдә үз хисабына кыргыз мәктәбе ачкан һәм аның матди чыгымнарын үз өстенә алган. Әле аның кылган игелекләре моның белән генә бетмәгән. Хәмзә бай — шәһәрдә татар басмаханәсен оештыручыларның берсе булган, мәчеткә дә ярдәм итеп торган.

Котлыйбыз!

23 декабрьдә тумышы белән татар булган күренекле үзбәк язучысы, Хәмзә исемендәге Үзбәкстан Дәүләт бүләге иясе Әсгать Мохтарның дөньяга килүенә 75 ел була. Үзбәкчә язылган роман һәм повестьлары, шигырь һәм поэмалары белән дан казанган якташыбыз татар әдәбияты барлыгын да онытмады. Илленче-алтмышынчы елларда Үзбәкстанда аның тырышлыгы белән Г.Тукай, М.Җәлил җыентыклары дөнья күрде. Ә.Мохтар ул китапларны туплаучы да, кереш сүз авторы да булды, кайбер шигырьләрнең тәрҗемәчесе дә иде. Аның татар язучылары белән якыннан аралашып яшәве һәм мәрхүм әдибебез Габдрахман Әпсәләмов белән баҗа булганлыклары да мәгълүм.

Ике халыкның олы зыялысы булган шәхесне — Әсгать ага Мохтарны Татарстан язучылары, «Мәдәни җомга» укучылары исеменнән кайнар котлыйбыз, аңа саулык-сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

Ярминкәләргә килегез

Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков кышкы ярминкәләрне үткәрү турында махсус боерык чыгарды. Алар түбәндәгечә үтәчәк.

Чехов базары
26 декабрь, Арча.
27. Апас.
28. Саба.
29. Теләче.

Мәскәү районы
26. Биектау.
27. Буа.
28. Балтач.
29. Кукмара.

Идел буе районы
26. Әтнә.
27. Балык Бистәсе.
28. Лаеш.
29. Питрәч.

Авиатөзелеш районы
28. Кайбыч.
29. Кама Тамагы.

Яңа Савиново районы (Адоратский урамы)
29. Югары Ослан

Совет районы (Дервишләр бистәсе)
28. Чүпрәле.
29.Тәтеш.

Җомгадан — җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Киләсе елның 24 мартында республикада Татарстан Президентын сайлаулар үтәчәк.

Якын көннәрдә «Казан» милли мәдәният үзәгендә язучы Миргазиян Юныс иҗат иткән агач сыннар күргәзмәсе ачылачак.

Казанда тимераякта фигуралы шуучыларның шәһәр хакимияте призына «Идел-95» халыкара бәйгесе булып үтте.

Татарстан хатын-кызлары корылтае уңаеннан ВИКО күргәзмә үзәгендә төрле илләрдән килгән 70кә якын предприятие, фирма катнашкан «Хатын-кыз һәм бизнес», «Яңа ел бүләкләре» дигән күргәзмә-ярминкә 23 декабрьгә кадәр эшли.

Зеленодолда икенче татар китапханәсе ачылу тантанасында аңа Татарстан Милли китапханәсе — татарча китаплар, ә җирле хакимият фортепьяно бүләк итте.

Ырынбурда татар театры эшли башлауга 90 ел тулуга багышланган фестивальдә Татар дәүләт академия театры Т.Миңнуллинның «Җанкисәккәем» спектаклен күрсәтте.

КамАЗның кою заводының 10 мең эшчесе, хезмәт хакын вакытында түләмәгәнгә һәм эшчеләрне эштән бушата башлауларына түзә алмагач, шушы көннәрдә забастовка игълан итте.

Сәхифәдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Кече хуҗага яраган...

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш идарәсенең элекке хезмәткәрләре А.Хамматов, С.Оганесян, С.Поляков, Л.Хәкимуллин, С.Николаев турында республикада ишетмәгән кеше юктыр. Аларны Татарстан Югары суды коллегиясе вәкаләтләрен арттырып җибәрүдә, сак астындагыларны кыйнауда гаепләп төрлесен төрле срокка хөкем иткән иде.

Ләкин суд карары белән риза булмаган «бишлек» Русия Югары судына кассацион шикаять белән мөрәҗәгать итә. Быелның 17 июлендә ул Татарстан Югары суды карарын кире кагып, эшне яңадан тикшерүгә җибәрә.

Инде менә Татарстан Югары суды коллегиясе (башка составта, әлбәттә) әлеге милиция хезмәткәрләрен аклый.

Менә шушы инде ул хокук саклау органнарының ике хуҗага хезмәт итү бәласе! Кече хуҗага яраган олы хуҗага ярамый.

«Сөембикә манарасы»н эчәрбезме?

Сәүдә-сәнәгать палатасында Мәскәүнең «Майский чай» компаниясе товарларын тәкъдир итү булды. Исеменнән күренгәнчә, бу компания чәй җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә. Алар Татарстан өчен махсус «Сөембикә манарасы» дигән чәй дә җитештерергә әзер. Аның тартмасы, дизайны инде эшләнгән. Мәскәүлеләр, аны Казанда сатып алырга теләүче эре эшмәкәрләр табылыр, дип уйлыйлар. «Нигә эре эшмәкәрләр, нигә дәүләт сәүдә оешмалары түгел?» — дигән сорауга компания вәкиле А.Воронов болай дип җавап бирде:

— Эре эшмәкәрләрнең мөмкинлекләре киңрәк, аларның безнең чәйне сатып алу өчен көчләре җитәрлек булыр, дип уйлыйбыз.

Шулай итеп, татарстанлыларның кайнап торган самавыр каршында тирләп-пешеп «Сөембикә манарасы» чәе эчәсе көннәре алда әле.

«Мәкәрҗә»... Туймазыга күчкән

Туймазы татар дәүләт драма театрының ачылуына 5 ел тулды. Бу датаны Башкортстан Республикасы җәмәгатьчелеге зурлап билгеләп үтә. Театрның юбилей сезоны Татарстанның халык шагыйре, драматург Илдар Юзеевның «Мәкәрҗәгә барган идек...» дигән комедиясе белән ачылды.

Театрның баш режиссеры — Әбелхәер Сафиуллин. Комедиягә музыканы композитор Рим Хәсәнов язган.

Хатын-кызларыбыз бәхетлеме?

▪ Татарстанда 2 млн. 1 мең 800 хатын-кыз яши, бу — гомуми халык санының 53,3 проценты.

▪ **Икътисадның барлык тармакларында эшләүче хатын-кызлар саны 51,5 процент, сәламәтлек сагында, физкультура һәм социаль тәэминатта — 83, мәгарифтә — 81, финанс-кредит өлкәсендә, иминлек һәм пенсия белән тәэмин итүдә — 79, сәүдә, җәмәгать туклануы, материаль-техник тәэминатта — 76, хуҗалыклар һәм дәүләт белән идарә итү органнарында 69 процент тәшкил итә.**

▪ Хатын-кызларның 72,9 проценты урта һәм махсус урта, 16,3 проценты — югары белемле. Республикада эшләүче 4252 фәнни хезмәткәрнең 437се фән кандидаты, 28е — докторлар.

▪ **Рәсми теркәлгән 11800 хатын-кыз эшсезләр армиясенең 84 процентын тәшкил итә.**

▪ Хатын-кызларның 14,8 проценты сәламәтлек өчен зарарлы тармакларда эшли, 0,4 проценты авыр физик хезмәт башкара.

▪ **Хатын-кызлар арасында җинаятьчелек узган елда 12,3 процент тәшкил итте. Бу 1993 елдагыга караганда 3 процентка артык.**

▪ Балалар ясле һәм бакча белән 58 процентка гына тәэмин ителгән.

«Киңәш»не кесәңә сал

Чаллы шәһәрендә «Киңәш» гәзитенең беренче саны басылып чыкты. Исеменнән үк күренгәнчә, «Киңәш» тормыш-көнкүрештә файда бирерлек киңәшләр бирә. Юрист һәм табиб киңәшләре, белгечләр аңлатмасы... Пенсионерларга, сугыш һәм хезмәт ветераннарына, гарипләргә, балаларга, студент яшьләргә, аспирантларга, мәктәп укучыларына хөкүмәт пособиеләре турында аңлатма, төрле четерекле сорауларга җаваплар — тәүге санында «Киңәш» әнә шуңа төп игътибарны юнәлтә. Үз тиңнәрен, үз бәхетләрен эзләүче кешеләрнең белдерүләре белән «Димче» рубрикасы таныштырып барачак. Сорауларыгыз булса, гәзиткә мөрәҗәгать итегез. Сезгә юристлар, табиблар, остабикәләр, гомумән, үз эшендә һәм шөгылендә бай тәҗрибә туплаган кешеләр, белгечләр җавап бирәчәк.

Хат язу өчен адрес: 423805, Чаллы шәһәре, Х.Туфан проспекты, 23, а/я 53, «Киңәш» гәзите редакциясе.

КАЗАН КИБЕРНЕТИКА МӘКТӘБЕНӘ 35 ЕЛ

Компьютер татарча сөйләшә

Җиргә автомат җиһазлар, роботлар һәм компьютер заманы килде. Моннан берничә дистә ел элек ялган фән дип аталган кибернетикадан башка хәзер тормышны күз алдына да китерүе кыен. Әйе, фән-техника гаҗәеп тиз тәрәккый итә. Киләчәктә мәңгелек двигатель, вакыт машинасы ясау мөмкинлеге дә бар икән кешелек дөньясының. Кичә без фантастика дип санаган нәрсәләр бүген чынга аша бара. Фәннең төрле өлкәләрендә эшләүче галимнәр генә түгел, инженерлар, табиблар, студентлар һәм хәтта мәктәп балалары да компьютер белән эшлиләр. Без көн дә укый торган гәзит-журналлар һәм китапларга кадәр компьютер ярдәмендә эшләнәләр. Дөрес, без компьютерга әле күптән түгел генә күчә башладык. Америка, Япония, Англия кебек алга киткән илләрдә һәр мәктәп укучысының өстәлендә шәхси компьютеры торган бер вакытта җөмһүриятебездә бер компьютеры булмаган мәктәпләр дә шактый. Шулай туры килде инде, мәктәпләрне компьютерлаштыру мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән күтәрелгән бер заманда, илдә коточкыч инфляция, хәерчелек башланды. Икешәр-өчәр ай хезмәт хакы ала алмаган халык тамак турында уйласынмы, әллә ничәмә-ничә миллион сумлык компьютер алсынмы? Ярый, бусы кереш сүз генә булды. Кибернетика турында иде бит сүзем.

Быел Казан кибернетика мәктәбе үзенең 35 еллыгын билгеләп үтә. Әйе, гаҗәпләнмәгез, әлеге фәнне үстерүдә Казан дәүләт университеты галимнәре дә гаять зур өлеш керттеләр. 1960 елда университет каршындагы механика-математика фәнни-тикшеренү институтында оешкан кибернетика бүлегенең тарихы шактый кызыклы һәм гыйбрәтле.

1957 елда КДУның алгебра кафедрасы каршындагы математик анализ тәҗрибәханәсен җитәкләүче яшь галим Рәис Бохараев Мәскәү дәүләт университетында «Стрела» электрон-хисаплау машинасында программалар булдыру серләрен өйрәнә. Анда ул Неглинский урамындагы бибколлектордан Гильберт китапларын, Аккерманның «Математик мантыйк нигезләре» дигән китабын сатып ала. Казанга кайткач, яшь галим университетта математик мантыйк буенча лекцияләр укый башлый. Шулай итеп, әлеге уку йортында акрынлап хисаплау математикасы һәм кибернетика факультеты барлыкка килә. Сүз уңаеннан шуны искәртеп узарга кирәк, кибернетика өлкәсендә иң зур белгечләрдән саналган Р.Нигъмәтуллин, Н.Замов, В.Шарогонов, М.Арсланов кебек дистәләгән галимнәр — Рәис ага Бохараев лекцияләрен тыңлаган кешеләр. 1962 елдан бирле университетның алгебра кафедрасы һәм фәнни-тикшеренү институтының кибернетика бүлеге нигездә ихтималлык автоматларын өйрәнү белән шөгыльләнә. Ошбу өлкәдә тикшеренүләр алып бару нәтиҗәсендә Рәис Бохараев физика-математика фәннәре, фундаменталь тәгълимат, техник фәннәр, электрон машиналарның махсус сыйныфын конструкторлау тәгълиматы буенча ике докторлык диссертациясе яклый. Ихтималлык автоматлары теориясенә нигезләнә торган бу тәгълимат ярдәмендә әр-яңа сыйфатлы электрон машиналар ясарга мөмкин булды. Аларны, электрон-хисаплау машиналарыннан аермалы буларак, электрон модельләштерү машиналары дип атадылар. Мондый җиһазлар мәсьәләне хисаплау рәвешендә түгел, ә модельләштерү юлы белән чишәләр. Хәер, бу төр электрон җиһазның үзенчәлекләре турында сөйли башласаң, гади укучы аны аңлап та бетерә алмас. Шуңлыктан, мин аның искиткеч зур интеллектуаль мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле булуы турында гына әйтеп узуны мәгъкуль күрәм.

Өч дистә елдан артык вакыт эчендә фәнни-тикшеренү институты 12 монография чыгарды, 24 фәнни хезмәтләр мәҗмугасы бастырды. Матбугатта дөнья күргән фәнни хезмәтләрнең саны исә 500дән артып китә. Ул гына да түгел, фәнни-тикшеренү институты сигез тапкыр бөтенсоюз мәктәп-семинарлары, өч бөтенсоюз һәм ике халыкара конференция үткәрде. Галимнәр 15 кандидатлык һәм 5 докторлык диссертациясе якладылар.

1968 елдан башлап, СССР таркалганчыга кадәр кибернетика кафедрасының СССР Фәннәр академиясе каршындагы кибернетика буенча фәнни шура подкомиссиясе кысаларында әлеге өлкәдә алып барылган тикшеренүләр оештыруы да Казан кибернетика мәктәбенең ихтималлык автоматлары тәгълиматы өлкәсендә Союз күләмендә нинди зур абруйга ия булуы турында сөйли.

1985 елда дәүләт комиссиясе өчен универсаль ихтималлык процессоры проекты турында нотык әзерләгәндә, совет ихтималлык автоматлары тәгълиматы мәктәбенең хәлен ачыклау өчен кайбер саннарга мөрәҗәгать итәргә туры килде. Һәм ул саннар бөтен дөньяны шаккатырды. Соңгы биш ел эчендә ошбу өлкәдә без уйлап табучылык буенча АКШ, Япония, Алмания һәм Франция кебек алга киткән илләрне биш тапкырга узып киткәнбез икән. Хәзер исә дөньялар үзгәрде. Заманы шактый болгавыр булса да, ихтималлык автоматлары тәгълиматы зур адымнар белән алга бара. Күптән түгел генә Р.Бохараевның «Ихтималлык автоматлары тәгълиматы нигезләре» дигән китабы Алманиядә немец теленә тәрҗемә ителде. Ул инде егерме елдан артык халыкара ФЦТ (компьютер белән хисаплау нигезләре) конференцияләре сериясенең даими эшләп килүче оештыру комитетында Русия кибернетика гыйлеменең бердәнбер вәкиле булып тора. Оештыру комитеты, тупланган тәҗрибәгә нигезләнеп, быел ФЦТ-97 конференциясен тагын бер кат Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Фәннәр академиясе базасында үткәрү турында тәкъдим кертте. Профессор Рәис Бохараев — элекке Советлар Союзының гына түгел, чит илләрдәге фәнни үрнәкләрдә дә ихтималлык автоматлары тәгълиматы буенча лекцияләр укыган абруйлы галим.

Ошбу мәкаләдә Казан кибернетикләры тарафыннан башкарылган олуг эшләр турында сөйләп бетерү мөмкин түгел. Шул сәбәпле, аларның Татарстан җөмһүриятен компьютерлаштыру өлкәсендә майтарган гамәлләрен яктырту белән генә чикләнү дөресрәк булыр, минемчә.

Кибернетика кафедрасы хезмәткәрләре Җ.Сөләйманов, Р.Һадиев, А.Еникеев, Рәис ага Бохараев җитәкчелегендә — «Компьютерлаштыру-90» дәүләт инновация программалары системасын әзерләү, Татарстанны компьютерлаштыруның программаларын (мәсәлән, җинаятьчелеккә каршы көрәш һәм татар телен дәүләт теле буларак тормышка ашыру программалары) хәл итүгә күп көч куйдылар. Әлеге ике программа да хәзер дәүләт тарафыннан акча белән тәэмин ителә.

1992 елда кафедра каршында Казан дәүләт университетының һәм Татарстан Фәннәр академиясенең ясалма интеллект мәсьәләләре буенча фәнни-тикшеренү тәҗрибәханәсе булдырылды. Тәҗрибәханә ике ел эчендә республикабыз өчен гаять мөһим булган мәсьәләне — компьютерларны «татарлаштыру» максатында техник системалар программалары өчен стандартлар әзерләү, ЭВМ белән татар телендә эшли торган белгечләр өчен автоматлаштырылган эш урыннары булдыру, шулай ук республикадагы компьютер челтәрен «татарлаштыру» кебек эшләрне башкарып чыга алдылар.

1993—1995 елларда тәҗрибәханә татар теле өчен компьютер лингвистикасын хәзерләү мәсьәләләре буенча өч фәнни хезмәт мәҗмугасын бастырып чыгарды. Ә 1994 елда исә компьютерлы технологияләргә татар телен кертү программаларына багышланган семинар-тәкъдим үткәрде. Болар барысы да киләчәктә татар теленең, тарихының һәм мәдәниятебезнең автоматлаштырылган машина фондына (Татарстанның машиналы энциклопедиясе) нигез салырга мөмкинлек бирәчәк.

Сүз соңында Рәис ага Бохараевка һәм аның хезмәттәшләренә зур уңышлар теләп калабыз. Татар кибернетикларының татар халкына хезмәт итүдә куйган тырышлыклары өчен киләчәк буыннар рәхмәт әйтер әле!

Заһид МӘХМҮДИ,
махсус хәбәрчебез.

ХӘТЕР КАЙТАВАЗЫ

Кыям МИҢЛЕБАЕВ

Авылымны уйлап уйга калсам...

(Нәсер)

(Ахыры. Башы 21—22 нче саннарда).

Моңарчы әле карт-корының оланнары тәрбиясенә калуына артык исем китми иде Ата-анага карата аеруча мәрхәмәтле-шәфкатьле булу гадәти бер нәрсә булып тоела иде Бу юлы күземә иң нык ташланганы аеруча нык сөендергәне — яшьләрнең ата-ананы тәрбия кылуга чынлап торып алынуларын күрү, үзләре өчен изге бурыч итеп санауларына инану булды Уйлана торгач, мондый гадәтнең канга сеңгәнен, безнең халыкта бу вазифаны үтәү борын-борыннан килгәнен, гаять көчле икәнен төгаенли алдым бугай Замана шаукымына иярмичә, авырлыкларга бирешмичә, яшьләр әлеге изге гадәтне киләчәктә дә дәвам итсен иде!

Кайчак берәр танышыңның 90 яшьлек әнисе әле дә исән икәнен ишетсәң дә нинди бәхетле кеше — тәмам олыгаеп беткәч тә, «Улым! Балам!» дип эндәшердәй кешесе бар, дип сокланып куясың. Шунда әңи исән чаклар, үзем туган көнне аңа, менә бүген төпчегең туган көн инде, дип чәчәк бәйләме алып кайтулар яки илтеп бирүләр.искә төшә Хәзер инде зыярәт кылырга гына кала.

Ата-бабага зыярәт кылу гадәте — безгә борын-борыннан килгән ихлас матур изге гореф-гадәтләрнең берседер Бу юлы да бабайларга зыярәт кылу нияте белән кыр зиратына сугылдык. Анда-санда гөрләп куак үскән киң вә иркен иске зиратыбыз инде, югыйсә Әмма аның капкасын ачып кергән кешенең йөрәге әрнемичә калмый торгандыр Җөмһүриятебезнең күп кенә авылларында борынгыдан калган зиратларны ауган-түнгән, җиргә иңгән кабер ташлары бизи Шуларга карап галимнәребез Болгар дәверенең сәхифәләрен ачалар, бүген исәннәргә борынгы бабаларыбызның васыятьләрен ирештерәләр Әмма безнең бу зиратыбыз искелегән-борынгылыгын бары тик халык күңелендә генә саклаган Ташлар да, алардагы язулар да юкка чыккан. Пенән арасындагы беленер-беленмәс кенә булып калган түмгәкләргә карап, кайда кемнең әбисе яки бабасы ятканын ачыклау елдан-ел кыенлаша бара. Сантыйлар тарафыннан мескенлеккә дучар ителгән каберстан.

Болгарда бабаларыбыз ничәмә-ничә гасырдан бирле яткан мазараның зур-зур ташларын кубарып алып, чиркәүгә нигез салып калдырган булганнар Нәкъ шундый ук вәхшилекне районда утыручы түрәләр дә «егетләнеп» эшләп ташлаганнар. Дөресрәге, авылдашларым кулы белән эшләгәннәр Ләгънәт үзләренә!

Сугыш башланган елны кар яман күп яуды. Кырык икенең язында ташулар зәһәр булды Авылыбыздагы инеш аркылы 30 нчы елларның уртасында зурдан кубып хәйран биек һәм дә күркәм итеп салынган күперебез хәтәр дә нык ябырылган калын бозларга каршылык күрсәтә алмады — чытырдады. сыкранды ыңгыраштьы да, халыкны зар елатып. барчабызның күз алдында җимерелде, бүрәнәләре боды̆ндагы мунчалар белән бергә, берәм-берәм суга акты

Зур күпернең янына ук җыйнак кына итеп, кечкенәрәк күпер салып куйдылар Буденный районы эчендә йөргән машина һәм арба тәгәрмәчләре күпергә төшә торган юлны шомартып, тәмам беләүгә әйләндереп бетерә иде Коры чакны шулаен шулай да бит — көз җитеп, яңгырлар ныгытып яварга тотынгач үзле кара балчык бөтенләй изрәп төшә дә, ни җәяүлегә, ни атлыга юл әсәре калмый

Дәһшәтле сугыш еллары Колхозның җыеп алган икмәген актык бөртегенә хәтле элеваторга төяп озатырга кирәк. Яңгырлар башланды Юл юк Районга хәбәр итәләр Тегендә утыручы түрәләр Казан алдында сынатмаска тырышалар Ихтимал броньнарыннан колак кагу куркынычы да аларны җитезрәк булырга әтәргәндер һәм алар Кече Чынлы инеше аркылы салынган күпер юлына таш түшәтергә карар кылалар — авылдашларымны елата-елата кабер ташларын йөзәр ел яткан урыннарыннан кубарып алырга, күтәреп арбага салырга, аннары аларны инеш буена ташып, ләпелдәвек балчык эченә түшәргә мәҗбүр итәләр

Бүгенге көндә печән эчендәге түмгәкләрнең кайсысы кемнең якыны икәнен әйтә алучылар, ай-һай, бар микән безнең авылда! Бу хәтле мәсхәрәләүгә 50 ел буена Ходай ничек түзеп торгандыр?!

Әһә, койма буенда, капка янында ук яңа каберләр пәйда булган икән Ташлар да матур гына. Әмма аларның язулары — нәкъ менә Казан зиратларындагы төсле. урысча «Фәлән Фәләнович Фәләнов» дип язылган

Ярый инде, цыкылдап торган татар авылындагы кибетнең маңгаена «Промышленные товары» дип язып куйганны күргәч

— һе-һе. шәһәрдәгечә, «Промтовары» гына түгел, тәмам җиренә җиткереп. урыс аңларлык итеп язганнар! Сыер дуласа, аттан уза икән шул, — дип, авыз ерып узасың.

Цеп-ци татар авылының исеме-аты каян килеп чыкканын фараз кылып маташучы Хода бәндәсенең, ул урысның «целина» сүзеннән килеп чыккан булырга тиеш, дигән «тарихи мәгълүматын» укыгач

— Урыслашу Цынлыга да килеп җиткән икән — дип уфтанып куясың.

Ана теленең сафлыгын саклаучы мәктәп диварында «Ибраһимова» урынына «Ибрагимова» дип язганны күргәч һәм фамилиянең паспорттагыча язылуын дәлил итеп китергәнне ишеткәч ирексездән уйга каласың.

Нишләп әле җөмһүриятебездә һәр ике тел тигез дип игълан ителгәннән соң да исем-фамилияләр фәкать бер телдә генә языла? Нишләп әле чувашлар белән мишәрләр күпчелекне тәшкил иткән районда татарча язуны гамәлләштермәскә? Нишләп әле кабер ташларына вата җимерә булса да, тырышып-тырышып урысча язып маташабыз? Әлеге чир шәһәрдән йокты микәнни соң? Югыйсә бит инде шәһәр җирендә вафат булсаң да, авылда җан тәслим кылсаң да — сират күперен кичкәндә һичбер мөэмин-мөселманнан паспорт сорамыйлар лабаса

Ана теленең бөтен матурлыгын кадерен-кыйммәтен белеп яшәү беребезгә дә зыян итмәс иде Ләкин моны эштә генә яисә өйдә генә эшләү дөрес түгел Һәр көненнең 24 сәгатендә, бөтен гомереңнең һәр мизгелендә бөтен телләрдән дә газизрәк һәм якынрак ана телен исеңдә тоту фарыз

Җөмһүриятебездә ике телнең дә тигез дәрәҗәдә йөрүенә һәм тигез хокуклы булуына без фәкать һәммәбез бердәм булып әрмый-гыйлмый эш алып барган очракта гына ирешә алырбыз Мәсәлән әле күптән түгел генә безнең беренче Президентыбыз турында матур гына китап чыкты Әмма ул кызганычка, фәкать урыс телендә генә дөнья күрде Аны яһүд яки урыс язса, бернинди киная ташларлык булмас иде Юк бит авторларның икесе дә үзебезнең егетләр! Әйтик менә Балтыйк буе мәмләкәтләренең кайсысында мондый хәлгә ләббәйкә дип торырлар икән? Юк шул менә, бүтән бер генә илдә дә ана телен читләтеп үтеп икенче бер телдә хәтта әле «старший брат» телендә дә китап язмыйлар Ошбу китап бер үк вакытта ана телебездә дә басылып чыккан тәкъдирдә ичмасам җөмһүриятебезнең чыннан да ике телле икәнлеген авыз тутырып әйтергә җайлырак буласы иде

Ә бит моны башкарып чыгуы кыен түгел иде урысча язылган кулъязманың шактый өлешен без фәкыйрегез татар теленә тәрҗемә итеп «Татарстан» журналы редакциясенә быелтыр ук тапшырды Бу тәрҗемә ул журналда гына түгел, кайбер башка гәзитләрдә дә өлешчә дөнья күрде

Районны урап кайтырга колхоз рәисе үзебезгә «УАЗ» машинасы бирде Шоферлар икәү берсе — хуҗалыкның механигы Фәрит икенчесе — үзебезнең элеккеге күрше Аяздин әбзәйнең улы Радик Энесе Мидхәт өеннән Зөфәр абзыйны алдык та киттек әр-яңа асфальт юлдан җилдертеп Җан рәхәте!

Иң әүвәл таныш-белешләр янына «Яңа юл» гәзите редакциясенә сугылдык Баш мөхәррир Ядкәр әфәнде Айнуллов ачык чырай белән каршылады үзебезне Хәл-әхвәл белешкәннән соң баш мөхәррир хакимият башлыгына хәбәр бирде һәм безне шунда алып китте

Рәхимҗан әфәнде Хәйруллин кабинетында шактый утырылды Әңгәмәдән хәйран канәгатьләнеп сәфәребезне дәвам итәргә ниятләдек Инде безгә элек редакциянең сәркатибе булган бүгенге көндә мәктәптә эшләгән Рафаил Субаев та кушылды Иске танышның, күңелемә хуш килгән каләмдәшнең үз яныбызда булуы юлны тагын да кыскартыбрак җибәрде

Кайчандыр улыс булган Абделнәфи бабам 30-35 ел галава булып эшләгән Яңа Кәкерлене һәм Алимә әбиемнең (җаны оҗмахта булсын) туган авылы Иске Кәкерлене сөйләгәндә әниемнең бигрәк тә дәртләнеп китүе әле дә хәтеремдә Фәүзия апам белән без инде тын да алмыйча тыңлый торган идек Шул авылларны гомерем буе күрәселәрем килеп яшәдем

Гәрчә карт-корыны хәзрәтләрне күреп сөйләшсәк тә узган гасырда булып узган вакыйгаларны да, шунда яшәгән кешеләрне дә белүчеләр калмаганына тәмам инандык Авыллары искиткеч матур әмма ләкин бабамнарның эзен чирәм каплаган миңа күрү насыйп булмады

Бөтен сәфәребездә берденбер маҗара кызыклы тоелды Анысын да безнең шофер егетләребез уйлап чыгарды Гаҗәеп зур Яңа Кәкерле авылы белән азмы-күпме танышканнан соң һәм дә үз төбәген хәйран шәп өйрәнгән Рафаилнең сөйләгәннәрен тыңлаганнан соң ниятебез Иске Кәкерлене дә күрү иде Авыллар янәшә үк диярлек аралары 2-3 чакрымнан да артык түгелдер Әмма берсеннән икенчесе әнә генә күренеп торган ул авылга барып җитүләре ай-һай кыенга туры килде!

Шәһәр кешеләре машинада берни абайламый утырганда, бу якларны үз ихатасыдай белүче Рафаил һич көтмәгәндә

— Без кая барабыз соң? Моннан уза алмабыз бит Иске Кәкерлегә — дип куймасынмы

Шофер егетләр дәшмиләр Тик бераздан гына

— Хәзер без район үзәгенә кайтыйк әле — дигәннәре ишетелде

Мондый җаваптан соң инде без дә мәрткә киткәндәй тыныч кына утыра алмадык Мин хәтта җәяүләп тәпи-тәпи булса да ул авылны күрми китмәячәгемне белдердем Егетләрнең дәлиле бераз соңрак мәгълүм булды Фәрит дигән авылдашыбыз нәкъ менә минем бабам юлын кабатлаган — Иске Кәкерле чибәренә өйләнеп җибәргән икән ләбаса! Карчыгын алып сишәмбе көнне бабаларына кунакка барасылары икән Вәгъдәләшкән-сөйләшкән булгач аңа бүген дүшәмбе көнне күренеп йөрү бер дә мач килми шуңа ул төртәне кире якка борган икән

Карт кешене тәпи-тәпи йөртәселәре килмичә генә сәфәрне дәвам иттерергә күнде егетләребез Әмма чын күңелдән теләмәгәч мәзәк кенә бер хәлгә дучар булдык

Олы юлга турыдан ярдырып чыгу нияте белән Фәритебез машинаны кискен генә бордырып та алды — без колхозның абзар-кураларына барып та терәлдек Аннан чыгу әмәле юклыгы ачыклангач якында гына такыр юлны күреп Фәритебез машинаны тагын да кискенрәк бордырып алуы булды — су тулы чокырга төштек тә баттык

Этеп тә карыйбыз машинаны тартып та карыйбыз — тик берни майтара алмыйбыз Тәгәрмәчтән әйләнә-тирәгә очкан былчырак безнең өс-башыбызны да танымаслык хәлгә төшерде Шунысы кызык, чокырдан болай гына чыгу әмәле юклыгын аңлагач та, егетләребезнең кәефенә кечтеки генә дә зыян килмәде Радик һич кабаланмый-нитми генә идарә ягына юл тотты Күз ачып йомганчы алагаем зур әрҗәле машинага утырып килеп тә җитте Шыксыз кыяфәткә кереп. борыны белән суга чумган машинабыз әллә ни кыстатмады, чирәмгә чыгып басты

Кояз егетләрнең өс-башлары пычранып беткән чагында да машиналары чиста вә пөхтә булыр Без җүнләп исебезгә килергә дә өлгермәдек, уңган-булган шоферларыбыз «УАЗ»икларын юып-сөртеп тә куйдылар Хәер үзләренең өс-башлары да алай ук зарланырлык түгел иде Без генә ул, шәһәр кешеләре акны күрдек — абындык, дигәндәй

Өч төрле нәрсәгә сөендем туган илкәйдә Беренчесә — авылдашларым бүген дә ачык чырайлы шат күңелле Көнкүреш хәлләре көннән-көн яхшыра бара. Яшьләр ягага китсәләр дә карт-корыны ташламыйлар

Икенчесе — язгы чәчүләрдән арынып бүген-иртәгә печәнгә төшәбез, дип торганда да, авылдашларым гүя мәрткә киткәндәй тынычланып калганда да. колхоз идарәсендә яшәү дәвам итә Дәртләнеп-гөрләп яши һәм эшли идарә-штаб Сабантуй батырыдай таза гәүдәле рәис Барис Гафуров беркем белән дә ләчтит сатып тормый — эшне кызу тота ут уйната

— Газ кертәбез авылга, — ди ул Шундук хыялын да әйтеп ташлый — Газ кертә алсам әгәр яшьләрне авылда саклап калам бит мин! — ди

Авылдагы хәлләрне шәһәрдә сөйләгән идем дөнья күргән кешеләр

— Бу чаклы авыр заманнарда утын белән күмер хакы шулай үсеп торганда, авыл өйләрен газ белән тәэмин итә алса, һәйкәл куярга тиешле андый кешегә! — диләр

Сөенечләремнең өченчесе әлбәттә укучылар белән аралашу мәктәп булды Андагы мохитне күргәч җилкәмнән 50-60 елны шудырып төшерәселәрем ваемсыз шушы бала-чага белән бергә буласыларым уйный-шаярасыларым килде

5 нче сыйныфта үткәрелгән әдәбият дәресенә керергә рөхсәт алдым Укытучылары Җәүһәрия ханым Шәйхаттарова татар әдәбиятын яхшы белә дип әйтү генә аз булыр — ул аны чын күңелдән ярата Активлык та, пассивлык та — гомерлек булучан Миңа калса Җәүһәрия ханым үзе актив җан буларак, бу асыл сыйфатны укучыларында да тәрбияләргә омтыла Ә инде ул биргән белем укучылары тормышында маяк булыр аның дәресендә шушы яшьтән үзләштергән сингармонизм законы татар теленең нәфислеген музыкальлеген аңларга, ана теленә гомер буе хөрмәт сакларга ярдәм итәр

1 нче сыйныфтагы уку дәресен исә әкияткә хыялый бер дөньяга тиңләр идем Шәһәр вә авыл мәктәпләрендә ничәмә-ничә дәрескә кергәнем бар шагыйрь «Җирне әз-мәз тырмалап чәчкән идем урган идем» дигәндәй мәктәптә дә университетта да укытканым булды тик инде авылдашым Гөлсирә Җәмдиһанова дәресе шикелле оста оештырылган кызыклы вә гыйбрәтле дәресне моңарчы күргәнем ишеткәнем булмады Гөлсирә ханым гүя дәрес тә үткәрми гүя үзенең йөрәк парәләре белән күңелле бер әңгәмә уен оештырып җибәрә дә хәйран оста дирижерлык итә Юк, ул үзенең укучыларына белем генә бирми шушы сабыйларны ул итагатьле-миһербанлы кеше булырга өйрәтә — бу исә һәммә нәрсәдән дә кыйммәтрәк

Өлкән сыйныфларда укучыларны зур тәнәфес вакытында күрдем Һәммәсенең өсте-башы пөхтә кыяфәтләре матур вә күркәм йөзләрендә нур Кыз балаларның зифалыгы-сылулыгы үсмер егетләрнең көчле-таза булуы һәркемнең күңелен җәлеп итәрлек Уңган-булган ата-ана тәрбиясендә сабый чактан эшләп үскән әлеге яшьләр һичшиксез газиз авылыбыз тормышына ямь өстәрләр нур сибәрләр шәфкатьле-мәрхәмәтле шәхесләр булып җитләгерләр

Безнең авылда кечкенәдән үк шигырь яисә әкият чыгармаган төрле уеннарга катнашмаган җырлар җырламаган кеше сирәктер Әле бүген мәктәптә белем алучы сабыйлар һәм яшүсмерләр арасыннан олуг талант ияләре — җырчылар вә артистлар композиторлар вә рәссамнар шагыйрьләр вә әдипләр чыксын иде! Иҗат кешеләре Җәүһәрия һәм Гөлсирә шикелле укытучылар белән бергә-бергә авыл халкына барча милләттәшләребезгә белем бирерләр рухи байлык өләшерләр иде

Киләчәк сезнең кулда. халыкның бар ышанычы — сездә. ул ышанычны акларсыз дип өметләнәм. авылдаш газизләрем!

Кече Чынлы — Чүпрәле — Казан.

Хокукый дәүләт төзү, кеше хокукларын яклау хакында фикер йөрткән һәм шул юнәлештә эш алып барган бер вакытта, прокурордан әдәбият-сәнгать турында сорау кайберәүләргә аңлашылып та җитмәс, бәлки. Ишермим, җитәкчеләребезнең вакыты шулкадәр кысан, прокурорның да мәдәният турында сөйләшергә ризалык бирүе түгел, хәтта кабул итәчәгенә дә өмет аз иде. Әңгәмәдәшем — Татарстан Республикасы прокуроры Сәйфихан Хәбибулла улы НАФИЕВ шигемне тиз таратты.

Сәйфихан НАФИЕВ:

БЕЗ ҺӘРКАЙСЫБЫЗ ТОРМЫШ ДИГӘН ТАМАША КАҺАРМАНЫ

Сүзебез ничектер тәрбия, яшәү мохитебездән башланып китте. Мин әйтә куйдым: «Сәйфихан әфәнде, табигатегез буенча Сез һич тә кырыс кешегә охшамагансыз. Гадәттә, прокуратурада, судта, милициядә эшләүчеләрне халык шундыйрак итеп күзаллый».

— Кешенең холык-фигыле яшьтән үк формалашуы һәркайсыбызга мәгълүмдер. Безне ата-ана, гаилә, мәктәп, коллектив тәрбияли, дибез. Безгә тирә-юньдәгеләрнең дә тәэсире зур. Хәтта ул кешенең киләчәк юлын билгеләгәндә дә хәлиткеч роль уйнарга мөмкин. Җырчы, музыкант булмыйча, үземнең кеше хокукларын яклау органнарына — прокуратурага эшкә килүемне дә шуның белән аңлатыр идем. Мәктәптә укыган елларымда бер кешене бер дә юкка рәнҗеттеләр. Аңа участок инспекторы да ярдәм кулы суза алмады. Шул чагында, мин хокук саклаучы булырга тиешмен, дигән фикерне күңелемә беркетеп куйган идем.

— Мәктәп, гаилә тәрбиясе дә эзсез югалмагандыр бит?

— Ул чактагы мәктәп тәрбиясе минем үземә бик үзенчәлекле булып тоела. Укытучыларның үз эшенә, фәнгә бирелгәнлеге безне белем серләренә тирәнрәк төшенергә этәрә иде. Укытучыбыз Фәтхи абый Әхмәровның татар теле һәм әдәбияты дәресләрен үткәргән чаклары әле дә булса сагындыра. Габдулла Тукай, Һади Такташ иҗатына якынлык укытучыдан башланган да инде. Ә бер шагыйрьгә, язучыга булган кызыксыну икенчеләрен белергә ярдәм итә. Без укыган елларда мәктәптә язучылар белән очрашулар да еш була иде. Якташ әдипләребез Шәрәф Мөдәррис, Зәки Нури һәм аларның иҗатлары белән дә шулай таныштык. Әдип сүзенең бәһасен без шулай яшьли белеп үстек. Мәктәп тәрбиясе минем тормышта аерым урын алып тора.

— Кешене җыр, рәсем сәнгате дә җәлеп итә. Сездә андый һәвәслек бар идеме?

— Безнең җидееллык мәктәптә хәзергедәй баян, фортепьяно кебек уен кораллары турында хыялланырга да юк иде әле. Укытучы апа җырлап күрсәтә дә, аннары без аңа кушыла идек. Җырларны бик яратам. Элегрәк, аеруча кышкы айларда, атнага бер мәртәбә диярлек төрле тамашалар булып тора иде. Шәһәрнекеләрме, район үзеге, авылыбыз үзешчәннәре дисеңме — җыр-моңы, спектакльләре белән куандырып тордылар. 200 урынлы клубыбыз шыгрым тулы була иде.

— Сәйфихан әфәнде, әйтегез әле, аеруча кайсы җырчыларыбызны тыңларга яратасыз?

— Авыл җиренә мәшһүр җырчыларыбызның моңы иң элек радио аша, аннары пластинкаларда килеп ирешә бит инде. Без өйдә Гөлсем апа Сөләйманова башкарган җырларны йотылып тыңлый идек. Шуның янына Әлфия Афзалова моңнары килеп кушыла иде. Ә Илһам абый башкаруындагы җырлар гомерем буе озата бара кебек. «Син сазыңны уйнадың», «Карурман» көйләрен тыңлаганда, уйларым белән әллә кайлардан урап кайтам. Аларны тыңлаган саен тыңлыйсы килә.

— Шушындый сүзләрдән соң, гаиләгез дә җыр-моңга битараф түгелдер, дип уйлап куясың...

— Кызларым мәктәптә укыганда үзләре өчен генә булса да пианинода уйнарга өйрәнделәр. Хәзер олы кызымның балалары — оныкларым җыр-бию белән мавыга. Аннары без концерт, тамашаларга да йөрергә ярата идек. Хатыным да моңлы итеп җырлый иде. Хәзер вафат инде... Авыр туфрагы җиңел булсын...

— ...

— Вакыт табып булса да рәссамнарыбызның күргәзмәләрендә, спектакльләрдә, концертларда булырга тырышабыз. Күргәзмәдә чакта, пейзажларга карасам, үземне туган якларыма кайткандай хис итәм. Ул минем бөтен арыганнарымны юып алгандай итә. Портретларда шул кешенең уй-кичерешләре белән очрашкандай булам, аның холык-фигылен ачарга тырышам. Портретны ясаган рәссам белән очрашканда, уй-фикерләремне аңарга да ирештерәм. Әгәр уйларыбыз тәңгәл килсә, күңелгә җылы булып китә. Безгә шатлык өлешүче, бәхетле мизгелләр бүләк итүче рәссамнарыбызга сокланам мин.

— Сезгә башкалар иҗатына гына сокланып яшәү хас димәс идем. Авыл сәхнәсендә спектакльләр уйнап йөргән чакларыгызны якташларыгыз әле дә булса хәтерли...

— Ихтимал. Сез хәрби хезмәттән соңгы елларны күздә тотып әйтәсездер. Элегрәк клублар бөтен авыл халкын үзенә тартып тора иде шул. Авыл яшьләре дә, үзешчәннәр дә актив иде. Мине дә шундый чараларга җәлеп иткәннәре хәтердә. Кызык, күңелле вакытлар иде ул.

— Спектакльдә нинди геройларны уйнарга ярата идегез?

— Төп геройлар һәм уңай персонажлар иде алар. Бала чактан ук начар гадәтләрне, тискәреләрне яратмадым...

— Кешедә тискәре сыйфатлар да булырга мөмкин ләбаса...

— Аңлыйм, адәм баласы фәрештә түгел. Читтән караганда, бәлки, миндә дә бардыр ул. Әмма яман гадәтләрдән котылырга кирәк. Шәхсән үзем начар гадәтләрдән тизрәк арынырга тырышам.

— Кешенең тискәре яклары сәхнәдә, кеше алдында, аеруча тиз күренә. Артистларыбызның нинди кыланышларын күңелегез белән кабул итә алмыйсыз? Ә кайсылары Сездә соклану уята?

— Сәхнә культурасы дигән төшенчә бар. Кайбер башкаручылар аны саклап җиткерми. Тамашачыны җәлеп итәм дип, нинди киемнәрдән генә чыкмыйлар алар. Аннары әсәрнең эчтәлеген тулаем биреп җиткерә алмаган башкаручыларны күңелем кабул итә алмый. Минем күңелемдә соклану уяткан артистларыбыз да күп. Шулар арасында Шәүкәт абый Биктимеров, Алсу Гайнуллина (авылдашым булганы өчен генә түгел), Ринат Таҗетдинов, Рузия Мотыйгуллина кебек артистларыбызга сокланмый мөмкин түгел.

— Спектакльләрдә уйнагансыз, театрларга да йөрим, дидегез. Анда чакта Сез нинди хисләр кичерәсез?

— Бу үзе олы бер сөйләшү булыр иде, мөгаен. Иң элек мин милли театрыбызның югары дәрәҗәдә булуын һәм шуның белән горурлануымны әйтеп узар идем. Бу шәхси бәя генә түгел. Төрле өлкәләрдән Казанга эш буенча килгән хезмәттәш-коллегаларымны еш кына Камал театрына алып барам. Анда урыс тамашачысына да тәрҗемә җайланмалары куелган. Спектакль барышында ук алар үзләренең соклануларын белдерәләр. Әсәрләрнең эчтәлеге, сәхнәләштерү, уйнау дәрәҗәсе аларны да нык җәлеп итә, алар аны югары бәяли. Аннары, дөрестән дә, театрның репертуары һәрдаим байый бара. Без яратып караган «Зәңгәр шәл», «Беренче театр», «Банкрот», «Дилефрүзгә дүрт кияү» спектакльләрен башка эчтәлектәге, әйтик, «Кишер басуы», «Идегәй» кебек үткәнебез, бүгенге хәлебез, киләчәгебез хакында безне тирәнтен уйландыра торганнары баета төшә. Мин ышанам, драматургларыбыз әле яңадан-яңа сәхнә әсәрләре белән куандырырлар. Аның өчен җим җитәрлек. Тормыш бит ул үзе спектакль. Тормышта һәркайсыбызга роль бүлеп бирелгән. Яхшы кешесе дә, яманы да, уңганы да, булдыксызы да, батыры да, куркагы да бар аның. Әмма яманнары, булдыксызлары, куркаклары һәм башка тискәре адәмнәре азрак булсын, яисә бөтенләй булмасын иде, диясе килә. Тамашалардан соң мин шулар хакында уйланам. Спектакльләр — ул безнең тормышның чагылышы. Язучы аны безнең уч төбенә китереп куя: кара, уйлан, нәтиҗә ясa, ди сыман.

— Сезнең өлкәдән дә әллә нинди әсәрләр иҗат итәргә мөмкин булыр иде.

— Әйткәнемчә, иҗат кешесе өчен җим җитәрлек. Укучыларыбыз язучы-юристлар Мәгъсүм Насыйбуллин, Зөфәр Фәтхетдинов әсәрләрен зур кызыксыну белән кабул иттеләр. Аларның дәвамчылары да булыр дип өметләнәм. Ләкин дөнья күрәчәк әсәрләр вакыйганы кәгазьгә гадәти төшерү генә булмасын иде. Әсәр кайбер йоклаган күңелләрне уятсын, кыек юлдан баручыларны уйландырсын, аларга туры сукмак күрсәтсен, авыр минутларында киңәшче, ярдәмче булсын ул.

— Сер түгел, иҗатчы үзе дә ярдәмгә мохтаҗ. Авторлык хокуклары һәрвакытта да сакланып бетми әле...

— Базар шартларында иҗат белән шөгыльләнү җиңел булмавын аңлыйм. Кыенлыктан чыгу юлын һәр иҗат иясе үзенчә тапканын да беләм. Авторлык хокукына килгәндә, аның сагында торучы законнар бар. Бу эшне җайга салучы, аны күзәтеп торучы оешма — ТАИС эшләп килә. Һәм соңгы чиктә, дөрестән дә, прокуратурага, судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әмма үземнең эшләү дәверендә бу уңайдан дәгъва белдерүчене хәтерләмим. Иҗат иясе үз хокукларының бозылуы турында беренче булып аваз салырга тиештер. Әйтик, әгәр дә җырчы үзе генә башкара торган әсәрләрнең башкалар тарафыннан җырлануын белә торып та, аларга дәгъва белдерми икән, мондый кешене киң күңелле дип әйтергә генә кала. Җырларны күпләп яздырып таратучыларга карата да үз мөнәсәбәтен беренче чиратта автор белдерергә тиеш. Әгәр юк икән, димәк, ул үз моңнарының халыкка барып җитүен өстенрәк күрә дигән сүз.

— Сәйфихан әфәнде, чыннан да, Сезнең алда әйткән фикерләрегез белән килешми мөмкин түгел. Читтән карап торсаң... нәкъ спектакльдәге кебек килеп чыга бит.

— Тормыштагы ролен кем ничек башкара бит әле?! Анысы да бар. Без исә һаман хәрәкәттә...

— Ярый, хезмәттә, иҗатта бәрәкәтле уңышлар теләп, әңгәмәне түгәрәклик. Шәхсән үзем өчен, мәчыннан да, йомшак күңелле, мәдәни җанлы кешене ачтым.

— Бу сүзләрегезгә өстәп шуны гына әйтер идем. Мин хезмәттәшләремә карата кырыс түгел, шулай да таләпчән, үз хезмәтен төгәл башкаруны, гадел һәм заманча карар чыгаруны таләп итүне кирәк дип саныйм һәм шул фикердә нык торам.

Әңгәмәне
Альберт САБИРОВ
үткәрде

ШАГЫЙРЬ НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

Разим ВӘЛИУЛЛИН

Зирәк акыл

Озак сузмыйк югалтканны кайтарганда,
Камыр булмыйк тимер эшең башкарганда,
Халкың өчен зур гамәлләр майтарганда
Гайярь булыйк, гайярь булыйк!

Чаян булып «чая дуслар» чаксалар да,
Дошман белән очрашсак та басмаларда,
Басмыйк өлә өзер торган чакмаларга —
Сабыр булыйк, сабыр булыйк!

Салган чакта бизмәннәргә язмышларны,
Алган чакта гаскәреңә Алыпларны,
Күтәргәндә көрәшләргә халыкларны
Гадел булыйк, гадел булыйк!

Гайярьлеккә юлдаш булсын зирәк акыл,
Гаделлеккә җитәр өчен кирәк акыл,
Иманлыга, гыйманлыга терәк акыл,
Аксакаллар булыйк!
Аксакаллар булыйк!!

Сабырлык сары алтынмы?

Сабырлыклар сары алтын,
Алтын, димәк, сабыр халкым!
Ләкин үзе генә бәлә,
Бары үзе аның хакын.

Шул алтынга алган язмыш...
Ә ул язмыш алтынмы соң?
Бакырларга вакланмыйча,
Бөтен булып калсынмы соң?

Тулып ташый тирән ярлар —
Ага алтын ташкыннары...
Без битараф, йоккан мәллә,
Җанга алтын салкыннары?

Нигә алтын хәсрәт белән
Бу җиһанны тутырырга?
Күпме мөмкин, хозурланып,
«Алтын» учлап утырырга?

Нигә алтын сабырлыклар,
Кулда тимер богау булгач?
Кирәкме соң тәти сыннар,
Алар алтын бозау булгач?

Борынгыдан килгән сүздер:
Сабырлыклар — сары алтын.
Милләт җанын ялкын алсын,
Алтын акыл салкын калсын!

Сату

«Омскида яшәүче бер ярлы хатын карынындагы сабыен 2 бүлмәле фатирга яки 4 мең долларга алмаштырырга мәҗбүр...»

(«Мегаполис экспресс»).

Тагын ниләр ишетербез микән,
Каралыктан күзләр бәйләнгән.
Доллар өчен илен, җанын сату —
Гадәтигә инде әйләнгән.

Гадәти хәл — вөҗдан белән сәүдә,
Иман белән, хәрби сер белән.
Акча диеп тәнен бирә бичә,
Яшәсә дә күркәм ир белән.

Хәзер бар да үтә — сатылалар:
Чәч тә, күз дә, башка әгъза да.
Гыйффәтлелек китә чүп бәягә,
Ялган акча, ялган назга да.

Фәкыйрьлекнең чиге булыр микән —
Теләнчеләр хәзер чат саен.
Горурлыкның шулай тапталуын
Күрергәме килдең, башкаем?!

Җан өшеткеч белдерүләр ява
Гәзитләрдән бөтен Рәсәйгә:
«Карынымдагы сабыемны бирәм —
Йә фатирга, йә мәй, йә чәйгә!»

Чиксез түбәнлеккә төшерелдә
Шакшы илдә Алла бәндәсе.
Бәгырь өртып, керә яралгыга
Өрәк — коммунизм шәүләсе.

Китәләр бөтенләйгә

Китә дә китә кешеләр,
Китәләр бөтенләйгә.
Җыр-моңнарга төренеп кала
Зәңгәр җитеннәр җәйдә.

Зәңгәр җитен түгел икән,
Бу — зәңгәр күзләр сере.
Җир! Җәсәд сиңа иңсә дә,
Җан мәңгелек, җан тере.

Мондый фараз алданумы,
Мистикамы, чынмы бу?
Авыр уйлар чолгап алса,
Юануга юлмы бу?!

Кеше китә. Дөнья кала.
Матур да, шәфкатьсез дә.
Бездән алдарак киткәннәр,
Нindirәк хәлләр сездә?

Ничек итеп каршыларсыз?
Китәсе бар бит әле.
Аһ, киек каз юлларыннан,
Гөлләр сибеп кулларымнан,
Үтәсе бар бит әле.

Кем уйлаган

Кочакларымын, үбәрмен дип,
Уйламаган да идем.
Һушсыз калдым хозурында
Акылдан шашам бүген.



Ул нәфис, исерткеч сының —
Тиңсез, алмаштырмаслык
Сөюеңнең тарту көче
Мәңге адаштырмаслык.

Кем уйлаган теләрмен дип,
Күрәргә, иркәләргә
Һаман-һаман түймамын дип,
Кичләр дә, иртәләр дә.

Сеңел, чумып яратудан,
Иңеп, оеп китә җан.
Сусыл иреннәр назлаудан
Туктамам дип уфтанам.

Уеннан уймак чыга ди,
Хан идем — хәзер колың!
Җиләнгә борынын төрткән
Ач.вә төкатьсез колын...

Ак толпарлар җигеп барам

Ардакладың-чөрдәкләдең
Йөрәгемнә канаттың.
Нигә сине бер күрүдә
Мәҗнүн булып яраттым?

Мәҗнүн булып яраттым да,
Бирелдем хисләремә.
Онытылдым. Бер ваемсыз
Иртәгә нишләрмен лә.

Бер күрүдә хуҗа булдың
Таңнарым-төшләремә.
И Раббым, аермасана
Тагын бер кичкә генә.

Тагын бер кичкә генә дә...
Гомерем буйларына!
Ак толпарлар җигеп барам
Бәхетем туйларына.

Ардакладың-чөрдәкләдең
Йөрәгемнә канаттың.
И Алиһәм, бер күрүдә
Ләйлә кебек яраттың.

Күзләреңдә моң күрдем

Рәссам дустыма

Нигә, дустым, моң бар күзләреңдә,
Нинди борчу синдә, нинди гамь?
Нигә әле болай күңелең боек,
Тирән уйга чумдың син тәмам?

Карашыңда халык күңеленең
Чагылышы инде, күрәсең.
Мәнсез сәясәттән изелә милләт,
Сыкрыйсыңдыр шуңа күрә син.

Әтьяларның төсе алмашына,
Төссезләнә яшәү мәгънәсе.
Чүпрәкләрнең хакы арткан саен,
Төшә бара Кеше бәясе.

Әйбер колы — меркантильләр үрчи,
Акчага бай — рухи ярлылар.
Бу гавамгә сәнгать кирәк түгел —
Комсызланып алтын ялыйлар.

Чынбарлыкны дөрес тасвирласак,
Безгә яный катыйль — бу чынлык.
Кайгыларга, сагышларга баттык,
Суыра бара котылгысызлык.

«Талант — милли байлык!» — диючe күп,
«Ипие бармы?» — дигән юк бугай.
Шуңа күрә сине якын итә,
Фәкыйрь-фокара, ярлы-ябагай.

Нигә, дустым, моң бар күзләреңдә,
Ниләр борчый синә, нинди гамь?
Милләт өчен сызланасың, бәлем,
Һәм «Ризык!» — дип, — бары бер тәгам».

ГУРИЙ ТАВЛИНГА 70 ЯШЬ

ЯШЬЛЕК ДУСТЫМА ЭНДӘШҮЕМ...

Җитмеш тирәсендә яшьлеккә дә бер кайтып килик әле. Хатирәләрнең иң кадерлесе, керсез аклары шул чордан калмыймыни?!

Безнең яшь аермабыз ике ел гына, гәрчә ел исәбе белән ул миннән өч елга олырак. Ул декабрь азагында туган, мин исә гыйнвар уртасында. Яшь чакта ике ел зур аерма. Гурий Тавлинны белә башлаганда ук ул миңа җиткән егет булып күренгән иде. Борынгы грекларча чибәр Гурийның «Син кем дә, мин кем!» дип кычкырып торган күзләре әле дә исемдә. Ул без яшәгән Югары авылга Түбән авылдан йөреп укый иде. Чиркәүле, урта мәктәпле Югары Баграж мәктәбе тирә-якта бердәнбер, аңа утызлап авылдан килеп укыйлар. Керәшеннәр, татарлар — кара-катыш. Кәзен, укучылар килеп тулгач, мәктәп кенә түгел, урам-тыкрыклар, клуб тирәләре гөж килеп тора иде. Чиркәүне клуб иттеләр. Укытучылар, өлкән класс укучылары бертуктаусыз спектакльләр куйлар. Концертлар, олимпиадалар булып кына тора иде бездә. Ишек алдында спорт мәйданы, футбол, волейбол ярышлары... Мәктәп түгәрәкләреннән җаның теләгәнне сайлап ал! Үз чемпионнары бар мәктәпнең, мәшһүр җырчылары, сәхнә осталары — артистлары да җитерлек. Күңелле, җанлы тормыш белән яши иде сугыш алды елларында Баграж мәктәбе. Атаклы балалар җитәрлек, ишле алар. Әмма безнең мәктәптә спорт уеннарында катнашмаган, гомумән, ыгы-зыгылардан читтәрәк йөргән тагын бер мәшһүр укучы бар иде! Гурий Тавлин — шагыйрь! Әдәбият түгәрәге гөрләп эшли, аның утырышлары бик җанлы үтә. Җитәкчебез — көндәлек матбугатта исеме күренә башлаган, Казан кадәр Казанда ике китап чыгарган Василий Багряшевский! Бераз таркау, оешып бетмәгән, әмма үтә риясыз кеше иде мәрхүм Василий Федорович Тарасов. Урыны җәннәттә булсын.

Гурийның мәктәп даны укытучыларныкыннан һич ким булмагандыр! Багряшевский — шагыйрь, ул олы кеше. Ә монда, әнә, яшь егет бәйгегә чыга. Күп укый. туктаусыз иҗат итә, шигырьләрен укып җибәрсә, без, утыз-кырык бала — әдәбият түгәрәгенә даими йөрүчеләр өнсез калабыз. Безнең борыннарга Пушкин, Тукай исе әле яңа керә башлаган, ә Гурий исә Надсон, Бальмонт шигырьләрен яттан сөйләп җибәрә. Шулар тәэсирендә булса кирәк, үзе дә урысча шигырьләр яза. (Миңа бүләк иткән урысча шигырьләре әле дә архивымда саклана).

Керәшен арасында кушаматсыз кеше булмый, аны Зөй, Баграж якларында «Мулла Гурие» дип беләләр. Багражларның дүртесендә дә чукындырылган татарлар яши. Без бөлекөй чакта Тугашлар тыкрыгы янында беренче агач чиркәү дә исән иде әле. Гурийның ерак бабалары мулла булганмы әллә? Төпченгәнем юк.

Бер заман Гурий миңа юка гына бер китап бирде. Сергей Есениннең фаҗигале вафатыннан соң чыгарылган, кайбер сәхифәләренең читләре кан белән каймаланган бу китап Баграж ягына ничек килеп җиткәндер дә, Гурий кулына нинди уравыч юллар үтеп кергәндер — белмим, хәтерләмим. Бер нәрсә исемдә: Есенин бакчасына мине Гурий җитәкләп алып керде.

Без нык ук якынлаштык дип әйтә алам. Әгәр якын сердәш булмасак, утыз җиденче ел фаҗигаләреннән соң, Ибраһимов, Тинчурин, Бурнаш китаплары кинәт юкка чыккач, Югары Баграж авылын бетереп, җәзаланган әдипләрнең китапларын эзләп йөрер идекмени? Телисә кемгә кермибез, юк, каян килгәндер безгә акыл, бик сайлап кына капкаларына кагабыз. Безнең авылда кулак мөһере сугылган хәлле, иң тырыш, иң эшлекле крестьяннарны сөргенгә кумаганнар. Керәшеннәр ул чорда бер-берсенә мәрхәмәтле була белгәннәр. Өйләрен алганнар, ихаталарына кагылмаганнар, хуҗаларын йә мунчага, йә келәт-амбарга күчергәннәр. Шундыйларга керәбез, «Сездә Галимҗан Ибраһимов китаплары калмаганмы?» дип сорашып йөрибез бит, әй! Мөгаен, бу эшнең башында һәм азагында Гурий булгандыр. Мин Галимҗан Ибраһимовны белергә өлгерми калдым, бердәнбер әсәрен, дәһшәтле һәм куркыныч «Адәмнәр»ен укуым гына хәтердә.

Яшь чакта сыенырлык, акыл алырлык олырак кешегә тартыласың. Мондый кеше минем очен шагыйрь дустым Гурий иде. Егетнең дөнья, тормыш, чынбарлык хакында кыю гына, йомры-йомры сүзләр ычкындыргалавын да искә алсак, Гурий кайбер җәһәттән дустым гына түгел, укытучым да иде. Мин аның зур һәм данлы язучы булып китәчәгенә шикләнми идем Бу, мөгаен, шулай да булган булыр иде, Гурийның омтылышы, тәкәбберлегә әдипкә комачаулаулый торган сыйфат дип саныйм. Озак елларга кадәр Гурий үзен таныта алмыйча торды. Моның бик җитди ике сәбәбе бар дип беләм.

Беренчесе һәм мөһиме — сугыш. Сугышка яшьли барып кергән гуманистик җанлы егетнең, шагыйрь, бары тик шагыйрь булып яшәргә әзерләнгән Гурийның канлы көрәш кырларында нилләр кичерүен аңлау кыен түгел. Хәтеремдә, сугыштан ул ничектер юашланып, басылып, әйтергә яраса, чак кына өшәнеп тә кайтты шикелле. Старшина погоннары таккан, өстендә калын сукноднан тегелгән солдат шинеле. Шинель килешми иде Гурийга, бәкрәйтә иде ул аны, иңнәреп аска баса иде.

● Гурий Тавлин.

Мин аны Лермонтовның «Безнең заман герое»ндагы Грушницкийга охшатып та йөрдем.

Поляк ордены Грюнвальд тәресенә лаек булган, байтак совет орден-медальләрен түшенә кадаган Гурийның сугышчан батырлыклары белән мактанганын бер дә хәтерләмим. Сәерме? Сәер! Башка җәһәтләрдән сүзгә оста, чак кына шартлатып та җибәрә торган старшинаның сугышны телгә алырга теләмәвен, бүгенге аңым югарылыгыннан торып, мин бары бер нәрсә белән генә аңлатам — рухын сындырган иде кан коешлар егетнең! Тән ярасы алу да җиңел түгел. Ә җан ярасы алганнарның хәлен кемнәр белә? Гурий элеккегә горур, кыю шагыйрь түгел иде инде. Заманасы да авыр. Ул беразга авылда калды, коммунистлар партиясенә керде, колхозда эшләде. Хәлләнде, элеккегә егәрә кайтты, новеллалар иҗат итә башлады, шигырьләрен дә ташламады, әмма сугышта күргәннәрен язмады да, сөйләмәде дә. Сугыш беткәнгә кырык ел узды, илле ел үтте. Гурийның сугышта күрсәткән батырлыклары, кичерешләре, бикле хатирә сандыгын җимереп, дөньяга чыга алмады. Кызганыч! Бәлки, Габдрахман ага Әпсәләмовның һушын алган «Дунай дулкыннары» повесте сугыш юлларына багышланган әсәр булгандыр, әмма Гурий аны да дөньяга чыгарырга өлгермәде. Казанга килеп, институтта укый башлагач, Гурий тәмам җанланып китте, исеме әдәбият дөньясында танылды. Әмма язмыш, без яшәгән катлаулы чор танылып килгән язучыга сынауларның тагы да катыргаын әзерләп куйган икән! Ул дүрт ел дәвамында төрмә-лагерьларда җәфа чикте, авырлыкларны чор белән бергә кичерде.

Исән-аман кайтып төшсә дә әдипнең рухы шактый төшенкә иде. Әдәбияттан читләште, бер нәрсә дә язмады дип әйтә алмыйм, очрашкан мәлләрдә ул канатланып китә, еш кына: «Роман тәмамладым әле... Фрунзеның ачы язмышы хакында... Повестьлар яздым... Капчыгы белән сиңа китерәп ташлыйм әле!» дип әйткәләп куя иде. Белүемчә, ул зур әсәрләреннән Солтангалиевкә багышлап зур роман язып бетерде. «Казан утлары» журналының ул чактагы мөхәррире Ренат Харис: «Бар андый роман, безгә китерде», дип тә сөйләгән иде. Кызганыч, ул әсәре дә дөньяда күренмәде. Ялгышмасам, әдипнең архивында байтак мәгънәле вә гыйбрәтле әсәрләр дөньяга чыгуларын көтеп ята булыр.

Казларның да чаты билгеле бер срокта гына ачылмый, кайсысы иртәрәк өлгерә, кайбер ана казлар тоткарланып торалар. Әдипләр дә шулай. Әдәби активлык кайберәүләргә өлкәнәя башлагач, дөньяның аркылысын-буен тәмам аңлагач, фикерләр, укмашып, бер бөтенгә әйләнгәч килә. Соңгы елларда Гурий татар әдәбиятын «Афәт» романы белән баетты. Без яшәгән заманның эче-тышын каерып ачкан, авыр һәм катлаулы язмыш кичергән шәхесләргә багышланган әсәрне татар укучысы үз итеп кабул кылды. Роман Гурий Тавлинны әдәбиятыбызның алгы сафына чыгарды. Бу әсәр турында фикерләрнең бүгенге көндә дә тынганы юк. Шул арада әдип икенче бер романын да өлгертте. Бу юлы Гурий еракта калган тарихыбызга күз ташлады һәм тарих аша бүгенгене аңларга тырышты. «Казан утлары» редакциясе вәгъдә иткәнчә, әсәр килесе елда журнал битләрендә дөнья күрәчәк.

Балачагыннан әдәбият дип яшашынган, дөньяның авырлыгын туя татыган яшьлек дустым Гурий Тавлинның иҗаты ныгыган, киңәйгән чак бүген. Декабрь аенда җитмеш яшен тутырса да ул иҗади хәрәкәттә, туктап торырга исәбе юк әлегә. Гәзит-журналларда күренгән мәкаләләре, төпле рецензияләре дә әнә шул хакта сөйли. Мин үз ягымнан аңа якты киләчәк, эшлекле картлык телим. Сау сәламәт бул, Гурий! Җитмешкә җиткәч, саулык бер дә артык түгел. Бай бул, Гурий! Җитмештә, бигрәк тә бүгенге заманда аңысы да бик кирәк.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.
Ноябрь, 1995 ел.

ХАЛЫК ВӘ ХАКЛЫК

ТӨРМӘЛӘР ҺӘМ ПАРЛАМЕНТЛАР

Һәр илнең халкы хакимиятне сайлау юлы белән оештыруны иң гадел юл дип саный. Борынгы заман кешеләре дә ыруг һәм кабилә башлыкларын сайлап куя торган булган. Галимнәр ул чорны кешелек дөньясының «алтын гасыры» дип атыйлар. Адәм баласы алтынның байлык икәнен таный башлагач, «алтын гасыр» тәмамланган. Надан затлар да хакимияткә якын кешеләрнең генә халык байлыгын үз кулларында тотуларын аңлаган. Шул сәбәпле, наданы да, акыллысы да хакимияткә үрмәләүне төп максаты иткән.

Хакимияттә урнашып калганнар, әлбәттә, үзләренең җылы урыннарын беркемгә дә бирергә теләмәгән. Шул сәбәпле, хакимиятне сайлап кую гамәле озак гасырлар буена рәсми рәвештә туктатылган.

Яңа заманнар килгәч, хакимиятне сайлау яңадан «мода»га керә башлый. XX гасыр башында Русия империясендә дә Дәүләт Думасы сайлаулары була. Безнең мәшһүр милләттәшебез, атаклы юрист (фикъһе белгече) Садри Максуди Дума мөнбәреннән татарның гына түгел, ә барлык мөселман халыкларының хокукларын яклаучыга әйләнә. Шовинист Пуришкевичның да чын йөзен дөнья җәмәгатьчелегенә Садри Максуди ачып сала.

Хакимиятне сайлап кую «мода»сы теге яки бу рәвештә безнең Русиядә дә, Татарстанда да хәзерге көннәргә чаклы сакланып килә. Мәсәлән, без быел 5 март көнне сайлаулар үткәреп алдык, яңа парламент булдырдык. Кыскасы, суверенитетыбызның эчтәлеген баетырга омтылдык.

Ниһаять, безнең дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларациягә биш ел тулган көннәрдә Русиядән зур кунаклар килеп, безне Русиянең субъекты дип кырыкмаса-кырык тапкыр кабатласалар да, моңа беркем дә хокукый яктан игътибар итмәде, киресенчә, җитәкчеләребез эндәшмәүне мәгъкульрәк күрделәр. Нишлисең, «сәясәт — пычрак эш», диләр бит. Бәлки, пычракны чыгарасылары килмәгәндер.

Чыннан да Татарстан Республикасы Конституциясенең 61 нче маддәсендәге «ассоциацияләшкән дәүләт« һәм Русия җитәкчеләре тәкрарлаган «федерация объекты» дигән төшенчәләр арасында сәяси, хокукый яки, һич югы, филологик аерма бармы-юкмы икәненә беркемнең дә җавап биргәне юк һәм бирергә җыенмыйлар да кебек.

Әмма моның милләтебез һәм дәүләтчелегебез өчен хәлиткеч мәсьәлә икәнен онытырга ярамый. Конституциябезнең 59 нчы маддәсен алып карасак, Татарстан туфрагында Татарстан Республикасы законнары өстенлек итә, дип акка кара белән язылган һәм бу бөтен халык тарафыннан да, Шартнамә нигезендә Русия тарафыннан да танылган!

Әлеге ике маддәне урап узып, Татарстанда Русия законнары нигезендә Русия парламентына сайлаулар үткәреп була идеме, юкмы? Урап узсаң, әлбәттә була иде. Монысы — мәсьәләнең юридик ягы. Мәсьәләнең юридик ягына таянып, сайлауда катнашырга теләүчеләрне милли хәрәкәт оешмалары, бигрәк тә Татар иҗтимагый үзәге, мөстәкыйльлегебезнең дошманы дип игълан итү ягында торды. Кайберәүләрнең дошман эзләү холкы бетмәгән әле, күрәсең.

Хәзерге вакытта Татарстан өчен генә булган Конституция таләпләре белән бөтен Русиягә таралган татар халкының милли бердәмлек идеяләре үзара каршылыклы мөнәсәбәтләргә керә. Кайсысына өстенлек бирергә соң аларның? Хокукый дәүләт төзик дисәк, әлбәттә, берсүзсез Конституция таләпләренә өстенлек бирергә кирәк. Әмма бу Конституцияне кабул иткән чакта татар халкының милли бердәмлек идеяләре төшенчәсе исәпкә алынды микән соң? Конституция таләпләрен җентекләп тикшергәндә дә бу сорауга төгәл генә уңай яки тискәре җавап биреп булмый.

Мондый чакта халык ни әйтер дигән принципка таяналар. Әмма халыкка да мәсьәләнең кайсы ягына басым ясап аңлатасың бит әле. Әгәр дә административ ысул белән Президент (яисә аның исеменнән) администрация башлыкларына, ә аннары администрация башлыклары хуҗалык җитәкчеләренә «кирәкле» күрсәтмәне «төшерсә», шул күрсәтмә тормышка ашачак. «Өстән» ничек әйтелсә, шулай эшләнә.

Ләкин сәяси-хокукый өзерлеге җитәрлек булмаган халык исеменнән спекуляция ясау да дөрес түгел. Сәяси нәтиҗәдән тыш, сайлау кампаниясенең икътисади нәтиҗәсен дә истән чыгарырга ярамый. Ничәмә миллиард сум акчаны, демократия уйнап, җилгә очырганчы, мәктәпләрнең һәм яшь гаиләләрнең тормышын яхшыртуга тотудан да иманлырак эш булмас иде. Әлбәттә, плакат язасы тукыманы ыштыр өчен ертырга ярамаганлыгын да истән чыгарып бетермәскә кирәктер.

Татарстан белән Русия арасындагы дәүләтара мөнәсәбәтләрнең Шартнамә нигезендә тиешле формуласы табылмады. Конституция нигезендә без Русия белән ассоциацияләшкән суверен дәүләт, ә Шартнамә буенча — Русия белән дәүләт буларак берләшкән (суверен) республика. Чынбарлыкта без — Русия субъекты. Татарстан Конституциясе буенча да, Шартнамә нигезендә дә Татарстанда Русия парламентына сайлаулар үткәрү каралмаган. Ә без сайладык. Кайберәүләр, тыелмаган да бит, дип әйтергә тырышалар. «Тыелмаган, димәк, рөхсәт ителгән» дигән принцип бары тик милек-мөлкәт һәм хуҗалык мөнәсәбәтләренә генә ярый торган кагыйдә. Аны һич тә конституцион-хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланырга ярамый. Русия Конституциясендә «Татарстанны бомбага тоту тыела» дигән кагыйдә юк, дип, бу гамәл рөхсәт ителгән дип уйласак, ә җинаять-процессуаль кодексында гаепләнүчегә кул белән орыну (рукоприкладство) гына тыелган, дип, аларны аяк белән типкәләү «тыелмаган», димәк, «рөхсәт ителгән» принцибын киң мәгънәдә аңлауның кая алып барганын чамаларга мөмкиндер.

Дәүләт эшендә Конституциядә язылганны гына эшләргә кирәк. Әмма без, Шартнамә төзеп, Русия Конституциясен дә таныдык. Анда исә бөтен Русиядә сайлаулар үткәрү каралган. Шулай да Шартнамә буенча Татарстан дәүләт дип танылган һәм безнең үз гражданлыгыбыз бар. Ә Русия үзенең татар милләтеннән булган гражданнарын Татарстан гражданнары дип танымый, гәрчә тигез хокуклы Шартнамә төзесәк тә. Тарихи, географик һәм халыкара мөнәсәбәтләрдән чыгып, без кайбер вәкаләтләрне Русиягә тапшырганбыз икән, бу Русиягә ниндидер сәяси хокукый һәм дәүләти бөекдержавачыл өстенлек бирә дигән сүз түгел әле. Әллә моны Русия сәясәтчеләре һәм юристлары аңламыйлармы? Аңлыйлар, әмма аңлауларын күрсәтергә теләмиләр. Бөекдержавачыл шовинистик сәясәткә хакыйкатьне күрмәү кулайрак. Ничек кенә булмасын, Татарстанда Русия парламентына сайлаулар үткәрү өчен катгый юридик таләпләр юк дип әйтү генә җитми, ә киресенчә, юридик документларда Татарстанда Русия парламентына сайлаулар үткәрү турыдан-туры каралмаган дип әйтергә кирәк.

Сайлауларны үткәрмәгән очракта да, без татар халкының милли бердәмлек идеясен игътибардан читтә калдыра алмый идек. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез халкыбызның мәнфәгатьләрен якларга омтылып, Русия парламентына сайланырга тырыштылар. Без бу вакытта тыныч кына утырып тора ала идекме, юкмы? Әлбәттә, юк. Әмма Русия белән Татарстан башкаларныкыннан үзәнчәлекле Шартнамә төзегән икән, Русиягә тапшырган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшереп тору өчен без, әлбәттә, Русия парламентына вәкаләтле вәкилләребезне җибәрергә тиеш идек. Мондый мәсьәләләрне хәл итәр өчен без үзебезнең Президентны да, Дәүләт Шурасын да сайлаган идек инде. Тик алар ни өчендер Русия Дәүләт Думасына сайлауларны үткәрүгә карата тиешле сәяси-хокукый мөнәсәбәтләрен ачыктан-ачык белдермәделәр. Русиянең административ өлкәләрендә сайлаулар ничек үткәрелсә, бездә дә шулай үткәрелүе Шартнамәнең һәм аның нигезендә төзелгән килешүләрнең хокукый эчтәлеген зур шик астына куя. Ул гына да түгел, Татарстан буенча Мәскәүнең хуҗабикә марҗалары да депутатлыкка сайланырга тырыштылар. Кыскасы, безнең өчен Русия парламентына тулы вәкаләтле вәкилләрне Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан сайлап җибәрү иң кулай юл булыр иде. Кызганычка каршы, Дәүләт Советындагы депутатларның мондый «вак-тояк» мәсьәләләр белән «вакланып» торасы килми, ахры.

Татарстанда әле язгы сайлаулар шаукымы бетеп тә җитмәде, Русия сайлаулары мәхшәре башланды. Тагын кичләрен кешеләрнең фатирларына имза җыючылар килеп, җаннарына тиеп беттеләр. Чынлап та имза җыючылар идеме алар, әллә юкмы — анысын беркем дә белеп бетермәде.

Кайчандыр Русия империясе «халыклар төрмәсе» дип атала иде. Американың 41 нче Президенты Р. Рейган исә аңа «явызлык империясе» дип өстәде. Нәрсә сайлады соң безнең халык? Парламентларның уртак төрмәсенме яки төрмәләрнең парламентынмы?

Назим САФИН,
хокук белгече, редакциянең кеше хокуклары рухиятне яклау һәм хатлар бүлеге мөдире

Я зучы кайда, ничек иҗат итә? Бу
сорау күп кенә укучыларны кызыксы-
ндырадыр дип уйлыйм. Шуңа күрә ка-
ләм әһелләре тормышына кагылышлы кай-
бер «вак-төяк» мәсьәләләргә тукталып үтмәк-
че булам. «Вак-төяк» сүзен куштырнаклар
эченә куйдым, чөнки, ныклабрак уйлап кара-
саң, безнең бөтен тормышыбыз вак-төякләр
белән уратып алынган. Һәм шушы вак-төяк-
ләр безнең яшәешебезгә, иҗатыбызга, көе-
фебезгә бик нык тәэсир итә. Нәрсә соң ул
«вак-төяк» һәм ул кайдан башлана?

Белгәнебезчә, язучы өендә иҗат итә. Шуңа
күрә өйдәге һәрбер җитешсезлек аның кә-
ефенә суга. Әйтик, иртән торып юыныйм гына
дигәндә суың булмаса, көчкә илла алла та-
мак ялгап, язарга утыруга өстеңдәге яки аскы
каттагы күршең гөмбердәтеп музыка уйнаты-
рга тотынса, әлбәттә инде, кулыңнан эшең
төшә. Монда мин фатирсыз интеккән яки бар-
лык әсәрләрен бала-чагалары йоклагач, кух-
няда язып йөргән әдипләрне әйтеп тормыйм
инде. Күп кенә шагыйрьләр, язучылар үзлә-
ренең иҗат юлларын тулай торакның кысан
һәм тавышлы бүлмәләрендә, кеше почмак-
ларында һәм тагын әллә кайларда башлый-
лар. Күбесе рәтле торак күрә алмыйча фани
дөньядан китеп тә баралар. Дөрес, арада бә-
хетлеләр дә юк түгел. Андый бәхетлеләрнең
фатирлары — шәһәр үзәгендә, урам тавыш-
лары керә алмаслык тыныч кварталларда,
иркен бүлмәле биек йортларда. Һава анда
саф, чөнки завод-фабрикалар адым саен тө-
тәп тормый, кино-театрларга барырга теле-
сәң — рәхим ит, һәммәсе янешәндә. Язар
өчен аерым кабинет. Кабинетында сиңа кирә-
кле китаплар, белешмәләр. Өстәлеңдә язу
машинкаң һәм синең кагылуны көтеп утыру-
чы телефоның.

дисеңме — санап бетерерлек түгел. Ә мин
бит Казанда түгел, җәһәннәм астындагы Ба-
улы районында ята идем. Ул чорда Язучылар
берлеге идарәсе рәисе Мирсәй Әмир, «Совет
әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журна-
лының баш мөхәррире Абдулла Гумеров иде.
Минем бүген Абдулла абыйны аеруча җылы
сүзләр белән искә алып китәсем килә. Әйбәт
кеше, чын зыялы кеше иде мәрхүм. Ул безгә,
беренче мәртәбә мин әле авылда яткан чак-
та, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Рәшит Гә-
рәйләр белән килгән иде. Шуннан соң ул ми-
не күздән ычкындырмады. Мин Казан хаста-
ханәләренең берсендә ятканда Сибгат Хәким
белән икәүләп килеп, минем шигырь дәфтәр-
ләремне актарып, әйбәт дип тапканнарын
журнал өчен үз куллары белән күчереп алып
киткәннәре хәтердә. Ә бер көнне палатага
Абдулла Гумеров бер кочак китап күтәреп
килеп керде: «Менә бу китап авторларының
һәммәсеннән автографлар яздырып алдым.
Сиңа күбрәк укырга кирәк. Бервакыт әле үз
китапханәңне булдырырсың, әмма әлеге бү-
ләкләрне югалтма», дигән иде.

Минем чынлап та кечкенәдән үк үземнең
шәхси китапханәмне булдырасым килә иде.
Хәтта берчакны үзебезнең клубтан «Совет
әдәбияты» журналының берничә санын чә-
леп тә кайтканым булды. Янәсе, маясы бул-
са, әкренләп җыелыр. Хәзер инде, шөкер,
китапларым шактый. Култамгалы китапла-
рым гына да бер шкаф диярлек. Әмма бүген
сүзем китаплар турында түгел, кешеләр, ка-
ләмдәшләр, хакимият вәкилләре турында.
Мин элекке буын язучыларны хәзергеләре
белән чагыштырып карыйм: бер буын арасы-
нда җир белән күк аермасы бар...

Минем фатирымда телефон юк иде. Авыл-
дан килгән гадәт буенча, өни тегендә-монда
киткәндә, ишекне биклэтмим. Чөнки беләм:
көнә буе миңа кем булса да килми калма-
ячак. Һәм чынлап та йә Марс Шабаев, йә

чан безнең китапларны басарга ашкынып то-
рдылар? Совет хөкүмәте дә мәдәният өчен
акчаны тамчылап кына тамызды. Шулай бу-
луга карамастан, Татарстан китап нәшрияты-
нда эшләүче бүлек мөдирләре: «Киләсе елга
тематик план төзибез, син нинди әсәр бирер-
гә уйлыйсың? Күләмен, әсәреңнең кыскача
аннотациясен язып җибәр», — дип мөрәҗә-
гать итәләр иде. Минем үземә, мәсәлән, Сафа
Сабиров, Шамил Рәкыйповларның шундый
хат җибәргәннәре булды.

Фәнис ЯРУЛЛИН

Күңелебез кыңгыраулары тутыкмасын

Чынлап уйлап карасаң, һәр язучы шундый шартларда эшләргә һәм яшәргә тиеш. Әйтик, кечкенә генә бер чиновникның конторада үз эш кабинеты, телефоны, секретаре була. Аны персональ машина йөртә. Хөкүмәт әлеге түрәне тотар өчен машинага, шоферга, секретарьга, курьерга һәм тагын әллә кемнәргә миллионнарча сум акча түгә. Ә андый чиновниклар үрчегәннән-үрчи, чөнки аңа талант кирәкми. Өз-мөз тырышсаң, белемең булмаса да, дипломың һәм югарыдагыларга ярый белү сәләтең бар икән — шул җитә.

Ә җиде миллионлы татар халкының 200ләп язучысы бар (аның әле чын язучысы 50—60тан артмыйдыр), шуларга тиешле кадер-хөрмәт күрсәтеләме соң? Башка иҗат кешеләре белән чагыштырганда, язучыга хөрмәт-ихтирам бик сирәк эләгә торган бәхет. Билгеле, бу иң беренче чиратта, хөкүмәтнең, дәүләт эшлеклеләренең әдәбиятны үги итүләреннән киләдер. Бу хакта матбугат битләрендә әледән-әле язылып торганлыктан, мин мәсьәләнең башка ягына кагылмакчы булам. Минемчә, язучыларыбызга кадер-хөрмәт кимүдә язучыларның үзләрендә дә гаеп бар. Халык бит сукыр да, саңгырау да түгел — ишетеп, күреп тора. Кемнәр бер-берсе турында ничек сөйли? Ни дәрәҗәдә зурлыйлар, кемнең исемен югарырак даирәләрдә телгә алмыйлар — шуңа карап укучы безнең әдипләребезне сортларга аера. Әлбәттә, һәр укучы алай дип әйтергә җыенмыйм: язучының иҗатына чын бәя бирүчеләр дә күп. Рәхмәт андыйларга. Ләкин алтынны бакырдан аерырга әдипләребез укучыларны үзләре дә өйрәтергә тиеш. Ничек итепме? Бер-берәңне хөрмәтләп, укучыга каләмдәшең иҗатын күрсәтергә булышып. Кыскасы, юллары күп инде аның.

Хәзер бездә язучы белән язучының аралашуы бетте. Ә бит моннан 25—30 еллар элек алай түгел иде. Мин үзем, мәсәлән, хастаханә палаталарында яза башладым. Беренче ике китабым шунда язылган әсәрләрдән әзерләнде. Марс Шабаев матбугатта минем хакта язып чыккач, язучылардан кемнәр генә килмәде миңа: Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Рәшит Гәрәй, Абдулла Гумеровлар дисеңме, ялкынлы трибун шагыйрь Мәхмүт Хәсәен, артист һәм мәсәлләр остасы Абдулла Шамуков Илдар Юзеев, йә Газиз Мөхәммәтшин сугылып уза иде. Алар — үзләренең яңа әсәрләрен, мин үземнекеләрне укыйм. Бер-беребезне тәнкыйтьлибез, бәхәсләшәбез, кызып китәлибез. Әмма үпкәләү юк. Мин аларга караганда тәҗрибәсезрәк яшь язучы булсам да, алар минем сүзне җитди итеп тыңлыйлар. Ә хәзер каләмдәшләреңә үзара сөйләшеп утырганда берәр тәнкыйть сүзе әйтсәң, ул синең дошманыңа әйләнә. Үч тотып йөри башлый.

Тагын элекке чордан бер мисал. Бервакыт мин пьеса язгач («Әнә килә автомобиль»), өйгә Илдар Юзеев белән Туфан Миңнуллинны чакырдым. Пьесам уңышлы түгел иде, укый башлагач мин аны үзем дә сиздем. Әмма алар, ике сәгать буена мине бүлдермичә, ялыктыргыч әсәремне ахырга кадәр тыңларга түземлек таптылар. Укып бетергәч, кызып китмичә, бик әдәп белән пьесамны баштанаяк «сүтә» башладылар. Мин шунда аларның һәр эпизодны хәтерләренә сеңдереп калуларына һәм төпле анализ бирүләренә исем киткән иде. Ә Марс Шабаев турында әйтеп тә тормыйм инде, иҗатымның башында ул минем һәр шигырьнең «сөяген сөяккә», «итен иткә» аерып, начар шигырьләр язсам, пыр туздырып китә иде. Мин әзме-күпме уңышларга ирешкәнмен икән — иҗатташ дусларыма бурычлы.

Әдипкә үсәр өчен аралашу кирәк. Иҗатташ дусларының фикерләрен ишетү — язган кеше өчен үзенә күрә бер мәктәп ул. Шунсыз иҗат кешесе юнәлешен югалтырга мөмкин.

Ә хәзер бармы соң бездә аралашу? Бер-беребезгә килеп яңа әсәрләребезне укыйбызмы? Яки газета-журналларның баш мөхәррирләре, югарыда әйтелгән Абдулла Гумеров кебек, яныңа килеп, үз куллары белән журнал өчен синең шигырьләреңне күчереп алып китәме? Гомумән, кеше белән аралашу культурасы калдымы бездә? Мин бу сорауга кистереп: «Юк!» дип әйтә алам. Хәзер безнең күңелләребез тарайды. Журналларга яки китап нәшриятларына берәр әсәр язуың турында хәбәр итсәң, зарлану китә: әйберләр күп, чыгарырга мөмкинлек юк — фәлән дә фәсмәтән. Хәзер күбебез тар күңеллелегебезне заман авырлыгына сылтыйбыз. Кайчан соң безнең илдә тормыш җиңел булды? Иписез үскән сугыштан соңгы еллардамы яки без яза башлаган алтмышынчы еллардамы? Кай-

Ә бит ул чорларда да акча елга булып акмый иде.

Кешегә киң күңелле, олы җанлы булу өчен матди байлык кына кирәкми. Әйтик, менә миңа, авыруым сәбәпле, хастаханәләрдә шактый еш яткаларга туры килә. Безне, гадәттә, хатыным Нурсөя белән салалар, чөнки мине сәгать саен бер яктан икенче якка әйләндерергә, кирәк-чакта утыртып, кирәк чакта яткырып торырга һәм дә башка йомышларны үтәргә сестра-санитаркалар җитешми. Белгәнегезчә, безнең гаиләбез икебездән генә тора. Димәк, хастаханәдә яныбызга килергә кешебез юк. «Ә Язучылар берлеге?» — диярсез. Миңа, мәсәлән, хастаханәдә яткан вакытта да, өйдә дә аннан бер генә кешенең дә килеп чыкканы юк. Дөрес, узган ел Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Гариф Ахуновлар килеп китте. Өч остахана исеменнән Тукай премиясенә тәкъдим итәчәкбез, дип, иҗатыма, соңгы вакытта эшләгән эшләремә әйбәт кенә бәя бирep киткәннәр иде. Ә башка вакытларда ни туган көн белән котлау, ни мондый бәйрәмнәр белән тәбрикләү юк. Мин монда дусларча кереп йөрүчеләрне әйтмим. Анысы башка мәсьәлә. Аллага шөкер, гади кешеләр арасында дусларым җитәрлек. Ул яктан мин үземне бәхетсез саный алмыйм: яшь шагыйрьләр дисеңме, студентлар яки укучылар дисеңме — өемдә һәрвакыт кеше. Хәтта ерак авыллардан автобус-автобус укучылар килеп төшә. Кайберләре үз һөнәрләрен күрсәтә — шигырь укый, җырлый. Кайберләре яңа шигырьләр укуымны сорый. Ерак шәһәрләрдән хәлемне шалтыратып сораучылар да бар. Тик Язучылар берлеге генә шалтыратмый. Хәл белү өчен югыйсә әллә нинди чыгымнар таләп ителми. Моның өчен бераз кешелеклелек кенә кирәк. Шалтыратып хәлен белешсәм, берәр нәрсә сорарлар дип куркалармы?! Юкса, Язучылар берлегеннән әллә нәрсә сорап, аларны аптыраткан юк. Хәтта литфондтан да: «Сиңа курорт-санаторийларга яки иҗат йортына путевка кирәкмиме? Гел өеңдә генә ятканчы, бер дөнья күреп кайтыр идең», — диюче булмады. Берәр җиргә барам икән — үз акчама йөрдем. Ә бит кайбер язучылар үзләренең туган авылларына, әни-әтиләре янына да командировка акчасына гына кайталар.

(Ахыры 18 нче биттә).

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ № 5 (28)

Бер балык башын күпме чәйнәргә була?

Туган тел турында җырлар
(Өзек)

И, телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.
И, безнең батыр телебез,
И, безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

Хәсән ТУФАН

Туган телен сөймәс туган анасын белмәс

Сүзләр хуш, куллар буш!

УКУЧЫ ФИКЕРЕ

Танылган галимебез академик Флүн Мусинның «Татар теле нигә кирәк?» дигән мәкаләсен (МҖ., 1995, 20 октябрь) укыганда, әллә адәм балалары арасында, чыннан да, олуг галимнәр әйткәнчә, күңел сиземләве — телепатия күренеше бармы икән, дип уйлап утырдым. Очрашып, фикер алышып тормаган кешеләрнең уйлары тәңгәл килүе, аларны борчыган мәсьәләләрнең бер була алуы мине тагын бер тапкыр дулкынландырды.

Болай булгач, сез Флүн Мусин әйткәннәрне кабатларга җыенасыз, диючеләргә минем җавап: кабатлау тәгълиматның анасы түгелме соң?

Кабатламый да булмый бит. Телебезне дәүләт теле итүдә бер генә җитди адым ясалмагач, бер үк балык башын нәтиҗәсез кабат-кабат чәйнәргә мәҗбүр булганга без гаеплеме соң?

Моннан өч ел элек Татарстан Югары Советы кабул иткән Конституциядә татар теле ике рәсми дәүләт теленең берсе дигән махсус статья билгеләнгән. Күпме бәхәсләр аша үтеп, Телләр турында закон һәм Дәүләт программасы кабул ителде. Хәтта шушы законнарны гамәлгә ашыру максатында Республика Министрлар Кабинеты каршында җәмәгатьчелек башлангычында Комитет та оештырган булдылар. Кыскасы, моңарчы бу эш кәгазьдә шактый шома барды.

Ә менә гамәлгә килгәндә? Моңарчы кәгазьләр күз буяр өчен генә эшләнгән булып чыга түгелме? Әлеге Комитетка һәм аның комиссияләренә эш башлап җибәрү өчен штат берәмлекләре дә, хезмәт хакы да, кыскасы, бернинди ихтыяҗга бер тиен акча да каралмаган. Бу идарәләрнең сөлгедәй озын исемлегендә саналган күренекле галимнәр, белгечләр үзләренең төп эшләре белән мәшгуль ләбаса. Шуларның берсе белән сөйләшеп торырга туры килде. «Их булса иде тәүлектә 48 сәгать, тел турында да бераз уйлар идек», — диде.

Әлбәттә, аларны гаепләп тә булмый — кем хәзер бушлай эшләсен, алай эшләгәннең барыбер юне булмый. Ә нигә соң, үтәлмәсен белә торып, карарлар кабул иткән булып, халыкны алдарга?

Әнә бит, академикка да бер гимназиядә ата-аналар: «Кәгазьдә генә калды түгелме соң ул телләр турындагы закон дигәнегез?! Тормышта әлләни үзгәреш күренми ич. Татар теле моңарчы ничек кирәкмәгән булса, хәзер дә шул хәлендә кала?» — дигәннәр.

Әлбәттә, бу сорау галимне дә борчый, аның күңелен дә агулы корт кебек кимерә. «Авыл капкасыннан чыккач татар теленең кирәге бетә, дигән элекке әйтем үз көчендә кала бирә бит», — дип борчыла ул. Чыннан да, бик нигезле борчылу шул. Менә, әр-яңа бер дәлил.

Күптән түгел биш ел бергә укып, югары уку йортын тәмамлаган бер дустым белән сөйләшеп утырабыз. Килеп керде гүзәл бер татар кызы. Исәнләште...

— Бу — сеңелем. Без укыган югары уку йорты студенткасы, — диде дустым. Ни сөенеч, татар мәктәбендә татар телендә белем алып; мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлап, югары уку йортына керү бәхетенә ирешкән. Ихластан котладым үзен, зур уңышларга ирешергә, бәхетле булырга язсын, дидем.

Ә кызыкайның йөзенә әкренләп күләгә төште.

— Ана телендә белем алуыма шатланып килсәм дә, Казанга килгәч, нәкъ шуның аркасында шактый борчуларга да дучар булдым, — диде.

— Нинди борчулар? — дим, аптырап.

— Моңарчы туган телдә уйларга, аралашырга, укырга-язарга күнегелгән иде, ә Казанның югары уку йортларында барлык фәннәр дә, кайбер тел фәннәреннән кала, урыс телендә укытыла икән. Татарча укып килгәннәргә шактый авыр. Урысча укучылардан калышырга мәҗбүр булабыз. Укытучысы да сиңа карап кына, яисә берничә кешегә карап кына, икенче режимга күчә алмый. Кайбер укытучылар хәлгә керә-керүен, әмма барысы да түгел. Ә син кайвакыт, теге йә бу сүзне дөрес әйтә алмавыңа уңайсызланып, көләрләр дип куркып, белгән фикереңне дә әйтә алмыйча төртелеп каласың. Укытучы, тиз генә дөрес җавап бирмәгәнгә ачуланып, начар билгене чәпәп тә куя. Шулай итеп, син өлгерми торган студентлардан санала башлыйсың. Күрәсез, ана телендә белем алуга шатлануыбыз иртәрәк булып чыга, хәтта үкенергә туры килә.

Бу сөйләшү миңа тынгылык бирмәде. Киттем теге уку йортына. Таптым теге укытучыны. Мәсьәләне уртага салып аңлашасы, уртак тел табасы килгән иде юк, булмады милләттәшем — укытучы туташ ут-очкын гына чәчте.

— Миңа барыбер татарча укыганмы безгә килгән кеше әллә урысчамы. Бездә кешене аеру юк, кем булуына карамастан, бертигез хокук, бертигез бурыч, бертигез таләп, — дип кисте дә салды. Аяк кына типмәде биллаһи.

Кабатлап әйтәм: ул бит милләттәшем, татар кызы иде. Югары уку йортларында татарча укытуны болай булса, гамәлгә ашыру өчен кемнәр янып йөрер соң?! Өстәвенә, бу хәл бит Татарстанның — татар иленең башкаласында бара. Татарга монда да шундый караш булгач, башка җирләрдә нинди булмас?!

Ә кайдан килгән ул бар кешене бер чыбыктан сөрү, ягъни бар кешегә бер караш, бер таләп? Дөньякүләм танылган академигыбыз А.Арбузов бер класста ике ел укыган.

— Аның татар мәктәбен тәмамлавы сәбәпле, башта бераз тоткарлануын исәпкә алу кирәктер, — дигән идем мин әлеге укытучы туташка.

— Миңа барыбер, — дип үзенекен тукыды ул.

Менә шушылар түгелмени инде телләр турындагы Программаны гамәлгә ашырырга аяк чалучылар. Бер төп телдән икенче төп телгә күчү — ул гадәттән тыш авыр һәм катлаулы нәрсә. Кем — кем, ә укытучы, аеруча югары уку йорты укытучысы шуны гына аңларга тиеш бит инде. Тик әлегә алар моны аңлап бетермиләр шикелле. Әллә аңларга теләмиләр дә инде?

Ни генә булмасын, бер нәрсә хакыйкать ләбаса: татар теле дә дәүләт теле икән, аңа кагылган бар мәсьәлә дәүләт аның җитәкчеләре гарантиясендә булырга тиеш, бер генә мәсьәлә дә үз агымына куелырга, кемнеңдер шәхси ихтыярына гына бәйле булмаска тиеш.

Менә нинди борчулы уйлар тудырды миндә академик Флүн Мусинның мәгълүм язмасы...

Равил ХӨСӘЕНОВ,
Казан компрессор берләшмәсе инженеры

БЕЗНЕҢ АНКЕТА

Киләчәк — яшьләрдә

Беренче көннәреннән үк сабый бала тирә-юньдәге бар нәрсәне игътибар белән өйрәнергә тырыша. Һәрбер тавыш, һәр сүз колагына аккош булып очып керә, олы кешенең кыланышлары игътибарсыз калмый. Еллар дәверендә бала үсә, чыныга, «аякка басарга» тырыша. Ә тирә-юньдәге мохит балага тәэсир итәмме соң? Әлбәттә!

Мин беренче класстан ук татар мәктәбендә, хәзерге көндә беренче татар гимназиясендә, белем алдым.

Гимназиябезнең ягымлы мөгаллимнәре, андагы җылы мөнәсәбәт безнең шәхес булып үсүебезгә булышлык итте. Мәктәбебез бездә менә дигән татар мөгаллимнәрен, журналистларын, врачларын, банк эшчеләрен күрә. Алла боерса, ышанычын акларга тырышырбыз.

Кечкенә сеңлемнең татар телендә сандугач булып сайравы, тәмләп сөйли белүе, миңа, ягъни бүгенге татар кызына кабатланмас бәйрәм шикелле. Кабатланмас бәйрәм шикелле... Әмма, бу бәйрәм һәр гаиләдә туктаусыз кабатланып, җөмһүриятебезнең барлык мәктәпләренә дә күчсен иде.

Милләтнең камилләшә баруы безнең кулда, ягъни татар яшьләренең акыл, зиһенендә. Яшьтәшләрем, сезгә бер генә киңәшем бар: «Киләчәк безгә карап тора. Тәвәккәллегез!»

Кадрия МАЛИКОВА.

ЯҢАЛЫК! ЯҢАЛЫК!

Дәреслек турында

Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләренең бүгенге хәле, яңаларын бастырып чыгару турында чираттагы фикер алышу Арчада булды. Татарстан Мәгариф министрлыгының фәнни-методик үзәге оештырган бу зонаара фәнни-методик конференция эшендә Арча, Балтач, Биектау, Әтнә районнары укытучылары, мәгариф хезмәткәрләре, дәреслек авторлары, нәшрият редакторлары катнашты. Рус һәм татар теле секцияләрендә дәреслекләргә җентекле анализ ясалды, эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

Төрле программалар нигезендә язылган һәм укытуга тәкъдим ителгән дәреслекләр турында фикер алышу аеруча кызыклы һәм әһәмиятле булды. Дәреслекләрнең сыйфатын алга таба да яхшыртуга юнәлтелгән бу чараның файдасы, һичшиксез, булыр.

Америкада татарча сөйләшәләр

АКШ эшмәкәре Илдар Агишны Татарстанда да яхшы беләләр — сәүдә эшләре белән ул безгә берничә тапкыр килеп китте инде. Ә күптән түгел Илдар әфәнде Мәскәү татарларының «Интеллектуал» исемле клубында кунакта булган. Аның белән әңгәмәсен «Азатлык» радиостанциясе хәбәрчесе, шул клуб җитәкчеләренең берсе Нәҗибә Кәримова тапшыруларның берсендә бөтен дөньяга ишеттерде.

Гомер буе Америка Кушма Штатларында яшәгән, шунда укыган яшь эшмәкәр үз ана телендә бөтен тәмен белеп, бик төгәл һәм аһәңле сөйли.

Безнең эшмәкәрләр, җитәкчеләр, дипломатлар кайчан туган телләренә шундый хөрмәт күрсәтә башлар икән?!

И.МАЗИН.

Сәхифәбездә:

- Туган телне — гамәлгә! Укучы фикере: алга бармыйбыз
- Югары уку йортларында: ана теленә ике төрле караш
- Тел өйрәнүчегә яңа китаплар.
- Хатлар яздым утырып... Язучы да бутагач, безгә ни кала
- Д.Карнегиның сөйләмият дәресләре: сүз алганчы, әзерлән!
- Балаларга укыгыз

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

ГАРӘБ ТЕЛЕНӘ МӘДХИЯ

Әй, бөек гарәб теле син,
Әй, гүзәл гарәб теле!
Хикмәтле милләт теле син,
Җирнең мөбарәк теле!

Дөньяга хуш ис тараткан
Гөлбакчаларның гөле.
Тел бакчаларында аткан
Мең чәчәкнең бер торе.

И, затлы гарәб теле син,
Иланы динем теле.
Сиңа мин туган телемдә
Мәңгелек гомер телим!

Син — изге Китап телесең,
Син — каләм-дәфтәр теле.
Син — борынгы, син — бүгенге —
Терекомештән тере.

Мөхәммәт пәйгамбәр теле,
Саваплы догам теле.
Син — гүя, Күкләрдән җиргә
Иңгән бер Ходам теле.

Кергән син әлифба белән,
Бисмилла белән миңа.
Тыңлаган саен сокланам
Синдәге сихри моңга.

Мөэмин-мөселман рухы син,
Мәгърифәт-гыйлем түре.
Изге кыйблабыз тарафы —
Мәккә-Мәдинә теле.

Син — изге сүрәләр моңы,
Дога-аятьләр сере.
Хәят вә җиһан күгендә
Дәү йолдызларның бере.

Мең дә бер кичә сере син,
Бөек Мәхәббәт теле:
Җан-гашыйк Мәҗнүн җыры син,
Таң-гүзәл Ләйлә төне.

Кергәнсең син дәүләтемә
Гамәл-шөгыльләр белән.
Мәгънәле зирәк исемнәр,
Күркәм фигыльләр белән...

Урелгәнсең син телемә
Аерып алмас булып,
Баетып Ана телемне,
Җәүһәр вә алмаз булып.

Бишвакыт намаз теле син,
Вә моңлы азан теле.
Дәрләгән учак өстендә
Кайнаган казан теле.

Кәрван-сарайлар теле син,
Чүлдәге мираж теле.
Әби-бабайлардан калган
Җуелмас мирас теле.

Дин вә мәгыйшәт теле син,
Илдән илләргә йөре.
Йокмасын сиңа кяфернең
Һичвакыт хәрам-кере...

Зәмзәм суларыдай сафсың,
Шифалы, сихәтлесең.
Биргәнсең минем телемә
Хәзинә нихәтле син!..

Мәңгегә өзелмәстер бу
Илаһи берлек җебе.
Якын син минем халкыма
Үз туган телем кебек.

Син — табигать, син — шәригать,
Мәдәният, аң-белем.
Беләсең килсә, син микем
Икенче туган телем!

Ишетсәм синең аһәңне,
Май кебек китәм эреп.
Хөрмә-җимешнең төше син,
Шулпа өстендә өре.

Син — алтын-көмешләрдән дә
Артык вә кыйммәтлесең.
Хөрмәтли синә затларның
Зыялы, һиммәтлесе...

Син — сирәк галимләр теле,
Шәех-сәетләр теле.
Меңләгән гадиләр моңы —
Көйле бәетләр теле.

Болгарыма сәях кылган
Ибн-Фадланнар теле.
Бәхет бакчасын сугарган
Көмеш фонтаннар теле.

Байлыгым вә зурлыгым син,
Ләззәтем, хозурлыгым.
Салдың син безнең күңелгә
Изге Иман орлыгын.

Якты хатирәләр теле,
Олугъ галимнәр теле.
Фән һәм фәлсәфә чишмәсе,
Моң вә шигърият күле.

Айлы манара нуры син,
Серле мәгарә төбе.
Мең рәхмәт сиңа! Мең яшә,
Соекле гарәб теле!!!

Сентябрь, 1995.

ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА

Юл яру һәрчак кыен

Балалар бакчасында мәктәпләрдә татар телендә укытуда берникадәр үзгәреш сизелә Ә менә югары уку йортларында хәл ничек? Мисал өчен татар мохитенә якын торган техник уку йортларыннан Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясен алыйк

Биредә укучыларның күбесе — республикабызның төрле төбәкләреннән килгән авыл егетләре Алар керү имтиханнарын татарча бирү фәннәрне татарча үзләштерү белән бик кызыксынган студентлар

Академиядә махсуслашкан өч факультет бар аларда икътисадчы агроном һәм авыл хуҗалыгы механигы (инженеры) белгечлеге бирелә

Авыл хуҗалыгын механикалаштыру факультетында татар телендә укыту мәсьәләсе 1990-1991 уку елында башлана Факультетның деканы Мөнир Гомәр улы Яруллин шул чорны искә төшерә

— Бу эшне башлаучыларның иң беренчесе Әнәс Хафиз улы Җомагулов булды Практик дәресләрне татарча укытуга башлап ул күчте Аңа бик җиңел булгандыр димәс идем Хәтта «милләтчелектә» гаепләргә маташтылар, дәресләренә «тикшерүчеләр» җибәрелде Аяк чалырга күп тырыштылар Ректорга чакырып, кисәтүләр дә ясалган. Ләкин Әнәс абый ана теленә табынган кеше булып чыга Бирешми, нык тора Иң мөһиме — башкаларга да тынгы бирми

Әнәс абый сафына профессор Алмаз Кыям улы Юлдашев та баса Татарча укытуга икәүләп керешәләр

Ул вакытта әле декан урынбасары булган Мөнир әфәнде 1991 елның мартында 1 курс студентларына (барлыгы 100 кеше) урыс телендә анкета сораулары бирә югары уку йортларында татар телендә укытуга ничек карыйсыз? Җавапларда исә шундыйрак фикерләр дә бар «Бу — мәгънәсез сорау». «Кирәкми, чөнки мин туган телемне онытттым». «Мин үзем урыс милләтеннән, татарлар өчен, әлбәттә, кирәк», «Аерым фәннәрне татарча укырга мөмкин». «Аерым группалар төзелсә — мөмкин» Кыскасы күпчелек (55-60 процент) «Әйе!». «Әлбәттә, кирәк!» ягында була.

Татар телендә укырга теләүчеләрдән махсус группалар төзелә башлый Бүгенге көндә әлеге факультетның 3 нче курсында 37 студенттан 2 группа 2 нче курста 40 студенттан 2 группа һәм 1 нче курста 47 студенттан шулай ук 2 группа аерым фәннәрне татарча үзләштерә

Шушы нәтиҗәгә ирешү өчен күпме авырлыклар үтәргә кирәк булган Татар милләтеннән булган җитәкчеләрнең аяк чалулары — бик тә аяныч Шулай да билгеләнгән юлдан тайпылмаска сүз биргән кешеләр бу нәтиҗәдә генә тукталып калмый Абитуриентларга керү имтиханнарын татар телендә тапшыру һәм татарча диктант язу мөмкинлеге бирелә Бу уңайдан 2 нче курсның группа старостасы Хәмис Мөхәммәтгалиев әйткән сүзләрне китерәм «Абитуриентларның бердәнбер шатлыгы инде — татар телендә диктант язу». — диде ул Шунысы да куанычлы — татарча диктант язучылар арасында «ике»ле билгесе алучы бер кеше дә булмаган Ә бит керү имтиханнарыннан физика химия фәннәрен яхшы билгегә бирөп тә русча диктантка «ике»ле алган абитуриент бөтенләй төшеп кала.

Ләкин проблемалар бүген дә күп әле Татар телендә белем бирүне барлык укытучылар да булдыра алмый. Методик кулланмалар җитешми, урыс теленнән тәрҗемә итү өстендә укытучыларга көн-төн эшләргә туры килә Ә шартлар юк, хәтта татарча машинкалар да юк Укытучылар бер үк лекцияне аерым группалар өчен урыс һәм татар телендә укыйлар, ә моның өчен аларга бернинди дә өстәмә түләү каралмаган Шулай да бирешмиләр, төрле юлларны табалар Әйтик, профессор Алмаз Юлдашев узган уку елында актив укытучылар өчен матди ярдәмне үз кесәсеннән чыгарган.

Яшь укытучылар да яңа эшкә кушыла бара Академиянең хәвефсезлек кафедрасы укытучысы Ринат Гали улы Нуруллин авыл хуҗалыгына караган терминнар сүзлеген язу өстендә эшли Башка укытучылар да үз фәннәрен татарча укыту өчен методик кулланмалар төзи

Татар группаларында укучы студентлар үзләре турында яхшы фикер калдыралар Дәресләргә 100 процент диярлек йөрүләре белән генә түгел, эштә дә үзләрен сынатмыйлар Бөреңге басуына эшкә чыгасы булса районнар татар группаларын сорыйлар Шуңа да академиядә укучылар арасында аларга хөрмәт белән карыйлар Үзләре белән аралашкач, мин дә моңа ышандым

Күптән түгел генә академиянең механикалаштыру факультетында татар телендә укучы студентларның, укытучыларның җыелышы булып узды. Бирегә Татарстан Дәүләт Советы депутаты Фәндәс Сафиуллин да чакырылган иде. Сөйләшү Татарстан Гимны тыңлаудан башланды. Җыелыш барышында уку процессына кагылышлы мәсьәләләр каралды. Агрономия факультеты доценты Камил Хәйрулла улы Галимов үзләренең факультетындагы үзгәрешләрне әйтеп үтте (Димәк, механикалаштыру факультеты үрнәгә үз җимешләрен бирә) Беренче, икенче курсларда аерым фәннәрне татарча үзләштерү каралган. Өлкән курсларда мондый мөмкинлек юк — чөнки укытучылар җитми. 2000 елга кадәр төзелгән планда башкарыласы эшләр графигы бар Әлеге эшне башлап җибәрүче Әнәс Хафиз улы Җомагулов яңалык әйтте. V курс студентларына дипломны татарча язу өчен мөмкинлек тудырылган

Фәндәс Сафиуллин да тыңлаучыларга үз фикерен җиткерде «Мин сезне укытучылар, укучылар итеп күрмим, көрәшчеләр итеп күрәм. Әгәр дә сез башка белгечләрдән өстенрәк буласыз икән — сез үзегезнең көчегезне исбатлыйсыз. Сез — башлап баручылар. Әлек Мәскәүгә карасак, хәзер инде үз җитәкчеләребез аяк чала. Җыелышта ректораттан кеше булмавы да борчый алар беренче башлап йөрергә тиешләр. Көрәшебез алда, ләкин бәйрәмнәребез дә алда Алла ярдәм итсен», — дип тәмамлады ул сүзен

Җыелыш, рәсми өлештән соң, академиянең үз халык театры куйган «Яшьлегемә кире кайтыр идем» дигән спектакль белән тәмамланды

Гөлназ ХӘЙРУЛЛИНА,
КДУ студенты

(Дәвамы. Башы 14, 19 нчы саннарда).

II бүлек
Ышаныч әзерлектән туа

Бу китап авторының 1912 елдан бирле һөнәри бурычы һәм шул ук вакытта яраткан шөгыле ул — елына якынча алты мең чыгышны тыңлау һәм тәнкыйтьләү булды. Аларны колледж студентлары түгел, ә бәлки җитлеккән кешеләр — эшмәкәрләр һәм белгечләр сөйләгән. Туплаган тәҗрибәсенә таянып автор менә нәрсәгә нык инанды: чыгышка алдан әзерләнергә кирәк, оратор нәрсә сөйләячәген ачык һәм төгәл белергә тиеш. Әйтерсең, сөйлисе әйберсе аңа нык тәэсир иткән булган һәм ул аны һич тә әйтми калдыра алмый. Хәтерлисез булыр мөһим идеясе булган һәм аны сезнең акылыгызга, хисегезгә җиткерер өчен үзе дә бөтен акылын һәм йөрәген биргән ораторга, үзегез дә сизмичә, ихтыярсыз тартылган чакларыгыз булды бит. Оратор-дәресләр бирә. Билгеле инде бу төр белгечләрнең вакыты чамалы: алар еш кына чыгышка тиешенчә яисә үзләре өмет иткәнчә әзерләнеп бетә алмый. Алар бит гомере буе үзләренчә уйлап, үзләренчә инанып, һәр күренеш хакында үзләренчә хөкем ясап тәҗрибә туплаган кешеләр. Шулай да кайберәүләренә моны тану кыен иде. Бу — агачлар артында урманны күрмәү иде.

Шушы төркем һәр җомгада кичке сәгать биштән җидегә хәтле шөгыльләнә иде. Бервакыт Нью-Йорк тирәсендәге банк хезмәткәре бер джентльмен (мистер Джексон дип атыйк) күрә бишенче ярты җиткән, ә чыгышының әле темасы да ачыкланмаган. Конторыннан чыгып, киосктан «Форбс мэгэзин» журналын сатып ала да, метрода Федераль резерв банкына барып җиткәнче (дәресләр шунда үтә) «Уңышка ирешер өчен сезнең карамакта ун гына ел» дигән язманы укып чыга. Әлбәттә, инде кызыксындырган өчен түгел, ә бәлки чыгыш өчен бирелгән вакытны тутырырга ярап куяр, дип.

Чын әзерлек нидән гыйбарәт?

Чыгышка әзерлек кәгазьгә язылган яисә ятланган шома фразалардан гыйбарәтме? Юк. Яисә үзегезне дә дулкынландырмаган очраклы рәвештә җыелган берничә фикердән гыйбарәтме? Юк. Әлбәттә. Әзерләнү ул — нәкъ менә үзегезнең уйлар, үзегезнең кичереш, карашларыгыз җыелмасын булдырудан гыйбарәт. Сездә бит алар җитәрлек. Алар көндәлек тормышта очрап кына тора, хәтта төшегезгә дә керә. Бөтен яшәеш хистән, кичерешләрдән тора бит. Һәм барысы да диңгез ярында яткан ташлар кебек зиһенегездә җыелып ята. Әзерләнү ул уйлаудан, фикерләрне «эшкәртү»дән, аеруча кызыксындырганнарын хәтергә төшереп, сөйләр өчен шомартудан, билгеле тәртипкә салып, үзенә бер төрле мозаика ясаудан гыйбарәт. Мондый программа сезгә бәлки артык катлаулы тоеладыр? Юк, ул әллә ни авыр түгел. Фикерегезне бер ноктага туплап, максатка омтылып уйланырга гына кирәк.

лса, әйберәк, якшәмбе иртәсе ндә сөйләячәк вәгазьне әзерләүне һич тә шимбә кичкә калдырырга ярамый.

Әгәр дә рухани бер фикерен халыкка сөйләр алдыннан башында бер ай, алты ай, хәтта бер ел дәвамында тота алса, фикерен нык камилләштерә барып, күренекле уңышка ирешеренә ышаныр иде. Бу хакта ул поездда барганда да, укып арыган күзләрен ял иттергәндә дә уйлый ала.

Әлбәттә, бу хакта ул төнлә дә уйлап ята ала. Шулай да чиркәү һәм гыйбадәт турында уйлап ятарга киңәш бирмәс идем. Моның өчен чиркәү мөнбәре дә җиткән. Шулай да минем төн уртасында торып, башыма килгән уй-фикерләремне онытмагаем дип, язып куйган очракларым булгалады.

Билгеләнгән вәгазьгә материал җыйганда бу темага яисә цитатага кагылган барлык уй-фикерләрегезне язып барыгыз. Библиядән алган текстыгызны беренче тапкыр ничек аңлаган булсагыз, шулай язып куегыз. Шуннан соң туган яңа фикер, чагыштыру, үзгәрешләрне дә языгыз.

Дейл КАРНЕГИ

Ничек үзеңдә ышаныч булдырып, халыкка тәэсир итәргә

лык осталыгының ярты сере шунда инде.

Менә шундый зиһени һәм хисси халәт кичергәндә оратор бик мөһим бер ачыш ясый: аның сүзләре үзеннән-үзе агыла. Сөйләү аңа газап түгел, ә — ләззәт. Яхшы әзерләнгән чыгыш сөйләп бетерә язган чыгыш инде ул. Беренче бүлектә әйтеп үтелгәнчә, күпчелек кешегә мондый күнекмәләр башлыча үз-үзеңә ышаныч тудыру, кыю булу, үзеңне вакытында кулга алу өчен бик файдалы. Әзерләнмичә сүз алган кешеләрнең күпчелеге зур хата ясый. Сугышка кысыр патрон, дымлы дары белән яисә бөтенләй коралсыз кергәндә солдат ничек курыкмасын да, ничек нервланмасын инде. Мондый очракта ораторның аудитория алдында үзен җайсыз тотачагына һич тә шикләнәсе юк.

Үз-үзегезгә ышаныч тудырасыгыз килә икән, нигә соң моның өчен кирәк булганны эшләмисез? Инде Ак йорт хуҗасы булганда да Линкольн «Мин беркайчан да төпле фикер булмаганда сүз алып сөйләрлек хәлгә төшкән карт булмам», — дигән. Ә апостол Иоанн «Чын мәхәббәт куркуны бетерә», — дигән. Чын әзерлек тә нәкъ шулай. Вебстрер «Тыңлаучылар алдына ике очракта гына чыгып баса алмас идем, беренчесе — начар әзерләнгәндә, икенчесе — киенер-киенмәс килеш», — дигән.

Нигә соң чыгышларыбызга җентекләп әзерләнмибез? Нигә? Кайберәүләр әзерлекнең нәрсә икәнен, аны ничек гамәлгә ашыруны күз алдына китермиләр. Ә икенчеләре вакыт җитмәүгә сылтый. Шуңа күрә дә, бу бүлекне без әлеге мәсьәләләрне тәфсилле ачыклауга багышлыйк.

Дөрес әзерлек

Әзерләнү нәрсә ул? Китап укумы? Китап уку — әзерләнүнең бер төре, тик иң яхшысы түгел. Укуның ярдәме тияр, әмма кеше китаптан «консервланган» фикерләрне күп алып, аларны шундук үзенеке итеп сөйләсә, чыгышта байбер нидер җитмәячәк. Тыңлаучылар нәкъ менә нәрсә җитмәгәнен аңламаса да, оратор сүзләренә битараф калыр.

Мисал китерим. Шушы китапның авторы бер арада Нью-Йорк банкларының бер төркем җитәкчеләренә ораторлык сәнгатеннән

Бер сәгатьтән ул язма авторы күтәргән проблеманы ышаныч белән кызыклы итеп сөйләргә маташты. Ничегрәк килеп чыкты соң бу азагы ничек бетте? Сөйлисе әйберен үзе дә аңлап җитмәгән, асылына төшенмәгән иде ул. Эшнең ничек килеп чыгуын «сөйләргә маташты» диюемнән үк ачык күренә булса кирәк. Ул чыннан да сөйләргә тырышып кына карады. Кыен хәлдән чыгу юлын тапмады. Үзен-үзе тотышы, сөйләү тоны шуны ачык күрсәтте. Ул әледән-әле язмага кире кайтып, автор сүзләрен китерде. Әлбәттә, бу чыгышта «Форбс мэгэзин» сүзләре бик күп, мистер Джексонныкы бик тә аз булды.

Менә шуңа күрә дә бу китап авторы аңа түбәндәге киңәшне бирде:

— Мистер Джексон, безне шул фикерләрен язган билгесез кеше һич тә кызыксындырмый. Ул монда юк. Без аның белән сөйләшә алмыйбыз. Безне сезнең фикерләр, сез үзегез кызыксындырасыз. Сез кемдер әйткәнне түгел, ә үз уйларыгызны сөйләгез, мистер Джексон фикерләрен күбрәк кертегез. Нәкъ шушы темага киләсе атнада чыгыш ясап карагыз әле. Язманы тагын укып чыгыгыз да ачыклагыз: автор белән килешәсезме юкмы. Килешәсез икән, аның фикерен үз күзаллавыгызча тасвирлагыз. Килешмәгән очракта, моны ачыктан-ачык әйтегез, сәбәбен аңлатып бирегез. Әлеге язма сезнең чыгышның этәргеч ноктасы гына булсын.

Мистер Джексон тәкъдимне кабул итте. Язманы кабат укыган, автор белән бөтенләй килешмәгән. Яңа чыгышына ул инде метро вагонында әзерләнми. Чыгышы аның аңында әкренләп, күпмедер вакыт дәвамында үз баласы кебек туа.

Икенче дәрестә кабат чыгыш ясаганда мистер Джексон үз йөзен, үзенең табышларын күрсәтә алды. Теге язма авторы белән килешмәве аңа яхшы сөйләргә этәргеч булды. Фикерләрдә берникадәр каршылык, аерымлык булу гомумән дә бик яхшы стимулятор ул.

Бер үк кешенең бер темага бер атнада ясаган ике чыгышының аермасы җир белән күк арасы иде! Дөрес әзерләнгәндә нинди уңышларга ирешеп була икән!

Дуайт Л. Муди дин тәгълиматы тарихына кереп калган нотыкларына ничек әзерләнә торган булган? Бу сорауга ул «Берниндисер дә юк — дип җавап бирә. — Мәгълүм бер теманы уйлый башлауга, мин аның исемен зур конвертка язып куям. Андый конвертлар миндә бик күп. Нәрсә дә булса уку барышында шул темага кагылышлы кызык һәм кирәкле фикергә юлыгам икән, аны күчереп алып, шул конвертка салып куям. Һәрвакыт куен дәфтәре йөртәм. Берәрсенең вәгазь яисә чыгышында мине кызыксындырган нәрсә ишетелә икән, аны язып алам һәм үз конвертыма салып куям. Язмалар бер ел, аннан да озаграк ятарга мөмкин. Яңа вәгазь әзерләргә керешкәндә ул язмаларны чыгарам да, аларны үзем күреп туплаган мәгълүматларга өстәгәч, миңа җитәрлек кызыклы материал туа. Шуның өстенә вәгазьләремне даими эшкәртеп торам: нәрсәнедер төшереп калдырам, нәрсәнедер өстим. Нәтиҗәдә алар беркайчан да искерми».

Йель мәктәбе деканы Браунның акыллы киңәше

Йель мәктәбенең 100 еллык юбилеен билгеләп үткәндә мәктәпнең деканы доктор Чарлз Рейнольдс Браун вәгазь сөйләү осталыгы турында лекцияләр циклы тәкъдим итте. Аның шул лекцияләре Нью-Йоркның «Макмиллан» нәшриятында китап булып та басылып чыкты. Доктор Браун чирек гасыр буена һәр көнне вәгазь әзерләгән һәм башкаларны да шуңа өйрәткән кеше. Шуңа күрә ул кайбер акыллы киңәшләр бирә аладыр. Ул киңәшләр 92 нче псалм турында сөйләргә җыенган руханига да, профсоюзлар турында сөйләргә әзерләнгән аяк киеме фабрикантына да бик әһәмиятле иде. Браун мәсьәләне болай ди: «Библиядән сайлап алган өзекне һәм гыйбадәтегезнең темасын әйбәтләп уйлагыз. Төмам туплангынчы һәм шомарганчы уегызда йөртегез. Алардан табылган нәни үсентеләргә үсеп китәргә мөмкинлек бирсәгез, бик күп мәгълүмат туплый алачаксыз.

Бу процесс озак вакытка сузы-

Фикерләрне кыска гына бер-ике сүз белән генә теркәп куегыз. Ә уегыз яңа фикер эзләүне дәвам итсен, тормышта бүтәнчә бер генә китап та укырга туры килмәс дип хис итегез. Бу — уйлау сәләтен үстерүнең бер төре. Шундый юл белән сез акыл эшчәнлегегезнең гел яңача, иҗади булуына ирешә алырсыз.

Чит кеше ярдәменнән башка туган, үзегезнеке генә булган фикерләрнең барысын да язып барыгыз. Акыл үсешегез өчен алар якут, алмаз, алтыннарга караганда да кыйммәт. Аларны төрле кәгазь кисәкләренә, иске конверт, хатларның буш урыннарына, бер сүз белән әйткәндә, кул астына эләккән теләсә нәрсәгә язып куегыз. Матур, чиста кәгазь битләренә язуга караганда бу күпкә яхшырак. Мондый алым кәгазьне янга калдырудан бигрәк, материалыгызны тәртипкә китерә башлагач, әлеге кәгазь кисәкләре белән эш итү аркасында җиңеллек бирәчәк.

Башыгызга килгән барлык фикерне яза барып, аларны өзлексез уйлап йөрегез. Бу процессны ашыктырырга ярамый. Бу бит әзерлек барышында сез сарыф итәргә тиешле акыл көченең иң күп туплана торган әһәмиятле чоры. Шуның исәбенә дә инде зиһенегез иҗади көчкә әверелә дә.

Сез ниһаять бер нәрсәне ачык төшенерсез: сез иң яратып сөйләгән һәм мәхәлләгез тормышына файда китерә алган вәгазьләр алар — нәкъ менә үзегезне күбрәк ачкан, күңелегез аша үткәргән шушы вәгазьләр. Алар — сезнеке, алар сезнең акыл көчегез, иҗат дәртегездән туган «балалар». Башка кеше фикереннән туган вәгазь, чыгышлар инде тотылган кием, кабат җылытылган ризык кебек тоела. Яшьләргә һәм сукырларга сәләтле гыйбадәтханәләргә бөреп кереп, кешеләрнең күңеленә үтеп, аларны бөркет сыман күкләргә күтәрелергә кыюлыкларын арттырып, максатларына омтылдыручы вәгазьләр генә аны сөйләүче кешенең тормышчан көчен, ихлас илһамын сеңдереп туган чын вәгазьләр.

(Дәвамы бар).

Текст төзелеше турында

КДУ доценты, филология фәннәре кандидаты В.Гарифуллинның «Газета текстының төзелеше» дигән монографиясендә (Татарстан китап нәшрияты, 1995) газета текстларының оешу механизмы өйрәнелә. Журналистик-публицистик стиль татар теле белемендә беренче тапкыр текст теориясе яссылыгында анализлана. Нәтиҗәдә газета текстының оешуы процессына йогынты ясаучы телдән тыш факторларны да исәпкә алу мөмкинлеге туа.

Хезмәтнең фәнни редакторы — академик Д.Тумашева.

Китап телче-филологларгагына түгел, барлык китап сөючеләргә дә кызыклы, файдалы булыр дип уйлыйбыз.

И.МАЗИН.

Вакытлы чыккан сүзлек

Г.Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм тарих институтында республикабызда телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру буенча Дәүләт программасын үтәү уңаеннан күп кенә телара сүзлекләр әзерләнеп, нәшриятларга тапшырылды. Кайберләре инде чыга да башлады. Күптән көтелгәннәре, җәмәгатьчелек игътибарын шундук җәлеп иткәннәре арасында профессор Ф.Ганиев җитәкчелегендә төзелеп заманында нәшер ителгән «Татарча-русча сүзлек»нең кабат бастырып чыгарылганы да бар.

Сүзлекне төзүчеләр: И.Абдуллин, Ф.Ганиев, М.Мөхәммәдиев, Р.Юналиева. Нәшрият мөхәррирләре — Д.Шакиров, Р.Юнысов.

Сүзлекнең төп кыйммәтен тарихилык принцибына тугрылык, актуальлек һәм телнең функциональ үсешен киңәйтә алуы ноктасыннан бәяләргә кирәк. Кыскасы, бу сүзлек тә киң катлам укучылар, студентлар, укытучылар, гомумән, барлык тел сөючеләрнең яратып файдалана торган китабына әйләнер дип өмет итәбез.

М.ХӘЙРУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Сукыр тавыкка...

Беркөнне Әфган телевизион марафоны тапшыруында бер язучыбыз әйтте: «Бәхетебезгә каршы, без булачак изге урында басып торабыз. Әфган сугышында үлгән каһарманнарыбызга, шәһитләргә биредә һәйкәл куелачак. Чечняда үлгән шәһитләргә дә һәйкәл куярга туры килачәк», диде.

Ачыклыйк әле, кем ул шәһит? Чечняда шәһит киткәннәр — бары тик чичәннәр үзләре генә: алар деннәре, теле, җире өчен һәлак була. Әфганнар үзләре шәһит, анда үтерелгән урыс, татарлар шәһит түгел. Баскынчы.

Аннары, аңлашылмады: язучыбыз һәлак булганнар өчен һәйкәл салынганга сөенәме, көенәме? Сөенсә — бәхетебезгә күрә, көенсә — бәхетебезгә каршы, дияр иде.

Язучылар үзләре дә тоемламагач, безгә ни кала? Газитләрдә, радио, телевидениедә дә иске сүзләрне урынсыз куллану тулып ята. Тәкбирне тәгъбир диләр, эчеп үлгән дә — шәһит, Казанны саклап һәлак булган да шәһит яисә шаһит.

Сукыр тавыкка бар да бодай, дигәндәй, газитләргә охшаган да, ошаган да; осталык та, остазлык та — бар да бер. Шагыйрьләр шигырьне тудыралар, сүзне каядыр алып баралар. Элек кенә ул майны язалар, шигырьне язалар яисә иҗат итәләр, җырны, көйне, бәетне чыгаралар, сүзне сөйлиләр иде.

Болай да гарип телебезне тәмам бетерәбез бит! Минем гомергә ана телем җитте анысы, ә минә сезнең гомергә җитәрме?

Шаһимәрдән САФИН.
Казан шәһәре.

ЭТИМОЛОГИК ТАБЫШЛАР

Җар

Татар теленең Урал алды сөйләшләрендәге **җар** — табигатькә мөрәҗәгать такмазасы (мәсәлән, Кояш, чык, чык, чык, Синең җылың бик тансык. Майлы ботка бирермен, Тәти кашык бирермен, Майлы ботка — казанда, Тәти кашык — базарда... һ.б.) бик борынгы рухани һәм социаль-сәяси термин. Борынгы-борынгы заманнарда бәндәләр, табигать көчләренә мөрәҗәгать итеп, аларның рәхим-шәфкатен яулап була, дип уйлаганнар.

Хәзерге төрки телләрдә **җар, йар,** монгол, бурят, калмык телләрендә **дзар, зар** «яңа хәбәр, кычкырып әйтелгән игълан, суд карары, указ» (шулай ук, фигыль нигезе буларак, **җар-мак** «кычкырып игълан итмәк, ярып салмак») мәгънәсендә.

Җар (татар әдәби телендә бу сүзне, яр дигән тагын ике омоним сүздән аеру өчен җ белән язу хәерле) нигезеннән бездә **җар салу** «сөрән салып, каты кычкырып игълан итү», **җар итү** «барча кешегә мәгълүм итү, хәбәр тарату», **җар чыгару** (М.Гафуридә) «указ чыгару, әмер-боерыкны бөтен ил-көнгә җиткерү», **җарлау** «кычкырып белдерү» дигән сүз вә тәгъбирләр таралган. Элегрәк **җарчы** «кычкырып игълан итүче» сүзе дә кулланылган. Төрки дәүләтләрдә суд хөкеме тик уңай, гаепләнмешне аклау рухында булса гына кычкырып игълан ителгән **(җар ителгән)**. Шунлыктан **җарлык, ярлык** «кичерү карары, амнистия» мәгънәсен алган. Бу нигездән инде **ярлык-а-у** «официаль амнистия» сүзе ясалган.

Җәмәгать, җәмәги, җәмгыять һәм җомга

Бу сүзләрнең гарәп телендә бер **җмг** «җыелу» тамырыннан булуы күпләр өчен сер түгелдер. Шулай ук **иҗтимагый** сүзенең дә шул тамырдан шытканы әллә ни яңалык түгел.

Мин биредә тик шул мәсьәләне генә куймакчы булам: нигә без **җәмәги** сүзен «община» мәгънәсендә кулланмыйбыз икән. Югыйсә күп кенә язмаларда авторлар шул **община** сүзенә тотынырга мәҗбүр.

Җәң һәм җанфарман

Иске татар язмаларында **җәң** «бер тапкыр сугышу, бәрелеш» сүзе кулланыла. Бу сүз **җәнҗал** сүзе составына, тәртибенә дә кергән: **җәнҗал, җәңҗал** ул фарсыча җәңү-җәдал (бәрелеш-ызгыш) сүзеннән кыскарган (соңгы компонент татар сөйләшләрендә **җәдәл, җәдәлләшү** сүзләрендә дә күренә).

Безнеңчә, татарча **җанфарман** сүзе дә элекке **җәң фәрманы** «сугыш башлану фәрманы» сүзеннән килә: мәгълүм ки, сугышта тизлек күп нәрсәне хәл итүчән. Шуңа күрә сугышка бәйле хәбәрләрне мөмкинчә тизрәк, ашыгычрак күндергәннәр.

Хәер, **җанфарман** сүзенең башкача (фарсыча) аңлатмасы да бар: «җанны бәреп булса да» дигән сүз, имеш.

Р.ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы.

ЯҢАЛЫК! ЯҢАЛЫК!

УРТАК НИГЕЗДӘ

23-25 ноябрьдә Шымкент шәһәренең Х.А.Ясәви исемендәге Халыкара Казах-төрек университетында «Төрки тел терминнарының компьютер фонды» дигән халыкара конференция булып узды. Бу конференция Казахстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, математика профессоры, академик Калдыбай ага Бектаевның тууына 75 ел тулу уңаеннан үткәрелде.

Конференция эшендә Төркия, Казахстан, Үзбәкстан, Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург галимнәре катнашты. Алар арасында танылган академиклар, профессорлар, төрки республикалар югары уку йортларының доцентлары, укытучылары бар иде. Татарстаннан «Ясалма акыл» лабораториясе мөдире Җ.Сөләйманов, КДУның механика-математика факультеты доценты Р.Якушев һәм КДУның татар теленә өйрәтү кафедрасы аспиранты Л.Ризванова конференциядә чыгыш ясадылар, татар терминологиясен стандартлаштыру өлкәсендә булган тәҗрибә белән уртаклаштылар.

Л.РИЗВАНОВА.

БҮЛӘККӘ — ИСЛЕМАЙ

Күптән түгел Актерлар йортында француз телендә шигырь сөйләүчеләр конкурсы булып узды. Аны Лореал фирмасы, Франциянең Татарстандагы вәкиллеге оештырды.

Конкурста катнашучылар арасында КДУ хезмәткәрләре, студентлар, милиция мәктәбе һәм Суворов училищесы укучылары бар иде.

Шигырьләрне французча иң яхшы сөйләүчеләр дип КДУның фәнни хезмәткәре Елена Шевченко, Казан педагогия университеты студенты Олеся Плетенникова, Суворов хәрби училищесы укучысы Искәндәр Мөбарәкшин билгеләнде.

Л.ФАЗЛЫЕВА.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

ДЕКАБРЬ. Рим календаренда унынчы ай булып теркәлгән декабрь исеме латинча **december (decem** — дэсять (ун). Борынгы грек теле аша славяннарга керә. Калын а нечкәрә, я булып әйтелә башлый: **декябрь, декебрь.** Шул ук вакытта урысларда к калын әйтелгәнгә, язылышы да **декабрь** булып китә.

И туган тел...

1995 ел
22 декабрь
№ 5 (28)

Беренче кар
(Өзек).

Төн буена туктамастан
Тышта ап-ак кар ява.
Капланып кырлар, болыннар,
Җир йөзе ап-аклана.
Ниндәен тиз үзгәреш бу!
Ниндәен тиз алмашу! —
арба урынында бүген
Кошлар кебек чана чаба.

Шул вакыт бер яшь бала,
Йокысыннан уянып,
Тышка таба күзне сала.
«Кар явадыр, кыш була!» — дип
Кычкыра ул яшь бала;
Үз-үзен белми куана,
Кул чаба да шатлана!

Нәҗип ДУМАВИ
1911.

Ил белән сөйләгәннең ирене авыртмый

Яла теле еланнан яман

Киләсе саннарда:

- Туган телне — гамәлгә! Ихтыяҗ турында сөйләшү дәвам итә!
- Тел язмышы — мәктәптә: укытуда яңа таләпләр.
- Тел кабинеты — тәҗрибә, фикер алышу
- Яңа китаплар. Укучы фикере һәм тәкъдиме
- Агач — авыз, балта — тел.
- Хатлар яздым утырып... Аңлашыйк әле...
- Этимологик табышлар
- Мирасыбызны барлыйбыз
- Сөйләмият дәресләре һәм бүтәннәр

Сәхифәнең мөхәррире
Илдар НИЗАМОВ.
Адресыбыз: 420503,
Казан, Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга»,
«И туган тел...»

КИЛӘЧӘККӘ КАЙТУ

Саклəбилəр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борыңгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте)

(Дәвамы. Башы 16 — 20 нче саннарда).

Аннан ул үзенә өстәл китерергә кушты. Аңа сый куелган өстәл китерделәр. Өстәл өстендә кыздырылган иттән башка нәрсә юк иде. е пычак белән кисеп, ул бер кисәкне кабып карады, икенче, өченче кисәкне ашады. Шуннан соң тагын бер кисәкне кисеп, аны хәлифә хәзрәтләре илчесе Сусән әл-Рассигә тәкъдим итте. Ашчылар аның каршына җитез генә бәлекәй өстәл китереп куйдылар. Аларда тәртип шундый — әлтабар үзе кисеп бирми торып, берәү дә ыйга үрелми. Ә инде өлеш чыгу елән кунакка бәлекәй өстәл китереп куялар.

Аннан ул миңа өлеш чыгарды өстәл китерделәр. Миннән соң табар уң ягымда утырган бигә кисеп бирде, аңа да өстәл куйлар. Аннан икенче бигә, өчен- э, дүртенчесенә ит өлеште әркайсына өстәл китерә торлар. Ул шулай ук улларын да ешсез калдырмады. Бу хәл чарылган барлык кешегә дә өстәл терелеп беткәнче шулай дәвам те. Һәркем үз өстәленнән аша-, чөнки уртак өстәл гомумән юк Әмма әлтабар өстәленнән бедә ризык алмады.

Әлтабар үзе тамагын туйдыру лән башкалар ашаудан тукта-, калган ризыкларын үзләре лән алып китү өчен җыеп аллар. Әлтабар иттән соң балдан йнаткан ширбәт китертте, сув дил атала икән. Ул әле кичә нә кайнатылган булганга бик әйт иде.

Менә әлтабар үз савытына эчеек койдырды да аягүрә торып сып:

— Мин бу туйны мәүланым мөиннәр әмире хөрмәтенә оешты- Аллаһ аның гомерен озын сын, — диде.

Бу сүзләрне ишетү белән аның т бие, уллары һәм без аягыбы- торып бастык, бу өч тапкыр атланды, әлтабар өч мәртәбә млек салынган савытын буты. Шуннан соң без таралышк.

Әле без килгәнче үк аның мәсте мөнбәреннән: «Йа, раббым! гар әлтабарының иминлеген ла, гомерен озын кыл», — дип ә укый башлаган булганнар. ны күздә тотып, мин аңа бо дидем:

— Аллаһы тәгалә генә кодрәте сез һәм бердәнбер бөек пади- — мәсҗет мөнбәрендә аңар башка һичкем телгә алына мактала да алмый. Менә си мәүланың, мөэминнәр әмире үзенең Шәрык һәм Гарептәге исап мөнбәрләреннән: «Йа бым! Колың вә җир йөзендәге илең Җәгъфәр иман әл-Мөктә биллахның, мөэминнәр әмиең иминлеген сакла», — дигән ләргә риза булып яши бирә. кадәр хөкем сөргән хәлифә- — аның ата-бабалары да шуэшләгәннәр. Рәсүлебез, Аллагәгалә аны гафу әйләсен: истианнар Мәрьям улы Гайса- мактагандай, мине чамадан күтәрмәгез. Мин дә Аллаһы әләнең колы вә рәсүле генә», — дип әйткән.

Әлтабар миннән:

— Хөтбәне минем исемнән укысыннар өчен ни таләп итәлә? — дип сорады.

Мин аңа:

— Моның өчен синең белән атаңның исемен телгә алу кирәк, — дип җавап бирдем.

Ул:

— Минем атам мөселман түгел иде, шуңа күрә аның исемен мөнбәрдән искә алуны теләмим. Мин үзем дә мәҗүси идем, шул сәбәпле үз исемемне дә телгә алуларын теләмим. Тик син миңа шуны әйт: минем мәүланым, мөэминнәр әмиренең исеме ничек?

Мин аңа:

— Җәгъфәр, — дидем.

Ул:

— Миңа аның исемен алырга мөмкин булырмы? — дип сорады.

— Әйе, мөмкин, — дидем мин.

— Алайса, мин үземә аның исемен — Җәгъфәр дигән исемне алам, ә атамны Габдулла дип йөртербез. Бу турыда имам хатибка боерык бир.

Мин аның үтенечен имам хатибка тапшырдым, ул аның исеменнән: «Йа раббым! Колың Җәгъфәр ибне Габдулланың, болгар әлтабарының иминлеген саклый күр!» — дип хөтбә укуны гадәткә кертте.

Хәлифә хәзрәтләренең хатын укып, бүләкләр тапшырганнан соң өч көн үткәч, әлтабар мине үзенә чакыртып алды. Теге дүрт мең динар акча мәсьәләсе аңа барып ирешкән һәм ул Ибне әл-Фурат утары белән идарә итүче әл-Фадл ибне Муса әл-Насрани аркасында аларның тоткарлануын без тапшырган хатлардан белеп алган иде. Аның тирмәсенә килеп кергәч, Алмыш әлтабар миңа утырырга урын күрсәтте. Аннан соң миңа мөэминнәр әмиренең хатын ыргытты да:

— Бу хатны кем алып килде? — дип сорады.

— Мин, — дип җавап бирдем.

— Монысын да синме? — дип сорады. Миңа исә кабат:

— Мин, — дип җавап бирергә генә калды.

Ул:

— Хатларда телгә алынган акчалар кайда? Аларны кая куйдыгыз? — дип сорады.

Мин аңа:

— Без акчаларны туплап өлгерә алмадык, чөнки бик авыр хәлдә калдык. Вакытыбыз тар иде. Без сезнең җирләргә, төньякка үтеп керү мөкинлеген кулдан ычкындырмас өчен, юлга алданрак чыктык. Ә алар соңрак кузгалырга һәм безне юлда куып җитәргә тиешләр иде.

Әлтабар моңа каршы:

— Дөрес, сез барыгыз бергә килеп җиттегез. Һәм минем мәүланым, мөэминнәр әмире сезгә сарыф иткән әлеге чыгымнар, миңа акча алып килеп, шул акчалар хисабына дошманнарым яһүди-хәзәрләрдән[20] сакланыр өчен ныгытма төзетүгә тотылырга тиеш иделәр. Миңа тапшырган бүләкләргә килгәндә, аларны илчем Баштуг улы Габдулла да исән-имин килеш алып кайтып җиткергән булыр иде.

— Бусы да дөрес, — дидем мин. — Ләкин без дә бик нык тырыштык.

Ул тылмач аша миңа:

— Бу кешеләрне мин танымыйм. Арадан бары тик сине генә таныйм, чөнки башкалар гарәпләр түгел, — дип әйтте. — Әгәр дә мәүланым хәлифә хәзрәтләре, Аллаһы тәгалә аны ярдәменнән ташламасын, син алып килгәнне алар да китерәсен белгән булса, хатын укып минем җавапны тыңлар өчен генә сине монда беркайчан да җибәрмәс иде. Шуңа күрә мин дирһәмнәрне бары тик синнән генә таләп итәм. Акчаларны бир, юкса бик мөшкел хәлдә калачаксың.

Дөресен әйтим, мин әлтабар хозурыннан бик нык куркынган һәм борчуга бирелгән хәлдә чыгып киттем. Олы гәүдәле, көчле тавышлы бу адәм бик нык тәэсир итә, тавышы гүя зур чүлмәк төбеннән яңгырагандай тоела иде.

Тирмәбезгә кайтып керү белән мин юлдашларыма булган өңгәмәне түкми-чәчми сөйләп бирдем. Аларга: «Мин сезне шушы хакта кисәткән идем түгелме?» — дидем.

Шушы хәлдән соң мәзин азан әйткән чакта аның икамәт дип аталган өлешен ике тапкыр кабатлады. Болай эшләү исә хәлифә сараенда кабул ителмәгән. Шуңа күрә мин бу хакта әлтабарга әйтергә кирәк таптым: «Синең мәүланың, мөэминнәр әмире үз мөнбәрләрендә икамәтне бер генә тапкыр әйттерә. Бу сиңа билгелеме?» — дидем.

Шуннан соң әлтабар мәзингә:

— Ул кушканча эшлә һәм каршы килмә, — диде.

Мәзин шактый вакыт үз вазифаларын килешенгәнчә башкарды, ә Алмыш әлтабар һаман саен теге акчаларны искә төшергәләп торды һәм минем белән бәхәсләр алып барды. Мин аны берничек тә өметләндерә алмадым, бу исә аның кәефен бик төшерә, ә миңа гел акланырга, үземне якларга туры килә иде. Бездән акчаларны алуга өметен тәмам өзгәч, ул мәзингә икамәтне икешәр тапкыр кабатларга кушты.[22] Һәм мәзин аны шулай башкарды. Шуны сылтау итеп, әлтабар минем белән кабат бәхәскә кермәкче һәм мөнәсәбәтләрне тәмам бозмакчы иде.

Икамәтнең икешәр тапкыр әйтелүен ишеткәч, мин мәзинне сүгеп ташладым һәм бу эшне тыйдым. Моны белеп алган әлтабар мине һәм юлдашларымны үзенә чакыртып алды. Без җыелып беткәч, тылмач аша ул миннән:

— Мәсәлән, мәзиннәрнең берсе икамәтне бер тапкыр, икенчесе — ике тапкыр әйтте, ди. Аннан соң шуларның һәрберсе халык белән бергәләп дога укыды, ди. Андый намаз рөхсәт ителәме, әлле юкмы?

— Намаз рөхсәт ителә, — дидем мин.

Ул:

— Мөҗтәһидләрнең[23] фикер каршылыгы беләнме, әллә инде аларның уртак фикеренә таянып-мы? — дип төпченде.

— Аларның уртак фикеренә таянып, — дидем мин.

Ул:

— Акчаларны тиешле иясенә кайтарып бирмичә башкаларга тоттырган кеше турында син ни уйлыйсың? Бу вакытта аларга өметләнеп торучылар хәтәр чолганышта, коллыкта яшәгәннәр һәм өметләре акланмыйча калган.

Мин:

— Болай эшләргә һич тә ярамый һәм андый кеше кабахәт санала, — дидем.

Ул:

— Син моны фикер каршылыгы беләнме яисә уртак фикергә таянып, үз-үзеңә ышанып әйтәсеңме? — дип сорады.

— Уртак фикергә таянып, үз-үземә ышанып әйтәм, — дидем мин.

Аннан соң ул тылмач аша шундый сорау бирде:

— Әйтче, әгәр дә хәлифә, Аллаһы тәгалә аның гомерен озын кылсын, миңа каршы гаскәр җибәрсә, ул мине җиңәр идеме?

— Юк, — дип җавап бирдем мин.

— Ә Харасан әмире?

— Ул да юк.

— Бәлки, илләребез бер-береннән ерак торганга һәм ике арада мәҗүси кавемнәр күп булгангадыр?

— Әйе, — дидем мин.

Шуннан соң ул сөйләп китте:

— Аллаһы тәгалә исеме белән ант итәм һәм сиңа шуны әйтәм: үз илемдә яшәсәм дә, мин бер нәрсәдән — үземнең мәүланым, мөэминнәр әмиреннән бик нык куркам. Һәм иң курыкканым — аңа минем турыда әллә ниләр барып ирешәр дә һәм шул сәбәпле аңарда миңа карата нәфрәт уяныр, ул мине каргар һәм, нәтиҗәдә, мин монда һәлак булырмын, ә ул, мәүланым, дөресен белмичә үз дәүләтендә элеккечә яши бирер. Безнең аралар ескиткеч, ерак бит. Ә сез, аның ризыгы белән туенучылар, ул биргән киемнәрне киеп йөрүчеләр, һәрвакыт аны күреп-ишетеп яшәүчеләр — аны алдадыгыз, чөнки боерыгын үтәмәдегез, миңа ул ышандырган ярдәмне күрсәтмәдегез, сез ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне алдадыгыз. Алай гына да түгел, сез мөселманнарның да ышанычын аклый алмадыгыз. Шуңа күрә, бирегә ихлас кеше килмичә, сезне дини җитәкчеләрем дип таный алмыйм. Әгәр дә андый адәм чыннан да килә калса, мин аны үземнең дини җитәкчем дип танырга әзермен.

Шулай итеп, ул авызыбызны каплады, без аңа каршы бер сүз дә әйтә алмыйча авыр тойгылар белән таралышырга мәҗбүр булдык.

Шушы сөйләшүдән соң аның үз-үзен тотышында сизер үзгәрешләр күренде: ул миңа аерым хөрмәт күрсәтә һәм үзенә якынайта башлады. Юлдашларымны исә үзенә якын да җибәрми, ә мине Әбүбәкер ес-Салыйк[24] дип атый иде.

(Дәвамын килесе елда укырсыз).

[20] Хәзәр дәүләтендә бары идарәче катлам гына яһүдләр динендә була.

[21] Алмыш әлтабар илчелек вәкилләре арасында бары тик Ибне Фазлан гына гарәп булып, башкалар фарсылардан тора, дип әйтмәкче.

[22] Икамәт — намазга керешер алдыннан аягүрә торып укыла торган дога. Икамәтне икешәр тапкыр кабатлау — бу очракта сәяси мәсьәләгә әверелә, чөнки болгар әлтабары Багдатка йөз тотмыйча исламның башка мәзһәбенә — Урта Азиягә килеп сыенган була.

[23] Мөҗтәһид — дини мәсьәләләр буенча яңа хөкемнәр чыгарырга хаклы галим.

[24] Әбүбәкер әс-Садыйк — 632-634 елларда хакимлек иткән хәлифә. әс-Садыйк — дөресен сөйләүче.

ГӘЗИТ ҺӘМ УКУЧЫ

Бер күрешү үзе бер гомер

Күптән түгел Тәтеш педагогия училищесы укучылары һәм укытучылары өчен гаять истәлекле, онытылмас вакыйга булды. Бирегә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры килде. Очрашуны педагогия училищесының татар теле һәм әдәбияты укытучылары теләге белән училище җитәкчеләре оештырды.

Ул көнне училищеның актлар залында алма төшәр урын да калмаган иде. Концертка татарлар белән бергә урыслар, чувашлар, мордвалар да килгән.

Сәхнәдән оркестрга кушылып курай моңы яңгырый — «Карурман» көе агыла...

Халыкара «Татар җыры — 93» конкурсы лауреаты, яшь җырчы Рөстәм Закировның оркестрга кушылып татар халык һәм композиторларыбыз җырларын башкаруы һәркемнең күңеленә хуш килде. Шулай ук тамашачылар курай һәм сорнайда уйнаучы Елена Даниловны, биюче Ләйлә Миндубаеваны, концерт алып баручы Камил Камаловны яратып кабул иттеләр.

Сәхнәгә Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиева чыккач, нур өстенә нур иңгәндәй булды.

Шул ук көнне оркестр коллективы районыбызның Келәш авылы халкы белән дә очрашты.

Безгә чын сәнгать бәйрәме бүләк иткәннәргә өчен оркестр җитәкчесе Х.Нигъмәтҗановка һәм коллективка рәхмәтебезне белдерәбез. Зөһрә ханым Сәхабиева сүзләре белән әйтсәк, киләчәктә дә шундый бәхетле очрашулар насыйп булсын.

Н.ГАРИПОВА.
Тәтеш шәһәре.

ТАШ ЕЛАТЫРЛЫК СҮЗ

Бәхетсез исем, бәхетле кибет

Татар теленең яңа сүзләр ясауга мөмкинлеге зур да инде. Әйтик, берәр сүзгә -лык-лек, -нык-нек кушымчасы ялгыйсың да, яңа мәгънәдәге сүз килеп чыга. Мәсәлән, кон-лек, тон-лек, печән-лек, утын-лык, бай-лык, хеерче-лек, шат-лык, кайгы-лык. Нәрсә? «Кайгылык» дигән сүз юк дисезме? Дөрестән дә юк. Ә менә «бәхетлек» сүзе юк дип кем әйтә ала. Сүзлекләргә кермәгәнме? Кермәсә соң? Ул ялгышлык белән язылмый калгандыр. Әгәр андый сүзнең булуына ышанмасагыз, Казанның Совет мәйданына килегез, үз күзегез белән күрерсез. Андагы коммерция кибете маңгаена бу сүз аршинлы хәрефләр белән язып куелган. Хәтта бер генә дә түгел, икә тапкыр. Ә сез юк дисез!?

Шушы мәйданнан ерак түгел, Академик Губкин урамында пилмән белән сыйлый торган туклану урыны бар. Белесезме, аның алтакасына (вывескасына) нәрсә дип язылган? Чеп-чи татарча итеп, «Кафе Пельменная» дигән. Әйе, әйе, нәкъ шулай, ким дә түгел, артык та түгел. Аңласаң аңла, аңламасаң, егыл да ул.

Татар теле болай да бик бай тел. Тик аны тагы да баетабыз дип, алай ук тырышырга кирәк түгелдер инде.

Р.ГАЛӘВИН.
Ә.ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

Һәр адәм баласының, үз туган туфрагыннан башка, үтә нык яраткан тагын берничә аерым төбәге була. Минем күңелгә андый якларның иң якыны — Чирмешән тирәләре. Җәе туры килсә — килмәсә дә, җәйләрен дә, кышларын да сугылырга тырышам мин ул якларга. Беренче карашка, татар көн иткән бүтән җирләрдән әллә ни аерылып та тормый ул: гап-гади урман-кырлар, эреле-ваклы инеш-елгалар һәм, калкулык дип атасаң үпкәләр төсле күренгән, биеклеккә туймаган таулыклар... Хәер, Чирмешән авылының бәр читендә бик борынгы күзәтү кирмәне калдыклары бар һәм шул тирәдән дошманнардан саклану өчен туфрак-таштан өелгән биек вал-ныгытма башлана. Кая кадәр сузыладыр ул — бер Ходай гына беләдер: халык сүзенә ышангандә, Агыйдел ярларына ук барып тоташа, имеш... Әмма минем үземнең җанымның җиденче тамырын чиерткәне — бөтенләй икенче нәрсә. Кем әйтмешли, җир өстендә кеше йөрмәсә, ниемә кирәк ул гүзәлләкләр?! Ул төбәкнең кешеләре үзләренә гашыйк итте дә инде мине (туган җиремдә тиң тапмагандай, шул як кызына өйләнүем дә шуңардандыр). Ару-талуны белми эш союда булсын, муйнак дигән тәшенчәне исләренә дә тә-

Тик хәзер ул аларның барысын... барлап бетерә алмый: бөтен... тар, зилзилә купкандай, Җир... ры өстендә бөтерелеп очкан... аныкылар гына бер урынга б... геп калмаган, әлбәттә: алар да... рлесе-төрле чит-ят җирләргә т... бөртекләре кебек сибелеп б... кәннәр. Уңышларын гына кем... җыя икән? Мин, танышым, ди... дә күптән түгел туган авылын... колхоз рәисе булып эшләгән Ф... руллин Фазыл бине Фәхерр... бине Фәхрулла бине Галиулла... не Мөхәммәдьяр бине Мөхә... тәмин бине Бәшир бине Хә... бине Тәүтил бине Чабак... ны... алдымда тотам. Ни өчен йә... бабасының исеме артыннан... нокта куйдым? Чөнки таныш... ның бик тә тынгысыз җанлы... ләнүчән һәм хәрәкәтчән кеше... нлеген әйбәт беләм: хәрәк... — бәрәкәт — нәселенең та... ларын тагын да төптәнрәк ... рып ятмый микән?

Әмма аның бүген бәйгә... генә дә исең-акылыңны кит... лек: нәсәбенең тармаклары — ...лчә тамырыннан ким түгел.

Галимнәр һәм тикшерүче... гадәттә, күренекле шәхесләр... һәм бигрәк тә ханнарның-па... ларның тайпаларын, фәнчә ... сәк, шәҗәрәләрен эзлиләр. ... күпчак алар тапкан шәҗәр... Фазыл Фәхруллинның тулы...

Ризван ХӘМИД

Татар...

шермичә, кунак-сый итешүдә булсын, оста телчәнлре, конлаштереп, җор-мәзәк, тапкыр сүз әйтешүдә булсын — аларны уздыручылар бардыр барын бу фани дөньяда, әмма минем үземнең андыйларны очратканым юк. Мин хәтта үз якташларымны болай ук күкләргә чөеп мактый алмыйм. Ихластыр! Ә бу искиткеч матур сыйфатлар кешегә ата-бабаларыннан буыннан-буынга мирас булып күчә. Тик соңгы җитмеш-сиксән елда халыкның табигате шулкадәр танымаслык булып үзгәрде ки, без хәзер ат менгә атабызны онытабыз. Татар халкы гомер бакый үз балаларын кимендә җиде бабасын танып белергә һәм аларның хәтерен изге итеп сакларга өйрәтә килгән. Ата-бабасын таныган кеше — тирән тамырлы имән ул. Ә инде безнең кебек каләм тибрәтүчеләрнең үз нәсел-нәсәбен танымавы — профессиональ яраксызлык! Кызганычка, хәзерге буын кемгәдер ачуы чыгып сүгенгәндә генә. «Җиде бабаңны танытам мин синең!» — дип күкрәгән тоя. Танытасың, пычагым, үз тамырыңны таны башта...

Ә менә Чирмешән артындагы Югары Чагадай авылы — хәтере коргаксыган татар җирләрендә үзенә күрә бер оазис саналырга хаклы! Ул авылда яшәүчеләрнең икесенең берсеннән сораштыр — ул сиңа, аз дигәндә, алты-җиде бабасын бәйнә-бәйнә тезеп бирер Минем үземә унлап борынгы бабасын яхшы белүчеләрне очрагырга туры килде. Ә бер танышым, сабыр савытларың молдерәмә тулып ташмаса — үз нәсел-ыруының дүрт йөз иллегә якын кешесенең исемен-җисемен тәфсилләп сөйләп чыга! Сүз бүгенге көндә тереклек итеп яткан туган-тумачалары һәм кардәшләре турында түгел Әйе, аларны яхшы белү дә — намус эше. Монда сүз аның ата-бабалары чорында яшәп, доньядан киткәннәр хакында бара Исән-имин аданашларының да кадерен белә танышым.

мен китереп киткәнче, бер ... тармак хасил итә. Ә аның кулы... өлегә нәсел башы саналган ... нче бабасы Хәсәен картның ... улыннан үрчегән җиде зур ою... барлык ир-атларының исемн... яшәгән еллары һәм кем бул... лыклары теркәлгән тайпа бар... шләп ир-атлар гына кергән ... дигән сорау туарга мөмкин. ... лисең, безнең мөэмин-мөсел... «төркен-җиян, ягъни, хатын... кардәш булмас, җилен аш ... мас», дип аларны нәсел агач... кундыруны кирәксенмәгән. ... лыктан Фазылда ерак әбиләр... рында мәгълүматлар бик сана... гына. Алай да бу бихисап ... урыннары буш калган нәс... чыннан да шактый күп нәрсә... ачыкларга мөмкин. Әйтик, ни... рәк кавем баласы минем т... шым? Тайпа очыннан нәсел ... насы Хәсәенне табабыз: «Хә... бине Тәүтил бине Чабак. Яңа ... морзадан Иске Үтәмеш авы... килеп урнашкан. Калашни... XYII гасырның беренче ярты... да гомер иткән.» Шушы кыска... на мәгълүматка тукталыйк. ... гае торыпшадай киң булмага... ше дә моннан берничә кызы... тиҗә чыгара ала: Х... 1600-1650 елларда яшәгән ... димәк, Чабак белән Тәүтил К... патшалыгы исән-имин чакта ... реклек иткәннәр була. Һәрх... Чабак бабай үзе Казанның ... релүен күргән булырга тие... лимнәр буын алмашынуын 30 ... тиңлиләр. Алар хакында бүт... гълүмат юк, калдырып то... Ә варислары Хәсәен — Кала... ков фамилиясе йөрткән. (Ә... эчендә генә әйтеп үтим, мин ... бу фамилияне урысларнык... белә идем. Мәсәлән, бөтен д... ны канга батырырга ярдәм ... автоматны уйлап табучы м... Калашников бар, әллә сон... тәнендә дә татар каны а... Безгә әлегә икенче ягы мө... чорларда татарлар фамили... маган, аларга аны урысла... кан. Кемнәргә? Урыс патша...

на хезмәткә ялланган морзаларга һәм башка йомышлы татарларга. Хөсәен Калашниковның уллары Берки, Яһүд, Бәшир, Әмир, Зәбир, Зөлкәрнәйн һәм Рамазаннар да шул фамилияне йөрткәннәр. Тайпада күренгәнчә, Хөсәеннең оныкларында фамилия юк. Ике буын йомышлы татар булган булып чыга (морзалар да «йомышлы татарлар» дип аталган). Билгеле булганча (мәсәлән, Казанда басылган «Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов» дигән белешмә — китапта шундый мәгълүматлар бар), йомышлы татарлар гади кара халыктан җыелмаган, аларга шактый зур җирләр бирелгән, казнадан заманына күрә күләмле генә акча даими түләнгән. Тайпаны игътибар белән карасаң, Хөсәеннең оныклары-туруннары арасында күренекле байлар, киң колачлы эре сәүдәгәрләр, имамнар һәм муллалар табыла. Кайберләре мәчет-мәдрәсәләргә күп кенә акчалар да багышлаган. Шулай булгач, Фазылның иң ерак бабалары да суган суы суыручы ярлы-ябагайлардан түгелдер: атаң ташчы булса, кулыңа мастерок тотасың. Ә без Төүтил белән Чабакның варислары «мастерок» тотмаганнарын күрдек. Монда нидер гөман итеп кенә карарга мөмкин. Танышымның үзе өчен генә әйтеп үтим: ниндидер

Җ ИДЕ БУЫН ЯДКАРЕ

кырык ир җәмәгате Югары Чагадай авылына нигез сала, кырык ир җәмәгате Иске Үтәмешнең үзендә кала.

...Бу бөек бабаларыбыз гаять тә һиммәтле, батыр эш алып барганнар, күп кенә истәлекләр калдырганнар. Күчеп килгәч тә, алар иң башлап урман-кырларга, инеш-елгаларга, күлләргә һәм тауларга матур-матур исемнәр кушканнар: Чагадай елгасы, Әчеле елгасы, Улаклы тау елгасы, Торна күле, Ардуан киләге (киләк — умарталык корырга махсус бүленгән урманлы-аланлы җир. — Р.Х.) һәм башкалар... Югары Чагадай авылына 16 төп нәсел нигез салган... Әгәр дә игътибарлап уйлап карасаң, бу схемаларны син дә хәтереңә салырсың, бу фәни дөньяның үзеңнән дә узуын аңларсың. Хәниф Вәлиев. Язылды 1947 елда, апрельнең җидесендә.» Һәм шушы сүзләрнең авторы, бисмилласын укып, тиңдәше булмаган эшкә тотына. Максаты — Югары Чагадайда яшәгән бөтен авылдашларының нәсел агачларын, гади халыкча әйткәндә, тайпаларын төзеп бирү. Күз алдына китерегез: канкойгыч сугышның

ниф Вәлиевич 1903 елда элекке Самара губирнасы, Бөгелмә өязе, Мордва Афонькин волосте, Югары Чагадай авылында крәстиән хуҗалыгында дөньяга килгән. Әткәсе Җәлалетдин углы Мөхәммәтвәли, әнкәсе — Иске Үтәмеш авылы Ишмөхәммәд углы Ханый Хәсәншасының кызы Миңнегаян... Яшь вакытында әткәсе-әнкәсе тәрбиясендә үсә. Югары Чагадай мәхәлләләрендә төрле имамнарда 1910-21 нче елларда укып, белем ала. Солдаттан елын тутырып кайткач, 1931 елга кадәр игенчелек итә. Аннан соң вафатына чаклы (1959) тире-йон, дару үләннәре җыючы була. Халык арасында зур абруй казана: бакчачы һәм умартачы һөнәрләрен үзләштереп, Югары Чагадайда бик күп җиләк-җимеш, яшелчә бакчалары, умарталык киләкләре оештыра.» Бар билгеле булганы шушы... Юк, тагын бер нәрсә әйтелми калган икән: кулъязмага караганда, ул шигырьләр дә язгалаштырган. Үз нәселенең тайпасы зур түгел, аларның нәсел агачының иң беренче үсентесен XYII гасыр азагында, XYIII гасыр башларында яшәгән Мөхәммәтәмин бабалары уты-

ган шәҗәрәләрне ул, кадерләп җыеп, китап сымак итеп төпләтеп ала һәм 300 экземплярын халыкка өләшә. Кулъязмаларның тузан эчендә аунап, юкка чыкканы азмыни?! Шуңа күрә Югары Чагадай халкы Хәниф абзый Вәлиевнең якты истәлеген олылап саклау белән бергә, Фазыл Фәхруллинга да чын күңелдән рәхмәт әйтә. Бу җыентыкка, Хәниф абзый төзегәннәрдән тыш, тагын бер зур нәсел шәҗәрәсе кушылган. Барлыгы — 59 шәҗәрә! Һәм шуларның кайберләрендә йөздән артык исем бар! Җыентык-альбомның тагын бер яхшы ягын әйтеп үтәргә кирәк: хәзер һәркем аңа үзе яңа мәгълүматлар өсти ала — андый мөмкинлек тә каралган. Танышымның шушы изге эшкә алынуының тагын бер сәбәбе бар: Хәниф абзый ике ояны туганлаштырып киткән икән — аның хатыны Мөнәвәрә апа Фазылның турыдан-туры алтынчы бабасы Бәшир бине Хөсәен нәселеннән чыккан кыз булган.

Әнә шундый-шундый әкәмәт эшләр кылып яталар Чирмешән артындагы Югары Чагадай кешеләре, ягъни мәсәлән, танылган җырчы Искәндәр Биктаһировның авылдашлары.

Тайпасын таныймы?

тарихи китапларның берсендә миңем күзгә «Чабак морза» дигән исемнең чалынганы бар иде. Һәм ул исем нәкъ Казан ханлыгы җимерелгән чорларга караган хезмәттә иде булса кирәк. Җитдирәк сүзгә күчкәндә, Чабак бабасының теге тарихи шәхескә берниндиндн катнашы булмавы ачыкланган очракта да шәҗәрәнең тулылануы мөһим бит. Чабак картның өулад-токымнары барлап бетергесез — арада күпне белергә тырышучан тынгысыз йөрәкләр табылмый калмастыр. Фазыл танышымның, аданашларыннан башка, үзенең бертуганнары гына да алтау: берсе Казан янындагы бройлер чебешләре фабрикасы директоры, икенчесе — Большие Ключи совхозы директоры, арада укытучылар, табиблар бар. Берсе дә төшеп калганнардан түгел: нәсел нәселгә йога, диләр бит. Кайбер туганнары пенсиядә, үз оныкларын үстереп яталар. Димәк, алар Фазылдан да күбрәк — турыдан-туры 11-12 ата-бабаларын танычак. Менә аларны җиде бабаңны танытам, дип куркытып булмаячак инде!

Ә хәзер газит укучыларга бер зур серне ачам: бу искиткеч күп хезмәт таләп иткән тайпаны... Фазыл Фәхруллин үзе төземәгән. Нишләп башыбызны катырасың алайса, дип гаҗәпләнергә ашыкмагыз, зинһар. Аның да роле бик зур монда! Укучыдан сабырлык үтенеп, тагын бер кат өлеге кулъязма «документ»ка мөрәҗәгать итик (авторның стиле, җөмлә-сүз төзелеше бераз саклана һәм кыскартып бирелә): «...16 нчы гасырның өченче чирекләрендә Яңа Шәйморза авылыннан Иске Самара губирнасы, Бөгелмә өязе, Мукшы Кармала волосте, Иске Үтәмеш авылына бертөркем татарлар күченеп килә. Халыклар үрчеп, ирләр җәмәгате 120 җанга җиткәч, 17 нче гасырның дүртенче чирекләрендә, Иске Үтәмеш өчкә бүленә: кырык ир җәмәгате Урманасты Үтәмеш авылын оештыра,

беткәненә ике ел да узмаган, хәерчелеккә төшкән йот заман, күпләрнең кайгысы — ничек тә башны ач үлемнән саклап калу. Күпләрнең күзләрендә — кан-яшь: якын туганнарын, ирләрен, аталарын-улларын сугыштан көтеп ала алмаганнар, ә кемнәрдер һаман да нәрсәгәдер өметләнеп фал ачтыра. Шәҗәрә кайгысымы? Хәниф абзый белә: авылның иң гаярь ирләре сугыш кырларында башларын салса, аларның ата-бабалары оныклары матур яшәсен өчен озын тарихта тагын да күбрәк корбан биргәннәр — боларны авылдашлары яхшы белергә тиеш! Аларга авыр кайгылардан бөгелеп төшәргә һич ярамый, ата-бабалары зур корбаннар биргәнгә дә, үзләре шушы көнгә кадәр, яхшымы-яманмы, тереклек итеп киләләр ич! Бабайларның изге рухлары хөтерле булуны таләп итә, өуладларын буыннар чылбырын өзәргә ирек куймаска өйрәтә, сез затсыз-нәселсез һәм төлсез хайваннар түгел — башларыгызны югары күтәрегез, үткәннәрне яхшы белсәгез, киләчәккә дә ышанычлы өмет белән карарга кыюлыгыгыз җитәр, ди! Мин гап-гади авыл крәстияненең сукыр лампа яктысында (чынында менә сүнәм, менә сүнәм, дип торган каен чырасы уты бәләндер) кара төннәр буе баш күтәрми иске кәгазьләр актарып утыруын күз алдыма китерәм. Көндезләрен аның андый мөмкинлеге булмаган, чөнки җан асрау кайгысын кайгыртасы бар... Хәниф Вәлиев төзеп калдырган тайпаларга кергән исемнәрне генә санап карадым — сабырлыгым төкәнеп, кул селтәдем: меңнәрчә һәм меңнәрчә исемнәр аталган анда! Бу — чын мәгънәсендә фидакарь хезмәт, моннан соң бер генә Югары Чагадай кешесе дә үзен кимсенүле бәндә итеп сизмәячәк!

Кем булган соң ул — Хәниф Вәлиев дигән кеше?

Шул ук кулъязмада өстәлгән аңлатмага сүз бирик: «Вәлиев Хә-

рткан икән. Танылган сәүдәгәр булган, биш угыл үстергән. Хәниф абзыйның тулы исеме Хәниф бине Мөхәммәтвәли бине Җәлалетдин бине Мөхәммәтәмин. Димәк, Хәниф үзе — нәсел башының туруны гына. Дөрес, ул Мөхәммәтәминнән өулад тайпасын мөмкин кадәр тулырак эшләргә тырышкан, хәтта, мөселман гадәтенә иярмичә, нәселдә булган барлык хатын-кызларны да җыйган. Ләкин шулай да үзенең нәсел агачы Фазылныкы янында — түбәсе күккә тигән биек кәүсәле, гигант ябалдашлы имән янәшәсендә үсеп утырган кечкенә куак кебек кенә. Аларны чагыштырып караганнан соң, Хәниф ага Вәлиевнең нинди риясыз һәм үз-үзен аямаучы фидакарь җанлы кеше булганлыгын тагын да ныграк аңлыйсың...

Хәзер укучыны сөерсендергән серне бөтенләй ачып бетерергә вакыт җитте: әгәр дә Югары Чагадайда Ф.Фәхруллин дигән кеше булмаса, бу гаҗәеп зур әһәмияткә ия кулъязманың дөньяда булганын да белмәс идек, мөгаен: Хәниф абзый Вәлиев төзеп калдыр-

Озынгарак киткән сүзебезне йомгаклап, нәрсә диик? Безгә, илебезне кайчандыр дер калтыратып торган кавказлы мыеклач сүзе белән әйткәндә, «завидевать итәргә генә» каламы? Әллә Югары Чагадай кешеләреннән үрнәк алып, «сәвит инкубаторы чебешләре» булмавыбызны үзебез өчен генә булса да исбат итәргә керешергәме? Икенчесе — мәгънәлерәк юлдыр.

Соңгы елларда бик күпләр үзләренең затлы нәселдән чыкканлыгын исбатлау өчен хәтта тиреләреннән ярылып чыгарга әзер. Борынгы аксөяк токымы булу — зур дәрәҗә бит хәзер. Моның өчен әсмыйлар да, кисмиләр дә хәзер мыеклының опричниклары. Ләкин бит Кеше дигән дәрәҗә сөяк төсе белән бәяләнми: үз затыңны онытма — затсыз булмассың. Беребез дә юктан бар түгел: бабаларыбыз ахыры килдек без бу якты дөньяга. Булмаган татар гына тайпасын корыта...

Фәнис ЯРУЛЛИН

Күңелебез кыңгыраулары тутыкмасын

(Ахыры. Башы 10 нчы биттә).

Хәзерге вакытта мин 14 катлы кирпеч йортның өченче катында ике бүлмәле фатирда яшим. Һәрвакыт эшләмәсә дә — йортта лифт бар. Ул яктан аллага шөкер. Дәүләт эшлеклеләре яшәүче өч метр биеклектәге ялан кадәр бүлмәләрдән торган булмаса да, фатирдан зарланмыйм. Алты бала бер сөкедә йоклап үскән малай бит мин. Мәсьәлә икенчедә. Безнең элек тә өчебезгә (әни, хатын, мин) ике бүлмәле фатир иде. «Хрущевка» дигән панель йортта ике бүлмәле фатирда 19 ел яшәдек без. Һәм унтугыз ел буена мин аны лифтлы, телефон кабеле кергән йортка алыштырырга йөрдем.Язучылар берлегендә шушы чор эчендә әллә ничә рәис алышынды. Мин кая гына язмадым — файдасы булмады. Хатыным икенче каттан ничәмә-ничә еллар (әле башта бер бүлмәледә 9 ел яшәдек) мине күтәреп төшерергә, күтәреп менгерергә мәҗбүр иде. Ә бит, бер уйласаң, күп тә сорамыйбыз — ике бүлмәле фатирны бары тик лифтлы ике бүлмәлегә алыштыру турында гына сүз бара иде. Ниһаять, Туфан Миңнуллин Язучылар берлегендә эшләгәндә бу бозны бер кузгатып куйды. Ләкин ул да: «Слушай, түлке шундый шарт белән центр-ментрдан дип сөйләшү юк. Каян бирсәләр — шунда барасың», — диде.

Минем, әлбәттә, чистарак һавалы районда театрлар тирәсеннән, кыскасы, шәһәрнең үзәгеннән аласым килгән иде. Драматург та бит әле мин. Яңа пьесалар буенча куелган чакта бу мине тыңламый ахры, дисәң, онытканда бәрәр сүз әйтеп куя иде. Әмма соңгы көннәргә кадәр акылы сәламәт, зиһене якты, хәтере нык иде. Хәтта берәр мисал китерергә кирәк булса, китаплар актарып тормастан, әсәрдән өзекләрне хәтердән әйтеп бирә ала иде. Мин аның белән соңгы тапкыр май ахырларында сөйләштем.

— Ибраһим абый, — дидем, — мине авылга Сабан туена чакыралар. Үзең генә кайта алмасаң, килеп алабыз, диләр. Кайтыйм микән?

Ул, гадәтенчә, телефон трубкасына тирән итеп сулап торды. Аннары: «Болай зурлап чакырганда кайтмыйлармыни? Ә мене мине беркая чакырмыйлар. 70 еллыгымны да зурлап уздыручы булмады. Дөрес, үзебезнең Ульян ягында чыга торган «Өмет» гәзите һәм мондагы басмалар берничә мәкалә бирделәр. Әмма чакырып зурлаучы юк. Хәзер инде машинада үзем йөри алмыйм. Туган якларга кайту булмас. Аннары «Запорожец»ым да бик тузды. Аның белән юлга чыгарлык түгел», — дигән иде.

Әйе, Бөек Ватан сугышы һәм Совет армиясе инвалидларына бушлай «Запорожец» автомобиле бирәләр. Җиде ел вакытка. Әмма аларның һәммәсе диярлек базада чагында ук ватык була. Күбесе заводтан ук дефект белән чыга. Инвалидка ярамаган тагы, дипме, бушлай булгач алмый хәлләре юк, дипме — кыскасы, бу машинаны алып кайткан көннән башлап төзәтергә, җитешмәгән җирен җиткерергә кирәк була. Әлбәттә, инвалид машина карау кебек эшләрне үзе эшли алмый. Автомобиль алу белән ул оста эзли башлый, вакытын һәм акчасын түгә. «Запорожец» машиналарында совет чынлыгы үткән инвалидлар гына йөри ала. Таза-сәламәт кеше аңа әйләнеп тә карамый. Хәтта шундый мәкаль бар: «Ишәк ат түгел, «Запорожец» машина түгел».

Ниһаять, Советлар Союзы таркалгач, бу үләт арбасы — «Запорожец»ларны чыгармый башладылар. Инвалидларга аның урынына «Ока» яки «Таврия» машинасы бирергә дигән карар чыкты. Шушы карардан соң Ибраһим абый миңа сөенеп шалтыраткан иде:

— Фәнис энем, миңа «Таврия» бирәләр. «Запорожец»ымның әле җиде елы үтүен-үтмәгән иде. Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать иткән идем, бернинди волокитасыз, срогыннан алда «Таврия» бирергә дип Социаль тәэминат министрлыгына язу җибәрделәр. Сиңа да, Фәнис, «Таврия» сорарга кирәк. Синең хәлең минекеннән дә авыррак бит, — диде ул.

Мин бу мәкаләне язган вакытта, инде Ибраһим абый мәрхүм булгач, аның җәмәгате Розалина апага шалтыраттым.

— Ибраһим абый теге вакыт миңа әйткән «Таврия»сен ала алдымы? — дидем.

— Юк, машинасын ала алмады, — диде Розалина апа. — Ләкин монда Социаль тәэминат министрлыгының гаебе юк. Ибраһим «Ока» алырга теләгән иде, ләкин ул исән чагында «Ока»лар кайтмады.

Миңа ничектер моңсу булып китте. Кеше кадерен белмибез шул. Хөрмәткә иң лаеклылар тиешле бәяне алмыйча дөньядан китә торалар. Һаман да безнең татарлыгыбыз комачаулый, ахры.

Ә бит урыслар үзләренең талантларын кадерли беләләр. Нинди авыр 30 нчы елларда яшәп иҗат иткән Николай Островскийга Сочида аерым йорт салып бирәләр. Үзен йөртер өчен персональ машина һәм шофер билгеләләр. Әсәрләрен машинкада басар өчен махсус секретарь беркетәләр. Аларның барысы өчен хөкүмәт түли.

Яки менә алай ерак булмаган чордан бер мисал. Урысларның Владислав Титов дигән бер язучылары бар иде. Заманында ул шахтада эшләгән. Шунда авариягә эләгеп, ике кулсыз калган. Һәм язмышына буйсынмыйча, кәгазьне стенага беркетеп, авызына каләм кабып, күңелендә булган хис-кичерешләрне хикәяләргә, повестьларга әверелдерә башлаган. Дөрес, аның таланты бик уртача иде. Әмма аңа вакытында ярдәм иттеләр. Чит илгә җибәреп, протезлар ясаттылар, акча түләп, хатынын үзенә секретарь итеп беркеттеләр, протез кул белән язарга җайлаштырылган махсус язу машинкасы, шулай ук махсус телефон аппараты эшләттеләр. Язарына азык булсын өчен чит илләргә командировкаларга йөрттеләр. Болар бит барысы да каргалган «торгынлык» елларында эшләнде.

Инде хәзер үземнән бер мисал. Бервакыт мин Язучылар берлегенә болай дип мөрәҗәгать иткән идем: «Минем хатыным Нурсоя Яруллина, мине карап тору сәбәпле, производствода эшли алмый. Шуңа күрә аның эш стажы бармый. Ә бит киләчәктә аның да пенсия алыр вакыты җитәр. Гомере буе авыру карап, картлык көнендә бер тиенсез калса, никадәр кыен булачагын үзегез беләсездер. Мин сездән күп сорамыйм: минем хатынымны шәхси секретарем итеп рәсмиләштереп булмыймы? Мин акча да, башка берни дә таләп итмим — бары тик аңа стаж гына барсын иде. Дөресен әйткәндә, ул болай да минем барлык язганнарымны машинкада баса, газета-журналлар, нәшрият өчен әзерли. Ә миңа боларны эшләү авыр».

Минем бу үтенечемә рәсми җавап та бирүче булмады. Үтенечем язучылар оешмасына барып җитмәгән дип уйлар идем, бервакыт бер каләмдәшем мондый бер «акыллы» киңәш бирде: «Авыр булгач, нигә язасың, сиңа кем куша? Ят өеңдә тик кенә!»

Язмам шактый озынга китсә дә, тагын бер-ике нәрсәгә кагылып үтмичә булмый. Чөнки алар минем йөрәк яраларым. Берсе шуннан гыйбарәт: моннан дүрт-биш ел элек, әлеге дә баягы, шул каргалган «Запорожец» белән дачадан кайтканда безне бер «КамАЗ» машинасы бәреп качты. Безнең машинабыз, мәтәлчек ата-ата, юл читендәге агачларга килеп бәрелде. Үзебез ниндидер могҗиза белән генә исән калдык. Ә машинаны төзәтерлек түгел иде. Алыштырырга әле өч ел көтәргә кирәк. Шуннан соң мин язучылар оешмасына: «Тулы бәясенә сатып алырга «Жигули» яки «Москвич» машинасы табып бирә алмассызмы?» — дип мөрәҗәгать иттем. Моннан биш еллар элек, машиналарга зур чират иде әле, аларның бәясе 10 мең тирәсе тора иде. Минем аны алырлык акчам бар иде. Хөрмәтле рәисебез: «Фәнис абый, мин сезгә бик ярдәм итәр идем, ләкин хәзер машиналар безнең оешмага бик әз кайта. Менә быел нибары дүрт машина вәгъдә итәләр», — диде. «Шуның берсен миңа сатыгыз», — дидем мин үземнең беркатлылыгым белән. Ә рәис: «Аларны Министрлар Кабинетыннан ук исемләп җибәрәләр: берсе — фәләнгә, икенчесе — төгәнгә», — дип ул дүрт язучының исемен атады. Мин: «Алар сәламәт, үз аякларында йөри торган кешеләр, ә миңа машина — аяк бит ул», — дип үтенечемне нигезләргә тырышып карадым. Ләкин ул, «Алар да язучылар бит», — дип сүзен тәмамлады.

Безнең язучылар оешмасыннан нәрсә көтәсең инде. Алар бит безнең ише урын өстендә ятучы язучыларны 4—5 елга бер булган съездга алып баруны да оештырмыйлар. Мин бу оешмада утыз елга якын әгъза булып торам. Шул вакыт эчендә бары бер мәртәбә — Гариф Ахунов рәис булып эшләгәндә — съездга алып бардылар. Ә узган съездан соң җаваплы бер иптәшкә: «Нишләп мине съездга алып баруны оештырмадыгыз?» — дигәч: «Анда кворум бар иде», — дип җавап бирде. Элегрәк чорларда, өйгә сайлау тартмасын алып килеп, рәис сайлауда булса да катнаштыралар иде. Хәзер алай итеп тә вакланмыйлар. Тагын шул Николай Островскийга әйләнеп кайтыйк: хәтерем ялгышмаса, СССР язучыларының беренче съездында аның үзен алып килергә мөмкинлек булмагач, өенә рация урнаштыралар. Рация аша ул барлык чыгышларны тыңлап ята һәм үзе дә чыгыш ясый. Ә бит техника нинди артта калган заман.

Теләк һәм күңелдә өз генә мәрхәмәт бар икән — эшләп булмастай эш юк. Ләкин үзебезнең бәгырьсезлегебезне күп вакыт заманга, елларның авырлыгына сылтарга яратабыз. Заман әле ул елдан-ел авырая барачак. Нәкъ менә авыр чакларда бер-береңә ярдәм кулы сузу мәслихәт бит. Күп кенә очракларда кешегә матди ярдәм дә кирәкми: аның ялгыз түгеллеген, янында иңдәшләре, фикердәшләре, кирәк чакта таянырга таянычы барлыгын белгертеп торсаң да җитә. Ул үзен кирәкле кеше итеп тоя башлый. Дөрес аңласыннар иде: мин бу язмамны кемнән дә булса үч алу, фәлән-фәлән кешеләрнең йөзенә пычрак ату өчен язмадым. Мин холкым белән үчле кеше түгел. Хәтта үземә этлек эшләгән кешеләрне дә кичерә һәм шул кичерә алуым өчен сөенә алам. Мин бары тик кешеләрнең күңел кыңгырауларына гына кагылырга теләдем. Әгәр кайбер җитәкчеләрнең күңел кыңгыраулары тутыкмаган булса, юк-юк та бер чыңлап куяр. Һәм шулвакыт андый кешеләр: «Туктале, мин һәрвакыт зур постлар биләп утырмам. Дан-дәрәҗә су кебек агып китәр. Бервакыт үземнең дә кешеләр ярдәменә мохтаҗ булуым бар. Шул чакта хезмәттәшләремнең, дусларымның күзенә туры карый алырмынмы?» — дип уйлар.

Бу язмам шундый уйлар уята алса, мин үземне максатка ирешкән дип санар идем.

Гонаһлы генераллар

Анатолий Куликов Русия Федерациясе эчке эшләр министры булып эшли башлагач та, үз аппаратын әхлаксыз, намуссыз кешеләрдән арындыра башлады. Инде узган атнада ук ул шактый югары пост биләгән 12 кешене эшеннән бушатты. Алар — майордан алып генерал дәрәҗәсендәге хезмәткәрләр. Шуларның дүртесе — генераллар.

Җинаятьчелек үссә дә...

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы күргән чаралар нәтиҗәсез калмый. Быел 43 оешкан җинаятьчеләр төркеменең җинаятьләренә чик куелды, бу төркемнәрнең 440тан артык әгъзасы җаваплылыкка тартылды. Республика халкы 229 данә ату коралын һәм шартлаткычны ирекле рәвештә тапшырды.

Гейдар Алиев Милли мәҗлестән канәгать

Әзәрбәйҗанның яңа парламенты — Милли мәҗлескә 8 партиядән 96 депутат сайланган. Шуларның бишесе — шагыйрь, бишесе — язучы, бишесе — академик, егермесе — профессор һәм фән кандидатлары. Җидедән бер өлешен хатын-кызлар тәшкил итә. Әзәрбәйҗан халык фронты партиясеннән сайланган оппозиция дә бар. Гейдар Алиев, бу парламент үз эшчәнлеге белән республиканы кризистан чыгарырга булышыр, дип ышана.

(«Независимая газета»).

Үз-үзен яндырам дип...

Мәскәүнең Газит тыкрыгындагы «Милли кредит» банкына алданган клиент, 57 яшьлек Раиса Уткина килеп керә.Сумкасыннан юан гына тимерчыбык чыгара да, үзен батареяга бәйләп куя. Аннан шешә белән бензин һәм шырпы чыгара: әгәр дә ике мең ярым доллар акчасын кайтарып бирмәсәләр, үз-үземне яндырачакмын, дип кисәтә. Ул узган ел акчасын югары процент вәгъдә итүче «Фаворит» банкына салган була. Әлеге банк таркалгач, аның йөкләмәләрен үтәүне «Милли кредит» банкы үз өстенә ала. Тик вәгъдәсен генә үтәми. Нишләргә белмәгән клиент шундый юлга барырга мәҗбүр була. Милиция һәм банк хезмәткәрләре бу апага бөтен акчасын кайтарырга вәгъдә биреп, аның кулыннан бензин һәм шырпысын алалар, үзен психик яктан тикшерү өчен Склифосовский институтына озаталар.

(«Московский комсомолец»).

Кәфен... гомерне озайта

Күп кенә кытайлылар саванны (кәфен) үзләре исән чакта ук әзерләп куялар. Аны кисеп-тегүне кияүгә чыкмаган кызларга тапшыралар. Алар фикеренчә, кызларның яшәү көче өлешчә саванга күчә дә, заказчының гомере озыная. Аннары саванны кәбисә елда тегәрүне өстен күрәләр: бу да гомерне озайта, дип уйлыйлар.

Хатыннар, туры булыгыз

Мадагаскарда хәрби сугышчыларга кайбер төр азыклар ашау тыела. Мәсәлән, дикобраз итеннән авыз итсәң, аның кебек куркак буласың. Шулай ук үгез тезен дә ашарга ярамый, аны ашасаң, үзеңнең тезләреӊ хәлсезләнә, походларда катнаша алмыйсың. Сөңге кадап үтерелгән телсә нинди терлек итен ашасаң, сугыш кырында ятып калачаксың, дигән ырым да яши.

Көнчыгыш Африкада фил аулаучылар ышануынча, үзләре ауда чакта хатыннары аларга хыянәт итсә, ул ирләр фил һөҗүменнән үләләр.

(«Крис»).

Пәһлеван самавыр

Туладагы «Штамп» заводы осталары дөньяда иң зур самавыр койдылар. Бу 450 литрлы пәһлеван 1996 елда билгеләп үтелəчәк «Самавырның 250 еллыгы»на багышлана. Аның биеклеге — 2 метр, краны 40 сантиметр. Ул Гиннес рекордлар китабына кертелер дип уйланыла. Юбилей пәһлеванның сыйдырышлылыгы 1922 елда шул ук заводта эшләнгән элекке самавырныкыннан 200 литрга артык икән.

Грипп фетнәсе

Русиянең дәүләт эпидемия күзәтчелеге грипп вируслары һөҗүме турында хәбәр итә. Инде Тверь, Самара, Калининград өлкәләрендә, Ташкентта һәм Мәскәү янындагы районнарда грипп белән авыручылар нык арткан.

Мәскәүдә грипп эпидемиясе 15 процентка җиткән. Теркәлгән 126324 авыруның 77833е балалар. Көн саен 42 мең авыру теркәлә. Бу чир сайлауларга да йогынты ясамый калмагандыр.

(«Известия»).

КамАЗ автобуслар заводы да

Яңа елдан «КамАЗавтобуспром» шәһәр эчендә йөри торган зур автобуслар җитештерүгә керешәчәк. 320 ат көчле двигатель куелган бу автобусларга 174 кеше утырып йөри ала. 1996 елда ул 100 автобус эшләп чыгарса, 1997 ел урталарына беренчел җитештерү куәтенә елга 2 мең автобус эшләп чыгару күздә тотыла.

(«Время и Деньги»).

Татар башына — 500 мең франк

Казанда яшәүче 76 яшьлек Әмир Үтәшев Франция хөкүмәтенең ел саен бирелә торган пенсиясен ала башлады. Ул 1943-44 елларда Франциянең Лепю шәһәрендә каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашкан. Немец командованиесе ул чакта «капитан Александр»ның башы өчен 500 мең франк бүләк вәгъдә иткән.

(«Вечерняя Казань»).

Сак булыгыз: юлбасарлар

Түбән Камадан Мәскәүгә бара торган пассажирлар тулы автобус Чаллыны бераз узгач та, дүрт егет мылтык һәм пистолеттан атып, шоферны урманга борылырга мәҗбүр итә. Анда алар бай туристларга әйберләрен чыгарып салырга боерык бирә. Талап алынган байлык 100 миллион сумнарга җыела. «Череп баеган» талаучылар тиз-тиз күздән югала.

Туристларны талау башка юлларда да очрап тора. Хәтта кайчак юлбасарлар милиция киемендә киенеп тә һөҗүм итәләр.

(«Труд»).

«Эшмәкәрләр»... бала сатып байый

Бездә үз баласын багарга теләмичә, бала табу йортларында ташлап калдыручылар күпме? Ә шул ук вакытта үз баласы булмаганнар аны чит илләрдән дә сатып алырга тырыша. Барселона һәм Мадридтан 20ләп гаилә хәйләкәр эшмәкәрләр ярдәмендә Беларусьтан уллыкка һәм кызлыкка бала алганнар. Аларның һәркайсы өчен Көнбатышта 12-40 мең доллар акча түләгәннәр. Чит ил гражданнарына беларусь балаларын балалыкка алу процедурасын җиңеләйтү өчен табиблар аларны чирле сабыйлар дип белешмә биргәннәр.

(«Комсомольская правда»).

Җәяүлеләр гаеплерәк икән

Казанда 10 айда 770 юл һәлакәте теркәлгән. Шулар нәтиҗәсендә 82 кеше үлгән, 772се имгәнгән. Боларның 76 проценты җәяүлеләр гаебе белән булган. Шуңа күрә юл иминлеге өчен көрәшне җәяүлеләр арасында да киң җәелдерергә кирәк.

(«Зилант»).

«Такташ»лар дөнья бүлешә

Казандагы зиратларның берсен яшелләндерүче Владимир Пичушкин, хатыны белән өеннән чыгып, Фучик урамындагы йорты каршында торган машинасына юнелә. Руль ягына кереп, двигателен кабызырга керешә. Шул вакыт аның янына бер хатын-кыз йөгереп килә дә руль артында утырган Пичушкинга ата. Володя шундук үлә. Җинаять урынында 7 гильза, 3 пуля табыла.

Тикшерү нәтиҗәсендә шунысы ачыклана: атучы кеше хатын-кыз түгел, ә кыз булып киенгән «Маймыл» кушаматлы Илдус Әгъләмов булып чыга. Пичушкин да, Әгъләмов та «Такташ» җинаятьчеләр төркеменнән икән. Алар арасында акча һәм йогынты сферасын бүлешкәндә бәхәс чыккан. Ә аны хәл итү өчен бер-берсен үтерү алар өчен табигый эш. Илдус алданрак өлгермәсә, Володя аны үтергән булыр иде, мөгаен.

(«Казанские ведомости»).

Урласалар, яхшырак булыр иде

Ниндидер явыз ниятле кешеләр Тукай районындагы бер совхозның ягулык складына кереп (каравыл куелмаган) А-76 маркалы 20 тонна бензинны (чама белән 30 миллион сумлык) җиргә агызган. Кызык, шулкадәр байлыкны җиргә очыру кемгә кирәк булды икән?

Коралланган һәм бик куркыныч

Казанда яшьләр генә түгел, картлар да тик ятмый икән. Совет районында яшәүче бер пенсионердан «Сайгак» карабины, 8 патроны белән газ пистолеты, 7 ау пычагы, 1 данә «Макаров» патроны, 5,45 миллиметрлы 1 патрон, берничә ясалма ату коралы өчен заготовка алганнар. Боларның хуҗасын күңелсез картлык көтә.

(«Аргументы и факты» в Татарстане).

И, көнчелек!..

46 яшьлек ир үзенең бизнестагы көндәшеннән үзенчәлекле итеп үч ала. Ул Барселонадагы «Хэппи Дак» дигән популяр кафе алдын сагыз белән ябыштырып чыга. Унбишләп малайны яллый да аларга тартмасы белән сагыз бирә, һәм алар ябышкак сагызны кафе алдындагы тротуарга төкерәләр.

Рамоска моның өчен 1500 доллар штраф салалар һәм тротуарны сагыздан чистартырга әмер бирәләр. Хәсетлекнең яман чир икәне күптән билгеле, ул беренче чиратта кешене эчтән җимерә. Бу очракта Рамос көнчелеге аркасында матди зыян да күрә.

Кыйммәткә төшкән бүләк

Сакти, Индия. Региональ сәламәтлек саклау учреждениесе урта яшьтәге ирләргә 20 мең презервативны бушлай тарата. Тик ул бик кыйммәткә төшә — бала табучылар саны чамасыз күбәя. Шаян чиновниклар... һәр презервативның башын тишкән булганнар икән!

Яшел борчак... һәм өзелгән бармаклар

Мерсисайп, Англия. Балта остасы Ронд Голдт бармакларын өздерә. Аның дусты югалып калмый, Рондны яшел борчаклар тутырылган суыткычка сала да хастаханәгә элдерә. Хирурглар аның ике бармагын да ялгыйлар.

(«Всемирные новости»).

(Дәвамы. Башы 15 — 17. 19 — 20 нче саннарда).

Ахшам намазы

Укыла торган вакыты — кояш тәмам батканнан соң, шәфәкъ кызыллыгы беткәнгә кадәр укыла

Иң элек өч рәкәгать фарыз. аннан соң ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә, барысы бергә биш рәкәгать укыла.

Йәсигъ (Йәстү) намазы

Вакыты — кояш тәмам баеганнан соң. шәфәкъ кызыллыгы югалып, иртәнге таңга кадәр вакыт аралыгы эчендә ниятләнеп укыла.

Йәсигъ намазы барлыгы унөч рәкәгатьтән гыйбарәт. иң элек дүрт рәкәгать сөннәт укыла. аннан соң дүрт рәкәгать фарыз. тагын да ике рәкәгать сөннәт мөвәкдә һәм өч рәкәгать витр намазы укыла.

Йәсигъ намазының икенче өлешендәге ике рәкәгать сөннәтне дүрт рәкәгать уку саваплырак санала. Әмма бу вакытта әүвәлге ике рәкәгатьне

тиеш.

Әгәр дә чәче тартылган икән, ягъни үрелмәгән булса, ул вакытта ир кеше шулай ук чәчен юарга тиеш.

Әгәр дә госел коенучы хатынның тырнак астында коры камыр калса, ул вакытта госеле дөрес түгел, кабатлап башкарылуы сорала. Чөнки камыр берара каты булса да, бераздан аңа су үтеп йомшарыр һәм юылыр. Әгәр дә тырнак астында балчык калган икән, ул вакытта госеле дөрес була, чөнки балчыктан су госел коенган вакытта ук үтә. Әгәр дә тырнак астыңа чыраише нәрсә кереп, үзе белән бергә балчык та үткәргән булса, чыра алынып та, тырнак асты каралып, балчыгы калса, госел коенганда тырнак астын каезлап-җимереп су кертеп маташу һич тә кирәкле һәм дөрес эш түгел, чөнки госелең дөрес икәнлеген онытмаска гына кирәк.

Госелнең сөннәтләре

Әгәр дә кече-олы йомышларыңны башкарсаң, алар артыннан ул урыннарны юарга һәм аны ният итеп эшләргә кирәк. Аннан соң намаз

Фәрит ЯХИН

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ

те сөннәт мөтәхибә кылынып. аннан соңгы ике рәкәгатен «Собханәкә » һәм «Әгузе бисмиллаһ.. » белән укырга кирәк. Шул рәвешле алар икешәр-икешәр рәкәгать булырлар. Шулай ук сөннәт һәм нафилә намазлары фарыз намазлары рәвешендә укылырга тиешле. Фарызны бозганнар исә сөннәт һәм нафиләне бозалар. Әгәр дә башка намазларда дүрт рәкәгать бер намаз хисабында йөрсә. йәсигъ һәм икендедә ике рәкәгать бер намаз исәпләнелер Шунлыктан, теләсә, сөннәткә ике рәкәгатькә бер сәлам бирер. теләсә — дүрткә бер сәлам. Әгәр дә дүрткә бер сәлам бирә икән. ул вакытта әүвәлге утыруында әттәхияттән соң салават һәм догаларын укыр, аягына баскан вакытында «Собханәкә . « «Әгузе бисмиллаһ...»ларны башлап әйтеп үтәр.

Намазның шартлары

Намазның унике шарты бар. Аларның алтысы намазга кергәнче үтәлергә тиешле. аларын «шарт» дип атыйлар. калган алтысы — намазга кергәч үтәлә. боларын «рәкен» дип йөртәләр.

Намазга керер алдыннан кирәкле шартлар:

1 Тәһарәт алу. кирәк булса. госел коену.

2 Нәҗестән сафлану. тәндә. киемдә. намаз укый торган урында нәҗесләр бар икән. аларны чистарту фарыз.

3. Гаурәт урыннарны кием белән каплау. аларны ачылып китмәслек итеп ябу шарт.

4. Кыйблага йөз белән басу. ягъни Кәгъбәи-шәриф тарафына йөз белән юнәлеп тору.

5. Намаз вакытында укылганда гына дөрес. ягъни бишвакыт намазларның кайсы вакыттан кайсы вакытка кадәр укылырга тиешлеген дөрес һәм шул чакта гына уку.

6. Ниятләнү. ягъни кайсы вакыт намазыңны укыйсың икән, шул вакытның намазын ният итеп башкару, ниятеңне белдерү.

Намазның эчендә булган шартлар:

1 Ифтитах тәкбир. ягъни намазга тотынганда колак каккан вакытта «Аллаһү әкбар!» дип әйтү.

2. Кыям ягъни намазны аягөсте басып уку.

3. Карәәт. ягъни намазда аягөсте булганда Коръән уку.

4. Рәкүгъ. ягъни баш белән билне тигез итеп иелү, бөгелү.

5. Сәҗдә. ягъни тезләрне, аякларны, кулларны һәм йөзне җиргә кую, терәү.

6. Кәгъдә ахирәт. ягъни намазның ахырында әттәхият уку өчен кирәк булган вакыт аралыгы дәвамында утырып тору.

Боларның берсен дә намаз уку алдыннан һәм укыганда онытып калдырырга ярамый. әгәр дә хәтердән чыксалар, дөрес намаз хисапланмый.

Хәзер бу унике шартның ничек үтәлүен аерым-аерым карап, тәртипләрен күреп үтик.

1. ТӘҺАРӘТ АЛУ

Тәһарәт алу ике төрле була, аның беренчесе — олуг тәһарәт, ягъни тәһарәт кәбири. Олы тәһарәт коенырга кирәкле саналганда, коенып сафлануны таләп итә. Икенчесе — кече тәһарәт. ягъни тәһарәт сәгыйри. Монысы госелне таләп итми, юынып пакьләнүдән гыйбарәт.

Госелнең фарызлыгы

Коръәндә шундый аять бар: «Вә ин күнтүм җүнүбән фаттаһһару», ягъни «Әгәр дә сез чиста түгелсез икән, ул вакытта камил рәвештә тазарыныгыз». ягъни госел коеныгыз.

Госелнең фарызлары

Госелнең өч төрле фарызы бар:

1 Мәзмәзә. ягъни авыз чайкау. Авыз куышлыгына су алып, анда бер генә урынны да калдырмыйча бер кат чайкаудан гыйбарәт.

2. Истиншакъ. ягъни борын эчен чайкау. Моның өчен борын эченә су тартыла һәм аның нечкә тишегенә кадәрге барлык урыннары су белән чылатыла. чистартыла.

3. Коену. Моның өчен тән-гәүдәнең барлык җирләрен су белән сафландыру таләп ителә. Әгәр дә бер генә җиреңә энә очы кадәр генә булса да су тими калган икән. ул вакытта госелең дөрес түгел. Тәнеңә балык тәңкәсе ише әйбер ябышып. астына су үтмәсә, шулай ук госел дөрес түгел. Тәнеңнең һәммә ноктасына, йөзек ише әйберләрнең асларына да су тидереп юу шарт.

Кешегә авыз-кулны юмыйча ашарга утыру мәкруһ санала!

Әгәр дә госел коенучы хатынның чәчләре толымнарга үрелеп куелган икән. ул вакытта толымнарын сүтеп тору шарт түгел. Шулай да ул хатын чәчләренең төпләрендә коры җир калдырмыйча чылата, толымнарын сүтмичә генә суда сыга. шулай дөрес була.

Әгәр дә хатынның чәч толымы сүтелгән икән, госел алганда тулысынча чәчен юу сорала.

Әгәр дә ир кешенең чәче үрелгән икән, ул аны сүтәргә һәм юарга

гәһарәте кебек пакьләнү сорала. Тәһарәт алганда авыз, борын, кул һәм башка урынны өчәр мәртәбә юу сөннәт.

Коенган вакытта иң элек уң җилкәдән башлап, сулына күчү. аннан баш очыннан коену дөрес.

Госел коенган вакытта аяклар су эчендә калса, соңыннан аякларны аерым юып алу тиешле.

Тәһарәтнең сөннәтләре

1. Тәһарәткә керешкән вакытта: «Бисмиллаһир-галиилгазыйм вәл хәмду лиллаһи галә динил-ислам вә галә тәүфыйкил-иман вә галә һидайәтир-рахман!» — дип укыла. Ә инде кулларны юганда бармакларны аралаштыру — сөннәт.

2. Юыла торган барча әгъзаларны өчәр кат юу.

3. Авызга су алган вакытта теш чистарткыч ярдәмендә тешләрне чистарту һәм борынга су алып, аны төшерү.

4. Йөзне юарга керешкән вакытта: «Ният иттем йөземне юарга, тәһарәт алырга», — дип белдерү.

5. Муенны һәм колакларны мәсех итү һәм һәр юыла торган әгъзаны сафландыруны уң яктан башлау.

6. Һәр юыла торган әгъзаларны кабул ителгән тәртибе буенча чиратлаштырып башкару: әйтик, башта — йөзне сафландырасың, аякларга мәсехне иң соңыннан үтисең. Әмма бу тәртипне бозып, башта аякларга мәсех, аннан соң йөзгә пакьләндерү ясарга да мөмкин, бу очракта тәһарәт һич тә бозылмый, бары тик сөннәткә хилафлык кына килә.

Тәһарәтнең мәкруһлары

Тәһарәтнең мәкруһларыннан унысын гына карап үтәрбез, алары башка галимнәр тарафыннан да бәхәссез рәвештә кабул ителгәннәр:

1. Тәһарәт алган вакытта суны йөзгә бик каты ору, чәчрәтеп юыну киңәш ителми.

2. Тәһарәттә баштан бүтән әгъзаларны өчтән ким тапкыр юып төшерергә киңәш ителми.

3. Тәһарәттән төшкән суның өстенә төкерү һәм сеңгерү киңәш ителми.

4. Тәһарәт алган вакытта кыйблага арка белән тору киңәш ителми.

5. Уң кул белән сеңгерү киңәш ителми.

6. Сул кул белән авызга һәм борынга тәһарәт алган вакытта су күтәрү мәкруһ санала.

7. Кояшта җылынган су белән тәһарәт алу киңәш ителми.

8. Тәһарәт алганда әгъзаларны сул тарафтан башлап юарга ярамый.

9. Тәһарәт алган вакытта дөнья сүзен сөйләшмиләр.

10. Йөзне юган вакытта авыз-күзләрне бик нык ачу яки каты йому киңәш ителми.

Читеккә мәсех итү

Читекләргә мәсех итү хедисләр һәм сөннәт белән дәлилләнә. Әмма читекләргә мәсех итү тәһарәт өчен генә дөрес, госел коенганда исә дөрес түгел. Әгәр дә читекләргә мәсехне тәһарәттә калдырсаң, ул вакытта тәһарәт бозылган саналыр, дөрес булмас.

Су үткәрми торган аяк киемнәренә генә мәсех дөрес; әйтик, күнитек, кәвеш, киез итек кебекләргә.

Читекләргә мәсех йорт эчендә яшәүченең бер көн һәм бер кич буе читекләрен салмаганда, мөсафир-юлаучыга өч көн һәм өч кичә дәвамында аяк киемнәрен салмый йөргәндә генә дөрес, әгәр дә салса, яңадан юарга тиеш.

Әгәр дә берәүнең аяк киемнәренә су керсә яки юеш җирдә йөрсә, тубыктан түбән бер генә аягын гына чылатса да икесен дә. читекләрен салып. тәһарәттә юарга кирәк. Алай эшләмәсә, тәһарәте дөрес түгел.

Мәсех микъдары өч бармак буе исәпләнелә. Ягъни аерым-аерым ике кулны да мәсех тарту өчен чылатасың һәм аерым-аерым өчәр бармак белән читекнең оч башыннан кунычына өч бармак эзе тартасың. Менә шушы читеккә өч бармак буе дигән микъдарны белдерә.

Кулларга аерым-аерым су алына. Әгәр дә читеккә бармакларны тидермичә генә су тамызып барсаң, тәһарәт дөрес саналмый, мәсех үтәлмәгән булып чыга.

Әгәр дә табаның яки үкчәң тишелгән читектән чыкса, күренсә, мәсех дөрес түгел. Бу очракта аяк киемнәрен салып, аякларны юарга кирәк.

Әгәр дә бер читегеңдә өч бармак сыярлык тишек яки сүтелгән җир бар икән, мәсех дөрес түгел.

Читекләргә мәсехнең вакыты тәмамланса, ул кеше тәһарәт алганда аякларын юар. шуның белән тәһарәте тәмам булыр.

Әгәр дә берәү яралы булып, ярасына су тидерү зыянлы икән, ул вакытта мәсех кенә тартыр, шулай дөрес булыр, каны күренсә дә, тәһарәте бозылмас Әгәр дә ярасы төзәлеп, кутыры купса, тәһарәт тиешле. чөнки бу вакытта тәһарәт бозылыр.

Әгәр дә ярага су тиюдән зарар юк икән, ул вакытта яраны юу дөрес, юмасаң тәһарәт бозылыр.

(Дәвамын киләсе елда укырсыз).

Атналык манзара TV

Дүшәмбе
25 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.35 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Татарча сөйләшәбез» 20.30 «Гашыйклар телеканалы» 21.00 «Яшел камин янында» Мөфти шеех Равил Гайнетдин. 21.55 Нәфис фильм премьерасы: «Победа любви» 3 нче серия. 23.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.55 «Зарядкага басыгыз!» 7.05 Мультфильм: «Огни» 7.30 Тамаша залы. 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 8.15, 11.05 «Юл патруле» 8.30, 14.45 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12.50 «90х60х90». 9.40 «Диск-канал» 10.00 «Рождество Христово. Вифлеем». 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.20 Атна фаразлары. 11.50 «Валюта биржасе». 12.00 Сериал: «Мстители». 13.05 Нәфис фильм: «Монахини в бегах». 15.00 Динле кешенең тантаналы тавышы. 15.30 Сериал: «Флиппер» 16.25 «Минем кино»: Анатолий Ромашин. 17.05 Ток-шоу «Минем тарих». Игорь Кириллов. 17.50 Нәфис фильм: «Чипполино» 19.10 Эфирда — музыка. 19.20 «Лариса» яңалыклары. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.35 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 Видеомода. 21.05 Тапшыру премьерасы: «Кстати» 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Криминаль хроника тележурналы. 22.05 Кинокомедия: «Близнецы». 0.00 Телесериал: «Особое подразделение»: «Расследование Симона»

1 НЧЕ КАНАЛ

Техник чараларга ремонт үткәрү сәбәпле, тапшырулар 15.00 сәгатьтә башлана.

15.00, 18.00, 23.30 «Яңалыклар». 15.15 Мультфильм: «Рождественское сокровище Михея» 1 нче кисәк. 15.40 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.00 «Джем». 17.30, 0.35, 1.05 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 Телеуен: «Көен таны». 19.35 «Ника-95» премиясе. Документаль фильм: «Прощай, СССР» 20.45 «Тыныч йокы, нәнилэр». 21.00 «Вакыт». 21.45 Сериал: «Лунный свет» 22.45 «Көмеш шар» В.Вульф алып бара. 23.40 Сериал: «Яңалыкларның телевизион хезмәте».

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 Хәбәрләр. 8.25 «Кирәк... Кирәк...» 8.30 «Йолдызнамә». 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9.40 «Телегазета» 9.45 «Үтә яшерен». 10.35 Сериал: «Одиссея». 25 нче серия. 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сезнең партнер» «Газпром» 11.50 «Төп мизгел». 12.00 «Авиация дөньясы» «Дубай-95» 12.30 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Яңа ел бәлеше» 16.30 «Көнгерә». 17.20 «Яңа тармак» «Авось...» 17.50 «Минем сугыш» 18.20 «Алыргамы, алмаскамы?» 18.30 «Коткару-911» 19.25 «Сабый авызыннан», 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Дүшәмбе саен детектив. «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Кто убил Гарри Филда?» (Бөекбритания). 21.40 «Репортер» 22.05 «Хакыйкать мизгеле» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55, 0.50 Төнге телесериал. Нәфис фильм «Последний контракт» (Италия). 3 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 13.00, 19.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары, 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 13.45, 15.25-15.32 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50, 19.05 «Телеблиц» 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла» 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 17.45 ТВ мәгълүматлары. Аурупа калейдоскобы. 18.15 «Классика-5» Д.Гершвин музыкасы.
22.30 «Шәһәр эшләре» 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Музыкаль-шоу «Телекомпакт»

Сишәмбе
26 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.55 Мультфильм: «Внимание: елка!» 18.05 Документаль фильм: «Дело — табак». 18.20 Балалар өчен. «Яңа ел әкияте». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Пульс» Медицина программасы. 19.55 «Әлли-бәлли-бәү». 20.05 «Татарча сөйләшәбез». 20.15 «Архитектурага сәяхәт». Казан мәчетләре. 20.50 «Безнә җырлар очраштыра». Угро-фин халыклары фестивале. 21.20 Нәфис фильм: «Последний романс». 1 нче серия. Төп рольдә — Хосе Каррерас. 22.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 «Эфирда — музыка». 7.30, 20.20, 23.55 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (25 декабрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05 «Юл патруле» 8.30, 14.45 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12.50 «90х60х90». 9.40 Диск-канал. 10.00 «Минем кино» Анатолий Ромашин. 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.20 «Атна һәлакәтләре». 11.50 «Валюта биржасе» 12.00 Сериал: «Спасатели Малибу». 13.05 Нәфис фильм: «Братья по крови». 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 Музыка һәм матбугат: «Каләм осталары» — Сергей Минаев. 16.30 «Кинескоп» киноканалы. 19.00 Сериал: «Лови удачу на лету». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.05 «Боз белән каен җиләге». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Кечкенә аваз». Туры эфирда уен. 22.25 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Фокусник». 0.20 Стинг «Пусть наступит ночь» музыкаль фильмында.

1 НЧЕ КАНАЛ

Көндезге сәгать 3 кә кадәр профилактик эшләр.

6.00 «Иртә». 9.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар. 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?». 11.10 Мультфильм: «Снеговик-почтовик» 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.00 «Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары». «Без һәм базар». 12.50 «О бедном гусаре замолвите слово». 1 нче серия. 14.10 Сериал: «30 случаев майора Земана» 15.20 Мультфильм премьерасы: «Рождественское сокровище Михея». 2 нче кисәк 15.45 Кварьетә «Веселая квампания» 15.55 Мультитроллия. 16.10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.00 «...16га кадәр һәм өлкәнрәкләр өчен». 17.30, 2.05, 2.35 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәнилэр» 21.00 «Вакыт». 21.45 «Беренче каналда Яңа ел төненнән» 10 минут 22.00 Хоккей. Аурупа кубогы. «Кельн (Германия) — «Динамо» (Мәскәү) Германиядән тапшыру. Тәнәфесләрдә (22.35) «Мәскәү. Кремль, яңалыклар» 0.35 Сериал: «Яңалыкларның телевизион хезмәте» 1.30 Русия сәнгате йолдызлары. «Триумф» премиясе.

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк... Кирәк...» 8.30 «Йолдызнамә» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Телегазета». 10.50 «Мөһим мизгел». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сезнең партнер». «Газпром». 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений». 12.15 «Куркыныч вирус. Уйланулар өчен мәгълүмат» 12.30 «Эшлекле Русия». 16.05 «Яңа ел бәлешә» 16.15 «Самовар» янында очрашулар» Ю.Энтин 16.50 «Ай тотучы» 18 15 «Десертка музыка». 18.25 «Сезнең партнер» 18.40 «Теледебатлар» 19 10 «L» клубы 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 «Самолет летит в Россию» 22.25 «Киноафиша» 23.40 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55, 0.55 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Последний контракт» (Италия). 4 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 13.00, 19.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 13.45, 15.30-15.34 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50 «Телеблиц» 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла» (Италия). 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 17.50 «Бөтен Русия буйлап» 18.00 «Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә»
21.05 Нәфис фильм: «Новогодний праздник» (Италия) 2 нче серия. 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 «Парни с улицы»

Чәршәмбе
27 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35 Мультфильм: «Голубая стрела». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Авыл». 20.15 «Әлли-бәлли-бәү» 20.20 «Татарча сөйләшәбез». 20.30 «Без нинди?» Тапшыруны психотерапевт Рамил Гарифуллин алып бара. 20.40 Мәдәният һәм сәнгать Казан Дәүләт академиясенең концерт-презентациясе. 22.00 Нәфис фильм: «Последний романс» 2 нче серия. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка». 7.30, 20.20, 23.45 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (26 декабрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05, 16.30 «Юл патруле» 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12.50 «90х60х90». 9.40 Диск-канал 9.55 «Минем тарих»: Игорь Кириллов. 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти» 11.20 «Атна низаглары». 11.50 «Валюта биржасе». 12.00 Сериал: «Ночная жара». 13.05 Нәфис фильм «Неисправимый лгун». 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы». 15.30 «Кино музыкасы»: Георгий Вицин. 15.45 А.Политковскийның «Кара җир нинди төстә» программасы. 16 15 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 16.45 Диск-канал: «Ace of Base». 17.30 Нәфис фильм: «Волшебная лампа Алладина». 18.50 Тапшыру премьерасы: «Шәһәр һәм аның Киңәшчесе». 19.20 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Казан автосалоны. 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Үз кешеләр. 22.05 Нәфис фильм: «Тайна «Черных дроздов» 0.10 Нәфис фильм: «Холодная лихорадка».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 23.50 «Яңалыклар». 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Тема». 10.50 «Хайваннар дөньясында». 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. Бәйләнеш — бердәмлек илләренең эшлекле хезмәттәшлеге. 12.50 «О бедном гусаре замолвите слово» 2 нче серия. 14.10 Сериал: «30 случаев майора Земана». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Кактус һәм Ко». 15.50 «Күңелле ноталар» 16.10 «Джунглилар чакыруы» 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.00 «Тет-а-тет» 17.30 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны» 20.00 «Хәтерләсеннәр өчен...» Л.Филатов алып бара 20.45 «Тыныч йокы, нәнилэр». 21.00 «Вакыт». 21.45 «Дом под звездным небом». 0.00 Сериал: «Яңалыкларның телевизион хезмәте». 0.55 Хоккей. Аурупа кубогы. «Динамо» (Мәскәү) — Фельдкирх» (Австрия). 3 нче период. Германиядән тапшыру. 1.45, 2.35 «Җыр-95».

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк... Кирәк...» 8.30 «Йолдызнамә» 8.35 «Ритмика». 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9.30 «Телегазета». 9.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.30 «Санта-Барбара» геройлары белән очрашулар 11.20 «Гадәттән тыш канал». «Яшибез һәм яратабыз» 11.30 «Крестьян мәсьәләсе» 11.50, 17.50 Мультсериал: «Камень сновидений». 12.15 «Яңа тармак». 12.30 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Яңа ел бәлеше» 16.30 «Кичә, бүген, иртәгә». 17.20 «Яңа тармак». «Ерак Көнчыгыш». 18.15 «Видеопоэзия». А.Фет. 18.25 «Сезнең партнер» 18.40 «Ак карга». 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 Михаил Боярский «Домино»сы 22.10 «Гадәттән тыш канал». 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55 «Криминаль хәбәрләр экраны» 0.05, 2.10 «Увлечения». «Ника-95» премиясе.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә» 13.00, 15.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле» 13.25 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Табиблар, фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру: «Рецепт». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.40 «Сестрички из Лос-Анджелеса» 16.50 М.Кшесинский турында видеофильм: «Матильда» 17.55 Мультсериал: «Там, где живет Паутиныч»
21 15 Э.Хиль концерты. «Это было недавно, это было давно...» 22.05 «Блеф-клуб» 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23 15 Юмористик программа «Золотой телец»

Пәнҗешәмбе
28 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 Мультфильм: «Ну, погоди!» 18.40 «Шигърият». Лилия Газизова. 18.50 «ГАИ мәгълүматлары». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Хөкүмәт сәгате» 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Татарча сөйләшәбез». 20.20 «Уйнагыз, гармуннар!» 21.55 Экранда кинокомедия. «Отпетые мошенники». 1 нче серия. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда музыка». 7.30, 20.20, 23.35 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (27 декабрь тапшыруын кабатлау). 8.15 «01» журналы. 8.45 «Җир планетасы». «Кояшлы диңгез». 9.40 Яңа вакыт сәнгате». 10.10 Документаль фильм: «Гость». 10.40 «XX гасыр капкачысы». 11.40 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.20 «Тегеләр, кемнәр». 12.30 Ток-шоу «Мин үзем»: «Мин матур түгелмен». 13.30 Нәфис фильм: «Рецепт ее молодости» (Л.Гурченко). 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 «CNN «Стиль». 15 50 Сериал: «Ночная жара». 16.50 «ПОСТ — музыка яңалыклары. 17.05 «Юл патруле». 17 20 «Мәхәббәт көйләре». 17.40 «Ушуайя». 18.00 «Computerlife». 18.30 «Кыюлар һәм матурлар». 19.00 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 19 10 «Турыдан-туры элемтә». Студиядә — Казан шәһәре башлыгы К.Исхаков 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.05 «Казанские ведомости» нәрсә турында язды» 21 15 «Телеэкспресс». 21.35 Атна фильмы. Нәфис фильм: «Свет женщины» (Ив Монтан, Роми Шнайдер). 0.00 RED WAVE тәкъдим итә: Кисс.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Хәтерләсеннәр өчен...» Л.Филатов алып бара. 10.45 Хоккей. Аурупа кубогы. «Динамо» (Мәскәү) — «Фельдкирх» (Австрия). 3 нче период 11.40 «Төмлә». 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. «Тынычлык түбәсе астында». 12.50 Киноның 100 еллыгына. «Александр Невский». 14.40 Мультфильм: «Новогодняя сказка». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Лего-го». 16.10 «Тин-тоник». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.00 «Рок-дәрес». 17.30, 2.25, 2.55 «Спортның җиде көне». 18.20 «Лотто-миллион». 18.35 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.00 Киноның 100 еллыгына. «Седьмая печать». 20.45 «Тыныч йокы, нәнилэр». 21.00 «Вакыт». 21.45 «Ника-95» Кинематография елының йомгаклары 0.45 Сериал: «Яңалыкларның телевизион хезмәте» 1.40 «Музобоз».

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк... Кирәк...» 8.30 «Йолдызнамә». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Барысы да аз-азлап». 9.30 «Телегазета» 9.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.30 «Санта-Барбара» геройлары белән очрашулар. 11 20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сезнең партнер» «Газпром». 11.50, 17 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Бомбейдә музей кино». 12.20 «Человек с бульвара Капуцинов». 14.20 «Һәм бу кино». 14.50 Мульти-пульти. 15.10 «XX гасыр кадрда һәм кадр артында». С.Бондарчук 16.05 «Яңа ел бәлеше» 16.15 «Шау-шулы яңалыклар». 16.30 Яңа ел әкиятләре. Фильм-феерия: «Щелкунчик». 17.20 «Яңа тармак». 18.20 Фильм-концерт: «Бөекләр һәм кабатланмаслар». 18.55 «Сезнең партнер». 19.10 «Урысча караоке». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21.30 «Битлек-шоу» 22 10 «Шау-шулы «Тыныч йорт». 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55, 1.55 «BLOW UP». Бөекбритания — Италия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 13.00, 19.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 13.45, 15.45, 17.30 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50, 17.35 «Телеблиц». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.50 Фильм-балет «Чаплиниана». 16.55 «Поэтик театр». С.Есенин. «Черный человек». 17.40 «Бөтен Русия буйлап». 18.00 «Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә»
22.10 «С.Есенин истәлекләре». 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Нәфис фильм: «Бонни и Клайд по-итальянски».

ҖОМГА

29 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Фильм — балаларга. «Двенадцать месяцев». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.50 Татарстан Дәүләт Советында. 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Татарча сөйләшәбез». 20.40 «Җомга көн кич белән». Альманах. Яңа ел чыгарылышы. 21.50 Экранда кинокомедия. «Отпетые мошенники». 2 нче серия. 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда музыка». 7.30, 20.20, 23.05 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Турыдан-туры элемтә» (28 декабрьдә язып алынган тапшыру). 7.55 «Телеэкспресс» (28 декабрь тапшыруын кабатлау). 9.20, 13.50 «90х60х90». 9.40 Диск-канал. 9.55 А.Политковский программасы. 10.25 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.15 «Юл патруле». 11.30, 16.30 «Спорт атнасы». 12.00 «Валюта бәясе». 12.05 Детектив сериал: «Ночная жара». 14.05 «Ресторан рейтингы». 14.20 Мультфильм: «Земля предков». 14.45 «Даруханә». 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы». 15.30 «Тегеләр, кемнәр...». 15.50 «Прибытие поезда» (Бертуган Люмьерлар фильмы). 16.00 Сериал: «Мелочи жизни». 17.00 Луи де Фюнес «Человек-оркестр» фильмында. 18.30 Чаплиниада: «Джонни в кино». 18.40 «Суперспорт». 19.00 Нәфис фильм: «Корабль любви». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Көннәрнең ямьсезләре булмый». 20.55 «Экология хәбәрчесе». 21.00 «Ипи заводы — минем язмышым». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис фильм: «Рукопись, найденная в Сарагоссе». 1 нче серия. 23.30 Джентльмен-шоу. 0.00 Нәфис фильм: «Контракт рисовальщика» (Бөекбритания). 1.45 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 18.00, 23.50 «Яңалыклар». 9.15 Мультфильм: «Левша». 10.00 «Алтын төнкә». Италиядә балалар җыры конкурсы. 10.40 «Киносәяхәтчеләр клубы». 11.25 «Бар да өйдә чакта». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 «Тартюф». 14.25 Мультфильм: «Кошкин дом». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Яңа чынбарлык». 16.05 «Золушка». 17.30 «Спортның җиде көне». 18.20 «Кыргый кыр». 18.35 «Кешә һәм закон». 19.05 «Ыгы-зыгылы вакыт». 19.30 «Беренче каналда Яңа ел кичә»ннән 10 минут. 19.40 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.45 Сериал: «Детективное агентство «Лунный свет». 22.45 «Караш». 23.30 «Трасса». 0.00 Хоккей. Европа кубогы. ХВ-71 (Швеция) — «Йокерит» (Финляндия). 2 нче һәм 3 нче периодлар. Германиядән тапшыру. 1.25 Телешоу «50х50». 2.45-3.50 «Мнимый больной». 1 нче серия.

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызнамә». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Барысы да аз-азлап». 9.20 «Әни». 10.45 Сәүдә йорты. «Ле Монти». 11.20 «Крестьян мәсьәләсе». 11.40 «Милиция хроникасы». 11.50 «Вовкулакия, яки Доктор Никодим табышмагы». 12.05 «Озынайтылган көн». 12.30 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Кем ягы?» 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Яңа тармак». 17.50 Нәфис фильм: «Зорро». 45 нче һәм 46 нчы серияләр. 18.50 «Яңа ел бүләше». 19.00, 20.35 Фәнни-фантастик триллер премьерасы: «Золотые годы». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 21.35 «К-2» тәкъдим итә: «Алтын билет» кинофестивале. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55-1 40 «К-2» тәкъдим итә: «Алтын билет» фестивале фильм-призеры «Яраткан комедия» номинациясендә.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 13.00, 15.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 13.25, 13.45, 15.45, 17.55 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50, 17.00 «Телеблиц». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телесериал: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.50 В.Холодная «Жизнь за жизнь» (1916 ел) фильмында. 17.05 Телеспектакль: «Малиновая кошка». 18.00 Ленинград өлкә телекомпаниясе күрсәтә.
21.00 «Парадлар парады» тәкъдим итә: «На-на» төркеме. 21.40 Петербург ангажементы 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 «День волков»

ШИМБӘ

30 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.50 Мультфильмнар: «Мороз Иванович», «Щелкунчик». 18.30 Х.Кумысников. Телеспектакль премьерасы: «Необычайные приключения под Новый год». 19.00 «Татарстан». 19.30 «7 нче стиль». 20.25 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 «Гадәти шимбә». 21.15 «Бер көрәшү — үзе бер гомер». Апас районы якташларына багышлана. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Бүген Мэрилин белән». 7.30, 20.20, 0.00 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (атналык кабатлау). Узган атна тапшырулары: 9.25 «Коммерция өйләнмәсе» (26 декабрь көнендәге тапшыруны кабатлау). 9.45 Тапшыру премьерасы: «Кстати». 9.55 «Лариса» яңалыклары». 10.25 «Казан автосалоны». 10.55 «Үз кешеләр». 10.30 «Атнага бер тапкыр» юмористик тапшыруы. 12.00 Шимбә сериалы: «Флиппер». 12.55 Хәрби телевидение. 13.25 Сериал: «Мелочи жизни». 14.00 Киноның 100 еллыгына. Ричард Аттенборо фильмы: «Чаплин». 16.30 «ПОСТ — музыка яңалыклары». 16.50 Мультсериал: «Город собак» (Канада). 17.15 «Яшерен йомыш». 17.40 Мультфильм: «Молодильные яблоки». 18.00 «Исәнмесез!». 20.45 «Мавыгулар дөньясы». 21.15 Телесериал: «Тропическая жара». 22.10 Нәфис фильм: «Рукопись, найденная в Сарагосе». 2 нче серия. 0.25 Сериал: «Строго на Юг». 3 нче серия. 1.15 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.45, 9.10 «Уяныгыз» телеканалы. 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 18.00, 0.10 Яңалыклар. 10.30 «Оттырма». 11.00 «Иртәнге почта». 11.35 «Тәмле». 11.55 «Минем хыялымдагы курчак». 12.35 «Бомонд». 12.55 Цветнойдагы циркта Яңа ел өлкасы. 13.25 «Трактористлар». 15.20 Мультфильм: «Исполнение желаний». 15.50 «Хайваннар дөньясында». 16.30 «Аурупага тәрәзә». Д.Киселев алып бара. 17.00 «Шулай бервакыт». 17.10 «Бәхетле очрак». 18.20 Михалков, Мордюкова, Ефремов, Гердт һәм башкалар 1 нче каналның «Рус проекты»нда. 18.55 Кинокомедия: «Операция «Ы» и другие приключения Шурика». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.45 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» Финал. 23.10 Сериал: «Детективное агентство «Лунный свет». 0.20 Хоккей. Европа кубогы. Финал. Германиядән тапшыру. 2.30 «Мнимый больной». 2 нче серия. 3.25-3.50 Музыкаль программа: «Рус кадаклары».

«РУСИЯ»

8.00, 11.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызнамә». 8.30 «Әдәплелек». Яңа ел чыгарылышы. 8.40 «В поисках капитана Гранта». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 10.55 Пилигрим. Русиянең сәяхәтләр бюросы. 11.40 «Скворец и Лира». 14.20 «Кадр-100». 15.20 «Футболга чикләр юк». 16.05 «Безнең бакча». 16.35 БДБнең бодибилдинг буенча ачык чемпионаты. 16.55 «Рек-тайм. 17.45 «Шарман-шоу». 19.00, 20.25 Фәнни-фантастик триллер премьерасы: «Золотые годы». 3 нче һәм 4 нче серияләр. 21.25 Раштуа бенефисы. Людмила Гурченко. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40, 0.55 «299-00-00» хезмәте. 23.55 «А» программасы. 1.10-2.40 «Несколько любовных историй».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10.00 «Яшәү стиле». 10.20 Балалар өчен нәфис фильм премьерасы: «Страшила на чердаке» (Чехия). 11 40 Музыкаль телефильм: «Бабиле-91» (Франция). 12.45 «Йолдыз» белән рандеву». Анастасия. 13.15 «Рецепт». Табиблар, фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру. 13.25 «Теледоктор». 13.45 Эшкә урнаштыру телевизион хезмәте. 14.00 «Сестрички из Лос-Анджелеса». 15.10 «Тарихи альманах» циклыннан. «Блеск и нищета Пушкинского дома». 15.45 «Золушка». 17 10 «Гыйбадәтханә». 17 40 «Телеблиц». 17.45 «Музыка мизгеле». 17.50 «Сказка про то, как царевич Глеб Тридевятое царство от Кащея Бессмертного спас».
23.10 ТВ мәгълүматлары. 23.35 «Оранж-ТВ» «Теләмәсәң — карама» каналын тәкъдим итә 0.25 «Яңа ел белән, Мәскәү!»

ЯКШӘМБЕ

31 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.10 Л.Лерон. «Без барабыз бәйрәмгә». Яңа ел әкияте. 19.25 Мультфильм: «Когда зажигаются елки». 19.45 «Көлкә корольләре». Күңел ачу программасы. 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 «Хуш киләсең, Яңа ел!» 23.35 Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнең яңа ел котлавы.

«ЭФИР»

7.00 «Рик Реннер белән яхшы хәбәр». 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. Узган атна тапшырулары: 7.55 «Коммерция өйләнмәсе» (28 декабрь тапшыруын кабатлау). 8.15 «Computerlife». 8.45 «Поза». 9.15 Мультфильм: «Чикарики». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 10.00 Музыкаль фильм-әкият: «Золушка» (АКШ). 11.20 «Ералаш». 11.40 Нәфис фильм: «Чародеи». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 14.20 «Атна фаразлары». 14.50 Нәфис фильм: «Зигзаг удачи». 16.25 Мультфильмнар: «Куплю привидение», «Мы с Шерлоком Холмсом», «Ограбление по». 17.00 Мультсериал: «Город собак» (Канада). 17.25 Сериал: «Спасатели Малибу». 12 нче серия. 18.25 «Тамаша залы» (КиноМеню). 19.10 Телеэкран премьерасы. Нәфис фильм: «Королева Марго» (Франция). 21.45 «Безнең өйдә — Яңа ел!». Бәйрәм программасы. 3.00 «Исәнмесез!» (30 декабрь тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.50 «Спортлото» тиражы. 8.00, 9.10 «Уяныгыз!» телеканалы. 9.00, 15.00, 18.00 Яңалыклар. 10.25 «Бар да өйдә чакта». 11.00 «Таң йолдызы». 11.50 «Три плюс два». 13.30 «Телескоп». Бәйрәм чыгарылышы. 14.25 «Көлкеле манзара». 15.20 Иоганн Штраус. «Летучая мышь» «Опера тарихлары» циклында». 16.25 Сәяхәтчеләр клубы. 17.15 Яңа ел мультфейерверкы. 18.20 «Футбол күзәтүе». «Ел йомгаклары». 18.45 «Яңа ел зәңгәр утлары» битләреннән». 19.40 «Беренче каналда Яңа ел төне»ннән 10 минут. 19.55 «Ак попугай» клубы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр!» 21.00 «Вакыт». 21.35 «Разиня». 23.35 Беренче каналда Яңа ел төнә. 23.50 Яңа 1996 ел белән! 0.05 Беренче каналда Яңа ел төнә (дәвамы). 2.45-5.00 «Чокнутые».

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызнамә». 8.30 «Яңа ел килә!». 8.55 «Шау-шулы яңалыклар». 9.10 «Мазай бабай кунакханәсе». 9.25 «В поисках капитана Гранта». 3 нче серия. 10.30 Хәерле иртә. «Чемпионнар өчен иртәнге аш». 11.00 «Сәгать 11 дәге хәбәрләр». 11.15 «Урыс лотосы». 12.00 «Яңа ел килә!» 12.15 Хроно. Авто- һәм мотоспорт дөньясында. 12.45 «Аты-баты...» 13.15 Дөнья экраны йолдызлары. 13.45 Кыш бабайга 299-00-00 телефоны белән шалтыратыгыз. 14.20 «Зимний вечер в Гаграх». 15.50 «Яңа ел килә!» 16.20 «Үз үзеңә режиссер». 17.05 Телекросс. 17.20 Джентльмен-шоу. 18.00 Мультфильмнар: «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха». 18.55 Яңа ел дискотекасы «Ксюшада кунакта». 20.25 Нәфис фильм: «Кто подставил кролика Роджера». 22.20 Һава торышы. 22.25 Хәбәрләр. 22.35 «Тылсымлы фонарь-95». Яңа ел тамашасы. 23.50 Яңа ел белән! 0.02 «Тылсымлы фонарь-95». Яңа ел тамашасының дәвамы. 1.05 «Камыш» шаулады». Төнге күңел ачу программасы. 2.35 «Карнавальная ночь». 3.50-4.50 Крис Де Бург «Эшләпәлә калыгыз» программасында.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9.05 «Сезнең кәнәгез». 9.30 «Шифалы сүз». 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Гарри Бардин мультфильмы: «Серый волк и Красная шапочка». 10.40 Музыкаль фильм премьерасы: «Фантазер» (Русия). 12.05 «Страсти-мордасти». 12.20 Гарри Бардин мультфильмнары: «Дорожная сказка». 12.40 «Тинэйджер-шоу». 12.55 Голливуд музыкасы. 13.20 Мультфильм: «Чудо-мельница». 13.40 «Маленькая миллионерша». 15.15 «Классика-5». «Йолдызлы 12 мизгел». 15.30 «Вообрази» студиясе. 16.00 «Буй-буй музыка». 16.20 «Ыргыт, өйдә». 17.20 «Экспресс-кино». 17.35 «Капчыктагы тычкан, яки Троян мәчесе». Песиләрнең музыка шоуы. 21.10 Видеофильм премьерасы: «Сериал века». 22.40 Санкт-Петербург мэры котлаулары. 22.55 «Яңа ел-96. Сезнең исәнлеккә!» Күңел ачу программасы. 23.50 Яңа ел белән! 0.05 «Яңа ел-96. Сезнең исәнлеккә!» (Дәвамы). 2.05 «Красивая, но опасная». 3.50 Ян Фридның музыкаль телефильмы: «Летучая мышь». 1 нче һәм 2 нче серияләр.

Һәркөнне 8.00 (якшәмбедән тыш), 19.00, 9.00 (шимбә), 10.00 (шимбә, якшәмбе) сәгатьләрдә — Мәскәүдән информацион һәм аналитик программалар трансляцияләнә.

ДҮШӘМБЕ, 25 ДЕКАБРЬ

6.00, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.48, 20.20 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 20.25 Һава торышы. 6.55, 7.50 Бәлдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.25 Тапшырулар программасы. 19.40 Баулы үзешчәннәрә концерты.

СИШӘМБЕ, 26 ДЕКАБРЬ

6.00, 7.00, 13.10, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.48, 20.20 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.30 Һава торышы. 6.55, 7.50 Бәлдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.25 Тапшырулар программасы. 12.25—13.50 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.15 Республика газеталарына күзәтү. 13.35 «Юл чатында». Информацион программа. 18.20 «Яшьлек» студиясе. 19.40 Татар композиторларының камера музыкасы.

ЧӘРШӘМБЕ, 27 ДЕКАБРЬ

6.00 «Татарстан дулкынында». 6.48, 20.35 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.30, 20.40 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00, 13.10, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.30, 20.40 Тапшырулар программасы. 12.20—13.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.35 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.15 Республика газеталарына күзәтү. 19.40 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 28 ДЕКАБРЬ

6.00, 7.00, 13.10, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.48, 20.35 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.30, 20.40 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.30, 20.40 Тапшырулар программасы. 12.30—13.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.35 «Балалар җырлый». 13.15 Республика газеталарына күзәтү. 19.40 «Музыкаль Татарстан» (Радиокүзәтү).

ҖОМГА, 29 ДЕКАБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.48, 21.10 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.30, 21.15 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00, 13.10, 19.10 «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.30, 21.15 Тапшырулар программасы. 12.20—13.35 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.35 Драма артистлары җырлый. 13.15 Республика газеталарына күзәтү. 18.20 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.40 Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, шагыйрь Ф.Яруллинның иҗат кичәсе. (Трансляция буенча язма).

ШИМБӘ, 30 ДЕКАБРЬ

6.00, 7.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.05 Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 9.55, 14.05 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.10 «Сезнең хатларыгыз». 8.20 «Мәсьәләгә бер караш». 8.35 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Декабрь». Шигъри программа. 9.30 «Кардәшлеккә чикләр юк». 10.20 «Көн артыннан көн». 12.20 Татар халык көйләре. 13.15 Яңалыклар эстафетасы. 13.35 «Яшьлек» студиясе.

ЯКШӘМБЕ, 31 ДЕКАБРЬ

6.00 «Чишмәләр Иделгә коя». Лениногорск «Чишмә» әдәбият-сәнгать берләшмәсендә очрашу. 10 декабрь тапшыруын кабатлау. 6.48, 7.45, 21.03 Тапшырулар программасы, һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00 «Хәерле иртә». 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 19.10 Яңалыклар эстафетасы. 19.30 «Хуш киләсең, Яңа ел». Балалар өчен тапшыру. 20.10 «Уены-чыны бергә». Әдәби музыкаль тапшыру. 21.10 Өлкәннәр һәм балалар өчен тапшыру. 21.42 «Татарстан дулкынында». 22.30 «Татарстан радиосының музыкаль студиясе кунаклары». 23.30 «Яңа ел белән!» Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев котлавы.

БАТУЛЛА БАГАНАСЫ

Изге теләк

Батулла яңа машина алгач, Актерлар йорты янына килеп туктый. Язучылар, артистлар Батулланы котлый. Батулланың авызы — колакта. Шулчак Разил Вәли машина хуҗасының кулын кысып әйтеп куя:

— Өстеңдә тузарга язсын!

Кызганыч кызык

Яшел Үзән ягына очрашуга баргач, колхоз ашханәсендә язучыларны бик шәпләп сыйларга телиләр. Язучылар белән бергә җырчы Рафаэль Сәхәби дә килгән була. Аш өләшүче хатын Рафаэль Сәхәбине күргәч:

— Син дә язучымы, энем? — дип сорый.

Сәхәби икеләнеп-нитеп тормыйча гына:

— Ие, апа, язучы мин! — ди.

— Кем соң син? Кайсы язучы? — дигәч, Сәхәби:

— Укыгансыздыр инде, апа, мин Гариф Ахунның «Идел кызы»н яздым, — ди. — Лев Толстойның «Анна Каренина»сын да мин яздым. Күп инде алар, саный китсәң, бик күп мин язган әсәрләр.

— Бик әйбәт, бик әйбәт! — ди апа.

Марсель Гали бу вакыйганы Батуллага сөйли, Рафаэль үзе дә шунда була. Әлеге хәл турында сөйләгәч, болар икесе дә кыты-кыты көлә башлыйлар. Батулла көлми, авыр сулап куя.

— Нигә көлмисең, Батулла? Кызык бит! — ди Марсель.

— Үкереп җыларлык хәл бит бу, җегетләр! — ди Батулла. — Нәрсәсе кызык моның? Шул бичара хатыннан көлүме? Аның ни гаебе бар? Ул китап укымаслык шартларда тәрбия алган. Маңкорт, мокыт булсын дип аны тәүлегенә егерме дүрт сәгать эшләтәләр бит. Әдәбиятсызлыктан әдәпсезлеккә бер адым!

Төнге кунак

Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Зиннур Хөснияр төн уртасында Батулла өенә килеп керәләр. Хуҗа җылы юрганы астыннан чыгып, ишекне ача, кунакларга табын әзерли, бәр шешә хәмер дә чыгарып куя. Каклаган каз, кыздырылган чуртан, икмәк вә яртыны күргәч, җегетләрнең күңеле эри. Ркаил хискә бирелеп:

— Бату ага, син — бөек кеше! — ди.

— Мин боек кеше! — ди Батулла.

— Батулла ул — даһи остаз! — ди Ләис.

— Мин таз кебек мөмтаз! — ди Батулла.

— Батулла абый ул — батыр кеше! — ди Ләис.

— Юк, җегетләр, — ди Батулла. — Мин бакыр кеше!

Зиннур Хөснияр сүзсез генә ашый.

— Дөресен генә әйткәндә, — ди Ркаил, — сезнең буын, Батулла абый, куркак буын! Ләкин син куркаклыгыңны яшермичә әйтә ала торган батыр кеше!

— Бату аганың сакалы ни өчен агарганын беләсеңме соң? — ди Ләис. — Халык өчен көрәшеп, эшләп агарган ул сакал.

— Юк, Ләис, — ди Батулла, — халык өчен эшләп агармады ул сакал.

— Ни өчен агарды соң алайса?

— Төннәр буе йокламыйча кунаклар сыйлаганга агарды ул сакал! — ди Батулла.

Ркаил белән Ләис көлә башлый. Зиннур Хөснияр эндәшмичә генә ашый.



ҮКЫ ДА УЙЛА

Рамил ВӘЛИЕВ

Асыл ирләр нигә асылына?

Иртә таңнан торып ашыга-ашыга фермага сыер саварга килгән Сәрия Гайнуллина абзар ишеген ачып җибәргәч, егылып китә яза. Ни күрсен, каршында матур гына киенгән яшь егет гәүдәсе асылынып тора. Дөньяда күпне күргән ханым тиз арада үзен-үзе кулга ала, әлеге хәлне ферма каравылчысына хәбәр итә. Икәү бергә килеп юньләбрәк карасалар, шаккаталар — авылдашлары Илшат Җиһангәрәев икән бит. Чыннан да, әфган сугышында сынатмаган, исән-имин туган ягына әйләнеп кайткан, Казан каласында эшләп йөрүче егетнең мондый фаҗигале үлеме һәркемне тетрәндерә. Ничек инде алай, әзмәвер гәүдәле, тормыш җанлы егет үз теләге белән дөньядан китеп барсын?! Ләкин тикшерү моның шулай икәнлеген раслый. Илшатны берәү дә асмаган. Ул үз теләге белән киткән. Хәзер исә сәбәбен дә төгәл ачыклау мөмкин түгел.

Язмамны шундый күңелсез вакыйга белән башлап китүем очраклы түгел. Соңгы вакытта менә диген ир-егетләрнең үз-үзләренә кул салу күренешләре аеруча ешаеп китте. Шунысы бигрәк тә гаҗәп, бичараларның һәрберсе турында: «Асыл иде, тыңлаучан иде», — диләр. Шулай да асыл ирләребез нигә асылына соң?

Азмы-күпме тормышны өйрәнгән, үз-үзенә кул салган кешеләр белән исән чакларында аралашкан кеше буларак, бу хакта шәхсән уйланганым да бар. Тик ясаган нәтиҗәләрем белән фикер уртаклашырга ашыгасым килми. Түбәндә китереләсе аянычлы фактлардан чыгып, укучы үзе нәтиҗәне дөресрәк чыгарыр, дип уйлыйм.

Шундый үлемгә дучар булган бер егетне (Рәсим Шәйхетдиновны) хәтерлим. Дөресрәге, аны әле мәктәп елларыннан ук белә идем. Беренче карашка бик кыю, берничә дә бирешмәслек егет дигән тәэсир калдыручан иде ул. Ләкин гомеренең ике елын әфган сугышында үткәреп кайткач, бөтенләй үзгәрде. Ничек булса да гаилә корырга омтылыш аңарда көннән-көн ныграк сизелә башлады. Нәкъ шул вакыт әфган сугышында катнашучыларның һәрберсенә берәр бүлмәле аерым фатир бирү турында карар чыкты. Рәсим моңа чын күңеленнән ышанып, шатланып йөрде. Ләкин кая ул? Нинди генә оешмаларның бусагасын таптамасын, һәркайда җавап бер: «Ашыкма, егет, көт бераз!» Ул арада илдә чуалышлар китте, инде гади кешегә фатир түгел, хәтта тулай торакта аерым бүлмә алу да бөтенләй читенләште. Моны аңлаган Рәсим үз язмышын үзе хәл итте — туган авылына кайтып асылынып үлде...

...Башкалар арасында үзен кимсетелгән дип хис иткән, җәмгыятьнең сәяси һәм икътисади үсеше бик түбән булу аркасында соңгы чиккә җиткерелгән кешене үз-үзенә кул салуы өчен әллә ни гаепләп тә булмый, минемчә. Дәлил өчен тагын бер мисал китерәсем килә. Алдан ук искәртәм, бу юлы мәсьәлә әлеге чиккә барып ук җитмәде. Казанның йортлар төзү комбинатына Рафил Гарәфиев армия сафларыннан хезмәт итеп кайтуга ук урнаша. Тора-бара өйләнә, бер-бер артлы ике балалары туа. Төзелеш оешмасында эшләп шактый стаж тутырса да, хәтта гаиләсе ишәйсә дә аңа фатир бирү турында уйлаучы да булмый. Ул һаман да тулай торакның 18 квадрат метр бүлмәсендә яши. Әрмәнстанда җир тетрәү булгач, андагы хәрабәләрне торгызу буенча отрядлар туплана башлый. Югарыда утыручы түрәләр әлеге отрядлар составында баручыларга фатир бирeләчәк, дип вәгъдә иткәч, Рафил гаиләсен калдырып Әрмәнстанга китә. Бихисап газаплар кичергәннән соң кире әйләнеп кайта. Хуҗалар вәгъдә иткән фатирны дәгъвалый башлый. Ләкин шундук кискен каршылыкка очрый. КДСКның элекке җитәкчесе В.Иванов, монда торасың килмәсә, авылга кайтып анаңнар янында яшә, дип кенә җибәрә. Ачуы килгән Р.Гарәфиев күршесендәге буш бүлмәне дә үзенеке итә. Аңа йорт җиһазлары урнаштыра. Ике арадагы диварның чирек өлешен җимереп ишек ясап куя. Аның бу кыюлыгы җитәкчеләргә барып ирешә һәм озакламый Казанның Идел буе районы прокуратурасы җинаять эше кузгата. Аны кулга алырга җыенган бер мәлдә, журналист буларак, бу эшкә мин дә килеп катнаштым. Шуннан соң гына әлеге гаиләне тынычлыкта калдырдылар. Югыйсә, бөтен өметләре өзелгән ирнең уенда ниләр булганын чамалау кыен түгел.

Әлбәттә, үз-үзенә кул салучылар арасында фатирсыз интегүчеләр генә түгел. Теләгәненә ирешә алмау, авыр хәлләрдән чыгу юлын таба белмәү, төрле психологик басымнарга түзмәү дә моңа сәбәп булган очраклар байтак. Мәсәлән, Васильево бистәсендә яшәүче Хафизовларның бердәнбер уллары поезд астына сикереп үлә. Машинист әйтүенчә, егет моны үзе теләп эшли. Чөнки башта поездның якынлашуын басып көтеп тора, сигналга игътибар итми. Состав якынлашкач кына рельска сузылып ята. Егет нишләп күрәләтә башын поезд астына салган соң? Бер карасаң, моңа сәбәп тә юк кебек. Ата-аналарына бер бала. Йорт-җирләре җитеш, машиналары бар, өс-башлары бөтен. Баксаң, узган көнне өйдә тавыш куба. Улы әтисеннән машинаны бөтенләйгә алмакчы булган, тик гаилә башлыгы каршы килгән. Нәтиҗәдә уллары мәрхүм, ә озак еллар тигез гомер кичергән гаилә аерылышырга җыена.

Гомумән, соңгы вакытта үзен-үзе үтерүчеләр саны арта бара. 1993 елда андыйлар республика буенча 1341 кеше исәпләнсә, 1994 елда алар 1669га җитә, ә быелның тугыз аенда гына да 2 меңгә якын шундый очрак теркәлгән. Республика дәүләт статистика идарәсенең махсус бүлеге хезмәткәре В.Культынова бу җәһәттән болай диде.

— Үзен-үзе үтерүчеләр санының артуына тормыш шартларының шактый кыенлашуы сәбәпче. Аннан соң безне яшьләрнең тормыш авырлыкларын җиңәргә сәләтсез булып үсүләре, әхлакый яктан тотрыксыз, берниндиихтыяр көченә ия булмаулары нык борчый. Алар эчкечелеккә, тәмәке тартырга, наркотиклар кулланырга җәһәт өйрәнеләр. Күңел төшенкелегенә тиз бирешүчән чирләшкә буын формалашуга нәкъ менә шушы күренешләрнең артуы зур этәргеч ясады.

Әлбәттә, кайберәүләр башкачарак та фикер йөртә.

— Үзен-үзе үтергән кеше беренче чиратта туганнарына һәм якыннарына зур рәнҗү белән дөньядан китә. Ә нәсел ниндидер мыскыллануга, зур рухи басымга дучар була. Һәм исәннәр әлеге авырлыкны күтәреп яши, — дип сөйли укытучы Роза Сәгъдәтшина.

Озак еллар «Чаян» журналында эшләүче Мөнирә апа Гатауллина шактый гына кызыклы фикерләр әйтте:

— Кеше холкы шулай ясалган: тормышта гел бишенче почмакны эзли. Таба алмаса, шуннан котылу юлы итеп үлемне сайлый. Әлбәттә, моңа аны этәрүчеләр дә була. Начар ниятле компаниядә йөрүчеләр, даими рәвештә физик һәм психик мыскыллванучылар һәм башкалар. Гаиләдә исә үзара аңлашып яшәү дә бик мөһим. Мин җәмәгатем белән һәрвакыт шулай яшәдем. Аның уй-фикерләрен уртак иттем, теләкләренә каршы килмәдем. Менә шунда да инде безне Аллаһы Тәгалә андый чиккә барып җитүдән саклады.

Мөнирә апага кушылып бу урында шәхси фикеремне дә әйтеп китәр идем. Дөрестән дә, кешене аңлый белү, аңа җылы караш күрсәтү бик мөһим. Әле армия сафларында хезмәт итә башлаганда Әнвәр исемле таҗик егете белән дуслашкан идем. Ул җылы якта үскән. Бирeдәге зәмһәрир суыкларны күрмәгән. Шунлыктан аны һәрвакыт җылырак киендерергә, хәтта урамга эшкә чыгарсалар, аның урынына үзем барырга тырыша идем. Инде хезмәт срогы бетеп, хушлашыр алдыннан Әнвәр мине кочаклап болай диде.

— Рәхмәт сиңа, Рамил. Әгәр син булмасаң, мин, бәлки, бу көннәргә кадәр яши дә алмаган булыр идем.

Әнвәрнең бу сүзләрен бер дә онытмыйм. Кешегә күңел җылысын бирә белү дә кирәк шул безгә.

Татарстан эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре М.Нуриев үз-үзен үтерүчеләр исәбенә физик һәм акыл ягыннан җитлекмичә туучыларны, яшәешнең мәгънәсен аңламыйча тормыштан туючыларны да кертә.

— Көнчелектән, авыр хәсрәт кичерүдән яки эшсезлектән дә үлемгә баручылар соңгы елларда күбәйде, — дип сөйли Мөхәррәм әфәнде. Күптән түгел Дәрвишләр бистәсе урманына кереп асылынган 27 яшьлек егет табылды. Чыгышы белән Биектаудан, техникум белеме алган. Һәм шунысы кызык, латинча сөйләшә һәм яза белгән. Ләкин соңгы елларда беркая да эшкә урнаша алмыйча интегеп йөргән.

Гомумән, соңгы вакытта яшьләр арасында үз-үзен үтереп гомерләрен өзүчеләр арта бара. Чөнки тормыш авырлыгына иң беренче нәүбәттә яшь буын тиз бирешүчән була. Мәктәп еллары

(Ахыры 24 нче биттә).

Асыл ирләр нигә асылына?

(Ахыры. Башы 23 нче биттә).

узгач, олы тормыш бусагасына аяк баскан кешенең үк һәркемнең җилкәсенә зур авырлык баса. Кызганычка, ул йөкне күпләр күтәреп бара алмый — канатлары тиз сына. Җитмәсә, хәзер хөкүмәт яшьләргә матди ярдәм күрсәтми, элек булган һәртөрле ташламаларны киметкәннән-кимәтә генә. Моның тискәре нәтиҗәләре күз алдыбызда. Шулай ук асыл егетләребезнең асылыну сәбәпләре дә көн кебек ачык. Ә моңа чик куелырмы, юкмы, бөтенләй билгесез. Чөнки тормышыбыз тискәре якка — хәерчелеккә, эшсезлеккә, эчүчелеккә таба көннән-көн күбрәк авыша.

Әлбәттә, барысына да тормыш авырлыгы сәбәпче, дип расларга маташу бигүк дөрес булмас иде. Җинаятьчелекнең массакүләм дәрәҗәдә артуы да күпләрне тормыштан ваз кичүгә этәрә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең тиешле дәрәҗәдә камил булмавы, гражданнарның шәхси хокукларының гарантияләнмәве, аларның теләсә кем тарафыннан һәм теләсә кайсы мизгелдә җәберләнә алу ихтималының чиктән тыш үсүе, аерым шәхесләрнең мәнфәгате беркем тарафыннан да якланмавы — үлемгә китерүче иң зур сәбәпнең берсе. Шул җәһәттән бер мисал китерәсем килә. Педагогия университетында укуын тәгәлләгән бер төркем яшьләр авылларга җибәрелә. Алабуга егете Сирай Гәрәев тә шулар арасына эләгә. Булдыклы, тырыш егет авылда да тик ятмый. Авыл яшьләренең күңелен күрер өчен кичен клубларда һәртөрле кичәләр, концертлар, дискотекалар оештыра. Үзе дә аларда катнаша, бии, җырлый, сыздырып гармун уйный. Бер карасаң, уңган егетнең тырышлыгына сокланасы гына да бит. Ләкин арада көнләшүчеләр табыла. Шундыйлар С.Гәрәевне чираттагы концерттан кайткан чагында тотып кыйныйлар. Күз төпләре шешенгән, авыр тән җәрәхәтләре алган егет бу мәсхәрәне күтәрә алмыйча, үзе торган карчыкның ихатасында асылынып үлә...

Үзенә-үзе кул салган кешене Шәригать кануннары буенча зиратка илтеп күмү тыела. Адәмгә җанны бер Аллаһы Тәгалә иңдерә һәм фәкать Аның ихтыяры белән генә ул кире алынырга мөмкин, — диелә Коръән сүрәләренең берсендә. Әмма шул ук Аллаһ тарафыннан яратылган бәндәнең акылы шулкадәр катлаулы, еш кына ул сүрәдә язылган кырыс маддәләр белән дә исәпләшми.

Минем асылынып үлүчеләр хакында табиблар белән дә сөйләшкәнем бар. Араларыннан берсе болай дигән иде: «Яман чир белән авырган кешене даваларга бернинди ысул юк. Кеше үзен-үзе кулга алса гына, үзен-үзе тормыш кыенлыкларын җиңәргә мәҗбүр итсә генә, ул яшәячәк». Мин сүзсез калдым. Кем әйтмешли, дөрес сүзгә җавап юк икән ул. Гәрчә, асыл ирләребез асылынып үлүгә сәбәпләр бихисап булса да!

Укчы йолдызлыгы астында туганнар

21 декабрь

Хәбибрахманова Роза Хәбибрахман кызы — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты.

Яһүдин Әзәл Бәдретдин улы — Татарстанның атказанган артисты.

Кәҗәмөгез йолдызлыгы астында туганнар

23 декабрь

Якупов Харис Абдрахман улы — СССРның һәм Татарстанның халык рәссамы, СССР һәм Татарстан Дәүләт бүләкләре иясе.

24 декабрь

Йосыпов Фәйзи Сәяр улы — Татарстанның атказанган артисты.

25 декабрь

Тавлин Гурий Иванович — язучы.

Хәбибуллин Мөсәгыйт Мөдәррис улы — язучы.

Мадякин Федор Павлович — КТУның инженерлык химия технологиясе кафедрасы мөдире, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире.

26 декабрь

Сафиуллин Әхәт Хафизулла улы — язучы.

Дәүләтшин Дамир Госман улы — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты.

Артамонов Николай Степанович — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, проектлаучы.

Ишбүлеков Идеал Дәүләт улы — РФнең атказанган, Татарстанның халык артисты.

28 декабрь

Фәтхетдинов Әхсән Сәрим улы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе.

НЕДОРОГО

Научно-производственное предприятие «Август» реализует со склада в г. Казани:

- *1. Стиральный порошок.*
- *2. Жидкие синтетические моющие средства.*
- *3. Отбеливатели: «Белизна», «Персоль», «Универсальный».*
- *4. Соду кальцинированную.*
- *5. Чистящие средства.*
- *6. Освежитель воздуха.*
- *7. Антистатик.*
- *8. Ароматизатор для ванн.*
- *9. Средство для осветления волос.*
- *10. Средство для борьбы с садовыми насекомыми.*
- *11. Средство для борьбы с колорадским жуком.*
- *12. Средство для борьбы с головным педикулезом.*
- *13. Средство для борьбы с молью, кожеедом.*
- *14. Краски для наружных и внутренних работ.*

**Форма оплаты любая.
Возможна оплата векселями «Ак Барса» и бартер.
Контактный телефон в Казани: 53-77-76.**

Калыр, китмәс, яшәр

«Сөт калыр, Ватан китәр!» дип язган Дәрдмәнд. Иншалла, **сөт тә калыр, Ватан да китмәс, «Мәдәни җомга» да яшәр!**

Хөрмәтле укучыларыбыз! Инде белгәнегезчә, 15 декабрьдә көндәлек матбугатка язылу тәгәлләнде. Әмма теге яки бу сәбәп аркасында «Мәдәни җомга»лы була алмаган дусларыбызга шуны искәртәбез:

беренчедән, киләсе елның 10 гыйнварына кадәр почта бүлекләренә барып, абонемент кәгазен тутырсагыз, гәзит сезнең өегезгә 1 февральдән килә башлар;

икенчедән, басмабызны редакциягә килеп алырга теләүчеләр өчен әле тулаем еллык подписка эшләү мөмкинлеге бар. Моның өчен безгә килеп мөрәҗәгать итегез. Адресыбызны исегезгә төшерәбез: Казан, Бауман урамы, 19. Язылу бәясе — 25 мең 392 сум.

Күлсәң — күп, күлмәсәң — ела

КОТЛЫЙБЫЗ!

Бүген, 22 декабрьдә, Әтнә кызы, сеңлебез Гөлназ белән Кече Әтнә егете Марсның тормыш сукмаклары кушылган бәхетле көннәре.

Гаиләдәге бердәм дуслык кына
Күркәм итә олы тормышны!
Хәерле юл сезгә МАРС - ГӨЛНАЗ,
Юлларыгыз булсын уңышлы!

Барлык туганнарыгыз исеменнән апагыз Фәридә.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Театр әһелләре берлеге һәм Минзәлә Татар дәүләт драма театры коллективы, Татарстанның халык артисты, Минзәлә театрының өлкән буын артистларыннан берсе, танылган сәхнә остасы

Рәшид Мөрдыхан улы Мөрдыхановның

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклашалар.

«Мәдәни җомга» гәзите редакциясе коллективы,

әнисе Гайшә апаның

озакка сузылган каты авырудан соң вафат булуы сәбәпле, редакция хезмәткәре Гөлира Сәләхованың, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Мәдәни Җомга

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый.

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук әзмәтләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

Реклама урнаштыру өчен игъланнар кабул ителә.

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең хисап-исәп счеты 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре күренсә, 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатулагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4471